МИРАС

ЧЫН

ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ

№9 / сентябрь 2013

ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕНӘ
60 ЕЛ

ТАТАРСТАН
НЕФТЕНӘ
70 ЕЛ

ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ, ЯҢАЧА КАРАШ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ **УКАЗЫ**

ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ ТӨЗЕЛҮНЕҢ 60 ЕЛЛЫГЫН ҺӘМ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА НЕФТЬ ЯТМАЛАРЫН ЭШКӘРТӘ БАШЛАУНЫҢ 70 ЕЛЛЫГЫН БӘЙРӘМ ИТҮ ТУРЫНДА

Татарстан Республикасының икътисади һәм социаль үсешендә нефть тармагының һәм Әлмәт шәһәренең зур ролен билгеләп, карар бирәм:

1. 2013 елның сентябрендә, Нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәрләре көненә туры китереп, Әлмәт шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм Татарстан Республикасында нефть ятмаларын эшкәртә башлауның 70 еллыгын бәйрәм итәргә.

2. Әлмәт шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм Татарстан Республикасында нефть ятмаларын эшкәртә башлауның 70 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты төзергә һәм аның составын расларга (кушымта итеп бирелә).

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына өч ай эчендә, аларны үткәрү вакытларын, җаваплы башкаручыларны, финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын күрсәтеп, Әлмәт шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм Татарстан Республикасында нефть ятмаларын эшкәртә башлауның 70 еллыгын бәйрәм итүне әзерләү һәм аны уздыру буенча төп чаралар планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенә, республика һәм җирле массакүләм мәгълүмат чараларына Әлмәт шәһәре төзелүнең 60 еллыгын һәм Татарстан Республикасында нефть ятмаларын эшкәртә башлауның 70 еллыгын бәйрәм итүне киң яктыртуны тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты **Р.Н.Миңнеханов**

Казан, Кремль

МИРАС
ЧЫН
ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ №9 (21) / сентябрь 2013

Эчтәлек

Татарстан Республикасы Президенты Указы

ТАРИХ

4 **Әлмәт — Татарстанның ныклы терәге** (Әлмәт шәһәренә 60 ел). *Мәҗит Салихов*
14 **Татарстанда нефть чыгара башлауга 70 ел.** *Шәфәгать Тәхаветдинов*
18 **XVIII гасырда Әлмәт төбәге һәм Әлмәт авылы тарихыннан.** *Айдар Ногманов*
28 **Әлмәт районы Бөек Ватан сугышы елларында.** *Айсылу Кәбирова*
33 **1950-1960 елларда ТАССРда нефть сәнәгате өчен мәгариф инфраструктурасының формалашуы.** *Марат Минкин*
37 **Әлмәт шәһәрендә иҗтимагый-мәдәни тормыш һәм мәгариф үсешенең кыскача елъязмасы**
40 **«Татнефть»нең кыскача елъязмасы**
43 **Татарстан нефтьчеләре гимны.** *Нур Әхмәдиев*
44 **Татарстанның көньяк-көнчыгыш шәһәрләрен төзүдә Чупай таш карьерының роле.** *Рамил Ханнанов*
48 **Хәтер сагында** (Әлмәт туган якны өйрәнү музее). *Ленар Гобәйдуллин*
52 **Әлмәт районында төбәкчелек гыйлеменең үсеше.** *Әлфия Галләмова*
58 **Суфый буларак Шиһабетдин Мәрҗани.** *Сәед Дамир Шаһаби*

ӘДӘБИЯТ

66 **Рухи дөнья җәүһәрләре.** (Әлмәт язучылар оешмасына 50 ел) *Илүсә Нәбиуллина*
74 **Хатлар булып калган хатирәләр.** *Рөстәм Төхфәтуллин*
82 **Күларты посёлогы.** *Клара Булатова*
84 **Гаяз Исхакый хатлары.** *Лена Гайнанова*
89 **Уйлар Ватаны.** *Флёра Гыйззәтуллина*
90 **Кылдан нәзек, кылычтан үткен.** *Аяз Гыйләҗев*
96 **«Бер-бер артлы замандашлар китә, өлгералмыйсындыр кул болгарга...»** *Харрас Әюпов*
99 **Буровойлар гөрелтесе.** *Энҗе Мөэминова*
100 **Тукай энциклопедиясенә.** *Зөфәр Рәмиев*

СӘНГАТЬ

104 **Әлмәт төбәгендә татар театры: 1940-1970 еллар.** *Дания Гыйльманова*

112 **Яңа китаплар.** *Ленар Гобәйдуллин*

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

116 **Акыл — тузмас кием, гыйлем — корымас кое.** *Гүзәл Нәбиуллина, Лилия Гыйләҗева*

12 +

Журнал «ТАТМЕДИА» ААҖ тарафыннан гамәлгә куелды.
2012 елның май аеннан чыга.

Баш мөхәррир —
Илфак Мирза улы ИБРАҺИМОВ
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары — җаваплы сәркатип —
Рамил ХАННАНОВ
(843) 222-09-83 (17-93)

Редакция советы:
Марсель Әхмәтҗанов
Разил Вәлиев
Резеда Ганиева
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Дания Заһидуллина
Илдус Заһидуллин
Данил Ибраһимов
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Данил Мостафин
Рөстәм Мөхәммәдиев
Рафыйк Мөхәммәтшин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Индус Таһиров
Рамил Ханнанов
Рафаил Хәкимов
Әнвәр Хуҗиәхмәтов

Бүлек мөхәррирләре:
Илдус ЗАҺИДУЛЛИН
Ленар ГОБӘЙДУЛЛИН
Ренат МИҢНЕГАЛИЕВ
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы —
Диләрә НӘҮРҮЗОВА
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректорлар:
Дания ФӘЙЗУЛЛИНА
Алия МӨБАРӘКШИНА
(843) 222-09-83 (17-90)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

Заказ №С-1952
Тираж — 2000 данә.
Формат 70 x 108 1/16
Басарга кул куелды: 23.08.2013
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Бәясе ирекле

Безнең журналга
54132 ИНДЕКСЫ
буенча Татарстанның һәм
70275 ИНДЕКСЫ
буенча Россия төбәкләренең
һәр элемтә бүлегендә язылырга
мөмкин.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-49398 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция хезмәткәрләренең фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.
Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә.
Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Тышлыкның 1 нче битендә — ике миллиард тонна (1943-1981) нефть чыгару хөрмәтенә Татарстан нефтьчеләренә куелган һәйкәл. Әлмәт шәһәре.
Л.Гобәйдуллин фотосы

Бу санда Л.Гобәйдуллин, авторларның архивларыннан, Әлмәт муниципаль районы хакимиятенең матбугат үзәге, «Альметьевский вестник» газетасы, «Татнефть» ААҖнең матбугат үзәге, Әлмәт туган якны өйрәнү музее, Әлмәт Татар дәүләт драма театры, Әлмәт язучылар оешмасы фондларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

«Истинное наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Тарих

...Чал тарихның һәрбер мизгелендә
Татар җанлы кайнар ярсу бар...

Флёра Гыйззәтуллина

ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕНӘ 60 ЕЛ

ӘЛМӘТ – ТАТАРСТАННЫҢ НЫКЛЫ ТЕРӘГЕ

МӘҖИТ САЛИХОВ,
Әлмәт шәһәре һәм муниципаль районы башлыгы



БУ ЕЛНЫҢ НОЯБРЬ АЕНДА ӘЛМӘТЕБЕЗГӘ – 60, ТАТАРСТАНДА НЕФТЬ ЧЫГАРЫЛА БАШЛАУГА 70 ЕЛ ТУЛА. ТАТАР ДӨНЬЯСЫНА КҮРЕНЕКЛЕ МӘГЪРИФӘТЧЕ РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИННЕ, АЛТЫН СӘНӘГАТЕН ҮСТЕРҮГӘ ЮЛ АЧКАН ЭШКУАРЛАР ЗАКИР ҺӘМ ШАКИР РӘМИЕВЛӘРНЕҢ АТА-БАБАЛАРЫН, ЯЗУЧЫ ҺӘМ ЖУРНАЛИСТ ФАТИХ КӘРИМИ, ТАРИХЧЫ-ГАЛИМ ҺАДИ АТЛАСИ, ТАНЫЛГАН ШӘХЕСЛӘР ШАМИЛ БИКЧУРИН, ЛӘБИБ ГЫЙЛЬМИ, АФЗАЛ ТАҺИРОВ, ХИСАМ КАМАЛОВ ҺӘМ БАШКА ДИСТӘЛӘГӘН ОЛУГ ЗАТЛАРНЫ БИРГӘН ӘЛМӘТ ТӨБӘГЕ – ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАЙОННАРЫНЫҢ ИҢ АБРУЙЛЫСЫ.

БОРЫНГЫДАН – БҮГЕНГЕГӘ

Каланың тарихы XVIII гасыр башында нигезләнгән Әлмәт авылыннан башлана. XIX-XX йөзләрдә биредә яшәүчеләр игенчелек, терлекчелек, чыпта-кап сугу, сәүдә итү белән шөгыльләнгәннәр. XX йөз башында Әлмәттә 3 мәчет, 2 мәдрәсә, земство хастаханәсе, почта-телеграф бүлекчәсе, пар тегермәне эшли, чәршәмбе саен базар, һәр елның 20-26 декабрендә ярминкә үткәрелә. 1920 елдан Әлмәт ТАССРның Бөгелмә кантонына керә, ә 1930 елның 10 августыннан район үзәге була.

1930 еллар башында, бөтен илдәге кебек үк, бу төбәкләр дә күмәкләштерүне кичерә: 54 күмәк хуҗалык оештырыла, зур булмаган терлекчелек комплекслары сафка бастырыла, йөк ташу

XX гасырның I яртысында Әлмәт авылы урамы.
Фото Әлмәт туган якны өйрәнү музее фондыннан

машиналары һәм башка төрле авыл хуҗалыгы техникалары алына.

Ил өстенә кара кайгы булып килгән Бөек Ватан сугышы күп планнарны юкка чыгара. Ил тоткасы булырдай ирләр фронтка алына, хуҗалык итү хатын-кызлар һәм балалар җилкәсенә кала. Әлмәт районыннан 18,5 мең кеше сугышка алына, шулардан 8509 якташыбыз яу кырында мәңгелеккә ятып кала. Райондашларыбыз арасында ике Советлар Союзы Герое — Никита Токарликов һәм Мотыйк Әхмәдуллин, Дан орденының III Дәрәҗәсенә дә ия булган кавалерлар — Корбан Тимергалиев, Гәрәфетдин Сәләхетдинов һәм Михаил Алаевның булуы безнең өчен зур горурлык.

Нәкъ менә сугыш кызган вакытта — 1943 елда — Шөгердә беренче нефть фонтаны бәреп чыга. 1948 елда дөньядагы иң эре Ромашкино ятмалары ачыла. Әлеге вакыйга Әлмәтнең, шул исәптән бөтен республиканың киләчәген билгели. 1950 елда Советлар Союзында иң эре нефть табу берләшмәсе — «Татнефть» оештырыла. Беренче нефтьчеләрнең тырышлыгы һәм хезмәттәге батырлыгы нәтиҗәсендә, 1955 елда берләшмә кара алтын табу буенча Советлар Союзында беренчелекне яулый. Бу алдынгы позицияне Әлмәт нефтьчеләре 17 ел дәвамында саклап тора.

1952 елның 25 мартында Әлмәт авылы шәһәр тибындагы Әлмәт посёлогы итеп үзгәртелә. РСФСР Югары Советы Президиумы Указы нигезендә, 1953 елның 3 ноябрендә Әлмәткә шәһәр статусы бирелә.

Сугыш чорындагы хәрабәләр торгызылганнан соң, 1960 елларда колхоз һәм совхозларда күтәрелеш, терлекчелек һәм игенчелектә үсеш күзәтелә. Бу елларда «Акташ» һәм «Җиңү», Токарликов исемендәге совхозларда, «Ярыш» колхозында мөгезле эре терлек үрчетү өчен зур-зур комплекслар сафка бастырыла.

1980 елларны авылның иң нык үсеш алган чоры дип бәяләргә мөмкин. Халыкның тормыш-көнкүреш шартлары яхшыра, балалар бакчалары, мәктәпләр, фельдшерлык пунктлары төзелә, юллар салына, су үткәрелә. Ул елларда Әлмәт районы республикада беренчеләрдән булып авылны газлаштыру программасын төгәлли.

1990 елларда иҗтимагый-сәяси вазгыять үзгәрү белән, илгә базар мөнәсәбәтләре үтеп керә. Республикадагы уңай үзгәрешләрдә Әлмәт районының икътисади куәте дә хәлиткеч роль уйный. Чөнки «Татнефть» ААҖ һәм казна бюджетын тулыландыра торган сәнәгать оешмалары югары технологияләргә нигезләнеп эшләүгә йөз тота, нефтехимия һәм химия сәнәгатен үстерү бурычлары куела. Әлмәтнең тотрыклы үсешенә ныклы

Әлмәт шәһәренең Ленин урамы

нигез салына. Шәһәр белән бергә авыллар да төзекләнә, ныгый.

Бүгенге Әлмәт Татарстан Республикасында динамик рәвештә үсеш кичерүче, ныклы икътисадлы, бай инфраструктуралы индустриаль үзәкләрнең берсенә әверелде.

НЕФТЬЧЕЛӘР — ТӨП ТАЯНЫЧЫБЫЗ

Нефтьчеләр — безнең төп таянычыбыз. «Татнефть» ААҖ җитәкчелеге ярдәме белән «Татарстан нефтенең 60 еллыгы исемендәге» парк Россиянең югары дәрәҗәдәге ял һәм күңел ачу үзәгенә әверелде, иң яхшы тау чаңгысы комплексларының берсе бездә, шәһәр үзәгендә гаҗәеп су-архитектура ансамбле — җиде өлештән торган шарлавыклы буалар бар, шунда ук велосипедчылар юлы сузылып киткән. Социаль объектлардан медицина-хирургия комплексы, Яшьләр үзәге, ипподром, Шахмат клубы, Хөкем йорты, TENNIS-SITI, Әлмәт нефть институты, «Нефтьче» мәдәният йорты, реконструкцияләнеп, яңа, заманча биналарга әверелүен лаеклы рәвештә олы казаныш буларак билгеләп үтәбез. Болардан тыш Комсомол паркы, Казан Изге Ана иконасы чиркәве да өр-яңадан төзекләндерелде.

Халыкның тормыш дәрәҗәсе яхшырган саен, сәүдә комплексларын арттыру ихтыяҗы барлыкка килә. «Панорама», «Корона», «ЭССЕН» сәүдә, «АКОС», «ТранТехСервис», «Альтернатива» диллерлык үзәкләре — соңгы берничә ел эчендә сафка бастырылган объектлар.

Каладагы тормыш дәрәҗәсен билгели торган фактор — юллар да игътибар үзәгендә. Соңгы биш елда гына да 6 транспорт чишелеше, 4 җир өсте һәм җир асты машиналар кую урыны, җәяүлеләр өчен 5 җир асты юлы булдырылды. Әминов, Шевченко, Ленин, Гафиятуллин урамнарының дәвамы барлыкка килү нефтьчеләр башкаласының киңәюен дәлилли. 20дән артык шәһәр урамына реконструкция, 50сенә капиталь ремонт ясалды. Әйләнмәле юлларның 5,5 км озынлыктагы бишенче чираты салынды, региональ һәм федераль карамактагы юллар төзекләндерелде.

Нефтьчеләрнең саллы ярдәме авыллар үсешенә дә зур йогынты ясый. Соңгы 6 ел эчендә су линияләрен алмаштыруга 100 млн сумнан артык акча бүленде. «Чиста су» республика программасы, «Татнефть» булышлыгы белән 7 торак пунктта су линияләре төзелде һәм ремонтланды. Социаль инфраструктура үсеше, шәһәр төзелеше, ТОСМСлардагы (территориаль иҗтимагый җирле үзидарә советы)

эшчәнлек, экология, авыл хуҗалыгы — кайсы гына тармакны алсак та, без нефтьчеләрнең ныклы ярдәменә таянабыз, аларның булышлыгы белән планнарыбыз чынбарлыкка әверелә.

ӘЛМӘТ — ЕВРОПА ДӘРӘҖӘСЕНДӘГЕ ШӘҺӘР

Әлмәт шәһәренең тарихи-мәдәни мирас объектлары исемлегенә 2 нче Җамигъ мәчете (1877) һәм район советы бинасы (1920 еллар) керә. 1950 елларда үзәк кварталларның төп өлешен алып торган бер-икекатлы щит йортлар урынына икекатлы таш тораклар һәм җәмәгать биналары (Техника йорты (1955-60), «Россия» кинотеатры (1959) һ.б.) үсеп чыга.

XXI гасырда да каланың үсеше кызу темплар белән дәвам итә. Дүрт ел эчендә Әлмәт, бер елга 155 мең кв. метрдан артык торак төзеп, үзенең тарихында рекордлы нәтиҗәләргә иреште. Социаль ипотека программасы нигезендә «Яшьлек» һәм «Көнбатыш капка» микрорайоннары барлыкка килде. Әлмәткә — 60, Татарстанда нефть чыгарыла башлауга 70 ел тулган тарихи вакытны да нефтьчеләр башкаласы төзелеш тармагында югары күрсәткечләр белән каршылый. «Көнбатыш капка»да 270 урынга исәпләнгән балалар бакчасы төзелеше бара, «Татнефть» ААҖ ярдәме белән «Яшьлек»тә 1250 урынга исәпләнгән, заман таләпләренә җавап бирерлек мәктәп сафка бастырылды.

«Алсу» микрорайоны коммерция торагы хисабына үсә. Күптән түгел генә биредә «АЛНАС» заводы хезмәткәрләре өчен 106 фатирлы йорт салынып куллануга тапшырылды, шәхси торак йортлардан торган «Дуслык», «Ивушка», «Урсала» микрорайоннары калкып чыкты.

2013 елда шәһәрнең 60 еллыгы уңаеннан республика бюджетыннан кварталара юлларны һәм 30 ишегалдын төзекләндерүгә 50 млн сум бүлеп бирелде. Президент программасы нигезендә, баскетбол, мини футбол, тренажёрлар өчен көйләнгән универсаль мәйданнар төзү эше төгәлләнү алдында. Әлмәттә мондый универсаль уен мәйданнары 8 урында булдырылды.

Республика программасы кысаларында, быел район һәм шәһәрнең 10 мәгариф учреждениесендә капиталь төзекләндерү эше башкарылды. Авыл клублары төзелеше программасы буенча, Елховойда күп функцияле үзәк сафка бастырыла. Татарстанда беренче медицина ярдәме күрсәтүне камилләштерү максатыннан оештырылган чаралар Кузай участок хастаханәсендә, Ямаш һәм Чуваш Сиренькиносы авылларындагы табиблык амбулаторияләрендә, 7 авылның фельдшер-акушерлык пунктында капиталь төзекләндерү үткәрергә мөмкинлек бирә.

Шәһәрдәге уңай үзгәрешләрнең күп өлеше, әйткәнебезчә, нефтьчеләребез ярдәме белән булдырыла. «Татнефть» ААҖ генераль директоры Шәфәгать Тәхаветдинов карары белән, агымдагы елда да калабызны төзекләндерү эшенә күп миллионнар бүлеп бирелде. Бу сумманың бер өлеше Әлмәтнең туберкулёз, психоневрология диспансерлары, Акташ участок хастаханәсе, Әлмәт үзәк хастаханәсенең инфекция бүлеге һәм башка учреждениеләрне төзекләндерүгә юнәлдерелде.

Әлмәт — Европа дәрәҗәсендәге шәһәр! Соңгы елларда калабызга карата мондый бәяне бик еш ишетәбез һәм аны зур горурлык хисе белән кабул итәбез. Чиста, уңайлы урамнар, төзекләндерелгән ишегаллары, матур мәйданчыклар, яшел парклар, заманча мәктәпләр һәм балалар бакчалары, мәдәният, сәламәтлек саклау, спорт объектлары... Бу — республика һәм Бөтенроссия бәйгеләре нәтиҗәләре буенча Татарстанның һәм Россиянең иң төзек шәһәрләренең берсе булып танылган кала!

Әйләнә-тирә мохитне саклау эшендә дә күрсәткечләр куандырырлык. Соңгы 10 елда гына да экологик программаларны тормышка ашырыр өчен, 45 миллиард сумнан артыграк (чишмә һәм елгаларны чистарту-тәрбияләүгә, шәһәр һәм районны яшелләндерүгә, һава торышына контрольлек итүгә һ.б.) акча тотылды.

Экологлар тарафыннан гомуми мәйданы 200 гектарга якын 5 парк төзү буенча эш алып барыла. «2012-2015 елларга Әлмәт шәһәре территориясендә парклар һәм скверларны төзекләндерү» программасы эшләнде, аның кысаларында 35 яңа сквер һәм аллея булдыру күздә тотыла. Яңа микрорайоннар интенсив рәвештә үсә һәм төзекләнә, Әлмәт Татарстанның чын нефть башкаласына әверелде. Әлеге уңышлар — бу бәрәкәтле җирдә яшәүче кешеләрнең уртак хезмәте нәтиҗәсе.

ҖЫРЛЫ, МӘДӘНИЯТЛЕ ТӨБӘК

Шунысы игътибарга лаек: нефтьчеләр башкаласындагы эшчәнлек икътисади яктан гына түгел, мәдәният, мәгариф үсеше тармагында да югары бәягә лаек.

Әлмәт ягы — җырга-моңга бай төбәк. Миңлебай авылы егете Шамил Бикчуринның композитор Әнвәр Бакиров белән берлектә иҗат иткән, киң колачлы «Тальян моңы» музыкаль комедиясе, Әлмәттән башланып китеп, Казан опера театры сәхнәләрен гөрләтте. Әдип Маликов, Саҗидә Сөләйманова, Гамил Афзал, Энҗе Мөэминова, Клара Булатова, Нур Әхмәдиев, Илдар Әхсән, Роберт Рәкыйпов, Разим Вәлиуллин һәм башка бик күп шагыйрьләребезнең шигырьләренә моң канатлары биргән Мәсгут Имашев, Рәис Нәгыймов, Зиннур Сафиуллин, Булат Юныс, Роберт Андреев һәм башкалар татар музыка сәнгатенең хәзинәсе булып торырлык җырлар тудырдылар.

Шәһәрдә һәм районда тарихи-мәдәни мирасыбызны барлау, үстерү, милли гореф-гадәтләребезне халыкка кайтару, татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтү, зыялы татар яшьләрен тәрбияләү дә көнүзәк мәсьәлә булып санала. Кичүчат авылында — Ризаэддин Фәхреддин, Миңлебайда Фатих Кәрими мемориаль комплексларында, Әлмәттә — төбәкне өйрәнү, Елховойда Хәлиулла Әхмәтшин исемендәге туган якны өйрәнү музей-

Ризаэддин Фәхреддин исемендәге мөселман дини үзәге



Казан Изге Ана иконасы чиркәве

ларында милли мирасыбызның бай өлеше саклана. «Татнефть» ААҖнең «Рухият» рухи яңарыш фонды ярдәме белән ел саен төбәктә туып үскән, яшәгән күренекле галимнәрнең, язучы һәм шагыйрьләрнең әсәрләре нәшер ителә. Нефтьчеләр тарафыннан — С.Сөләйманова, муниципалитет тарафыннан Р.Төхфәтуллин исемендәге махсус әдәби бүләкләр булдырылды.

Калабызда Татар дәүләт драма театры, Әлмәт милли-мәдәни үзәге, «Нефтьче» мәдәният сарае, балалар һәм яшүсмерләр иҗаты үзәге, картиналар галереясы һәм 13 китапханә бар. Исемнәре республикада гына түгел, дөньяның күп илләрендә билгеле «Әлмәтем», «Настроение», «Кардинал», «Серпантин» җыр һәм бию коллективлары, бертугандай дус булып яшәгән татар, рус, чуваш, мари халыкларының фольклор ансамбльләре Әлмәтне җырлы, мәдәниятле төбәк буларак таныта. Шуңа күрә дә чит төбәкләрдә яшәүче татарлар өчен уздырыла торган милли бәйрәмебез — Сабантуйларны оештыру нәкъ менә әлмәтлеләргә ышанып тапшырыла. Быел без, Санкт-Петербургта халыкара югарылыкта Сабантуй уздырып, милләттәшләребезнең күңел түрләрендә гореф-гадәтләребезнең сакланып калуына зур өлеш керттек.

«Татнефть» ААҖнең «Рухият» рухи яңарыш фонды тарафыннан үткәрелә торган «Сандугач сайрар илем» республика фестивале талантлы яшьләрне барлау, аларны үстерү юнәлешендәге күркәм эшләрнең берсе.

Әлмәтнең үз массакүләм мәгълүмат чаралары да уңышлы гына эшләп килә. «Луч» телекомпаниясе күптән түгел генә үзенең 22 яшьлек туган көнен билгеләп узды. 16 еллык тарихы булган «Яшьләр заманы» газетасы агымдагы елда «Альметьевский вестник» — «Әлмәт хәбәрләре» итеп үзгәртелде. Газета рус һәм татар телләрендә нәшер ителә, киң катлам укучыларны кызыксындырган актуаль проблемаларны яктырта.

МИЛЛИ МӘГАРИФНЕҢ ТОРЫШЫ

Бүген Әлмәт муниципаль районы мәгариф системасында милли тәрбия һәм белем бирү системасы җайга салынган, икетеллелекне үстерү юнәлешендә максатчан эш алып барыла. «Татарстан Республикасы телләре турындагы Закон», 2004-2013 елларга кабул ителгән «Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Дәүләт Программасы» нигезендә, милли мәктәпләр, балалар бакчалары ачу һәм

аларның эшен оештыру, ата-аналарның туган телдә белем һәм тәрбия алуга өстенлек бирүләренә ирешү, кадрлар туплау, адекват үсештәге мохит булдыру буенча эш тәҗрибәбез шактый. «Татарстан Республикасында 2010-2015 елларга төзелгән Мәгариф үсеше стратегиясе» милли белем һәм тәрбия бирү юнәлешендә киләчәгебезне билгеләде. Районда 17 татар мәктәбе, 25 татар балалар бакчасы, 4 (1 филиал) чуваш этнокультура компонентлы мәктәп, 2 чуваш балалар бакчасы, 1 мордва этнокультура компонентлы мәктәп филиалы эшли. Югары Акташ авылы балалар бакчасында туган телдә — мордва телендә белем һәм тәрбия бирү эше оештырылган, шәһәрнең 33 балалар бакчасындагы 42 милли төркемдә 967 бала ана телендә белем һәм тәрбия ала.

Бүген Әлмәт муниципаль районы мәгариф системасы балаларга ана телендә сыйфатлы белем һәм тәрбия бирүче белгечләр белән тәэмин ителгән. Мөгаллимнәр квалификацияләрен даими күтәреп тора, республика һәм башка төбәк югары уку йортлары галимнәре белән тыгыз элемтәдә эшли, региональ, федераль бәйгеләрдә, фәнни-гамәли конференцияләрдә, семинарларда чыгыш ясап, һөнәри осталыкларын арттыра.

2010 елның 1 сентябреннән Мәгариф үсеше федераль проекты кысаларында, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы карары нигезендә, Татарстан Республикасында «Күпмәдәниятле мәгариф үсеше концепциясе» таләпләренә җавап бирергә тиешле эксперименталь укыту-методик комплектларын (УМК) сынау районыбызның 5 мәктәбендә (1, 15, Габдрахман, Яңа Нәдер гомумүстерешле мәктәпләре, 1 нче гимназия) башкарыла, бүген Федераль эксперимент дәвам итә.

Белем бирү учреждениеләрендәге заманча җиһазландырылган татар теле һәм әдәбияты кабинетында укучылар туган телебезне һәм әдәбиятыбызны өйрәнә. Кабинетлар ел саен методик кулланмалар, программалар, уку һәм күрсәтмә әсбаплар, матур әдәбият әсәрләре белән тулыландырыла. Төрле чаралар аша балаларда туган телгә, туган җиргә мәхәббәт хисләре тәрбияләнә: ел дәвамында Әлмәт язучылар оешмасы әгъзалары белән очрашулар, Әлмәт татар дәүләт драма театрына экскурсияләр үткәрелә, милли-мәдәни атналыклар уздырыла, Туган тел көне кысаларында ана телендә шигырь бәйгеләре үтә. Болар барысы да массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртыла.

Мәгърифәтче-галим, якташыбыз Р.Фәхреддиннең шәхесе, энциклопедик эшчәнлеге, бәһасе алтынга тиң хезмәтләре бүгенге көнебез өчен дә гаять әһәмиятле. Балалар бакчасында, мәктәпләрдә галимнең хезмәтләре өйрәнелә, укыту-тәрбия эшендә киң кулланыла. Әлмәт шәһәренең 47 нче «Энҗе бөртеге» балалар бакчасы, мәгърифәтченең педагогик мирасын файдаланып, үсеп килүче буынны укыту һәм тәрбияләүдә югары нәтиҗәләргә ирешкәне өчен, Ризаэддин Фәхреддин исемендәге премия һәм диплом белән бүләкләнде.

Быел «Киләчәк — Будущее» республика программасы кысаларында, Татарстанның ике меңләп балалар бакчасында сабыйларның татар һәм рус телләрен ничек өйрәнүләре тикшерелде. 20 республика балалар бакчасы арасында 1 миллион сумлык Грантка шәһәребезнең 33 нче «Күк чәчәк» автономияле катнаш төрдәге балалар бакчасы да лаек булды.

Бүгенге катлаулы тормышта милләтләр дуслыгы, алар арасындагы мәдәни бәйләнешләр, көнкүреш мөнәсәбәтләре беренче планга куела. Шуны истә тотып, хакимият, мәгариф идарәсе төбәгебездә яшәүче һәр милләт вәкиленә үз тарихын өйрәнү, мәдәниятен, мәгарифен үсте-

рү өчен тиешле шартлар тудыра. Районыбызда таҗик, үзбәк, кырггыз, азәрбайҗан, әрмән, дагыстан, мордва, чуваш диаспораларының милли-мәдәни эшчәнлекләре оештырылган. Мәгариф учреждениеләрендә якшәмбе мәктәпләре челтәре булдырылды. 16 нчы мәктәп базасында — әрмән, Васильевка мәктәбе базасында мордва укучылары үз телләрен һәм гореф-гадәтләрен өйрәнә. Балалар бакчаларында һәм мәктәпләрдә диаспора вәкилләре белән әһәмиятле чаралар уздырыла.

Мәгариф өлкәсендә Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребезгә дә методик ярдәм итеп торабыз. «Төбәкара хезмәттәшлек планы» нигезендә, Оренбург өлкәсе Абдуллин районы мәгариф учреждениеләре белән элемтә урнаштырылды.

Сәләтле балалар — җәмгыятебезнең иң кадерле өлеше. Әлмәт муниципаль районы мәгариф системасында сәләтле яшьләрне эзләп табу, аларга ярдәм итү буенча нәтиҗәле эш системасы булдырылды: сәләтле балалар турында мәгълүматлар банкы тупланган, укучылар санына пропорциональ рәвештә ул ел саен үсә бара. Киләчәктә районыбызда сәләтле балалар өчен махсус белем бирү учреждениесе сафка

басар, анда милли тәрбия һәм белем бирү өстенлекле юнәлешләрнең берсе булыр дип өметләнәбез.

Мәгариф системасы тарафыннан милли тәрбия бирү буенча бөтен шартлар тудырылган, милли төркемнәр, класслар ачу перспективасы төзелгән, бу өлкәдә максатчан эшләр алып барыла. Иң мөһим бурыч — гаиләдә баланы туган телендә тәрбияләүгә игътибарны арттыру һәм балалар бакчаларында, мәктәптә ана телендә сыйфатлы белем һәм тәрбия бирү. Бердәм булып, бер максатка омтылып хәрәкәт итсәк кенә, киләчәгебез якты, өметле булыр!

Алты дистә ел эчендә кечкенә генә бер авылдан көчле индустрияле, сәяси һәм икътисади яктан тотрыклы, җырлы-мәдәниятле, милли мирасыбызны кайгыртып яшәүче кара алтын башкаласына әверелгән Әлмәтнең киләчәге дә зур һәм якты булыр дип ышанабыз. Юбилееӊ белән, Әлмәтем!

Гасыр арты туар яңа гасыр.
Гел яшь булып яшәр ак Әлмәт!
Дөрли генә бара күңелләрдә
Ак Әлмәткә туган мәхәббәт! ■

Фотолар Әлмәт муниципаль районы хакимиятенең матбугат үзәге һәм «Альметьевский вестник» газетасы фондларыннан

ТАТАРСТАНДА НЕФТЬ ЧЫГАРА БАШЛАУГА 70 ЕЛ

ШӘФӘГАТЬ ТӘХАВЕТДИНОВ,
«Татнефть» ААҖнең генераль директоры

Кадерле дуслар!

Агымдагы елда без Татарстанда нефть чыганакларын эшкәртә башлауның 70 еллыгын билгеләп үтәбез. Бу тарих берничә буын нефтьчеләрнең — республикабыз нефть сәнәгатен күтәрү өчен илебезнең төрле почмакларыннан килгән эшчеләрнең һәм белгечләрнең, сугыш чорында һәм аннан соңгы авыр елларда үзләре өчен таныш булмаган һөнәрне үзләштергән һәм соңрак җир куеныннан миллиардлаган тонна «кара алтын» чыгарган, компания һәм тармак үсешенең ныклы нигезен булдырган җирле халыкның фидакарь хезмәте белән язылган. Кыю идеяләр, заманча технологияләр һәм алдынгы эш алымнарын гамәлгә кертү буенча республикабыздагы нефть сәнәгате объектларын, чын мәгънәсендә, тәҗрибә мәйданына әверелдергән геологлар һәм бораулаучылар, нефть чыгаручылар һәм галимнәр зур өлеш кертте.

Бүген бу зур тәҗрибәне һәм хезмәт традицияләрен яшь буын нефтьчеләр дәвам итә. Алар алдында да нефтьне тиешле күләмдә рентабельле чыгаруны тотрыклы рәвештә саклау һәм арттыру, ресурс базасын киңәйтү, яңа чыганакларны үзләштерү, инновацион инженер-техник сәясәтне гамәлгә ашыру, чит ил проектларын үстерү буенча катлаулы бурычлар тора.

Вертикаль интегральләшкән холдинг статусында «Татнефть» ААҖ нефтьне һәм газны тотрыклы рәвештә чыгару, эшкәртү һәм сату эшләрен алып бара. Соңгы елларда компания нефть чыгару күләмен елына 26 млн тоннадан артыграк даими саклап килә. Республикабызда нефть чыганаклары эшкәртелә башлаганнан бирле, 3 млрд тоннадан артыграк «кара алтын» чыгарылды, «Татнефть» ААҖнең расланган чимал запаслары агымдагы ел башына 869 млн тонна тәшкил итте.

Нефть җитештерүне киләчәктә дә тотрыклы рәвештә арттыра баруның нигезен үзле «кара алтын» ятмаларын үзләштерүдә күрәбез. Битум чыганакларын эшкәртү Татарстан Республикасы һәм Россия дәүләт органнарының, фәнни оешмаларның даими ярдәме белән гамәлгә ашырыла. Үзләштерелә башлаганнан бирле 260 мең тоннадан артыграк битум чыгарылды.

Компаниянең көндәшлеккә сәләтле булуын һәм икътисади тотрыклылыгын без шулай ук нефть эшкәртү һәм нефть химиясе тармаклары үсеше белән дә бәйлибез. Бу өлкәдә соңгы еллардагы эре проектлар булып шина җитештерүне модернизацияләү, Түбән Камада тоташ металл кордлы яңа буын шина җитештерү заводын төзү тора. «ТАНЕКО» нефть эшкәртү һәм нефть химиясе заводлары комплексын күтәрү буенча проектны гамәлгә ашыру безнең компания өчен аеруча әһәмиятле стратегик мәсьәләгә әверелде. Бүген завод елына 7 млн тонна нефть эшкәртү буенча проект көченә күтәрелде. Чимал эшкәртүне киңәйтү буенча эшләр дәвам итә.

«Татнефть» ААҖнең төп бинасы

«Татнефть» ААҖнең нефть төбәге һәм республиканың социаль-икътисади үсешендә актив катнашуы иң өстенлекле эшчәнлек юнәлешләренең берсе булды һәм шулай булып кала да. Нефть тармагы үсешенең беренче көннәреннән алып нефтьчеләр, җитештерү объектлары белән беррәттән, шәһәр һәм посёлоклар төзеде. Быел нефть «тудырган» шәһәрләрнең берсенә — Әлмәткә — 60 ел. «Татнефть» нефтьчеләр башкаласында һәм әлеге төбәктәге башка шәһәрләрдә торак йортлар, мәктәпләр, сәламәтлек саклау, мәдәният, спорт корылмалары төзүгә зур өлеш кертә.

Татарстан нефтенең 70 еллыгын билгеләп үткән көннәрдә Россия һәм республика җитәкчелегенә тармак алдында торган мәсьәләләргә игътибарлы һәм безнең эшчәнлегебезгә даими терәк булган өчен, рәхмәтебезне җиткерәбез. Без шулай ук «Татнефть» компанияләр төркеменә керүче барлык хезмәт коллективларына да фидакарь хезмәтләре, сайлаган һөнәрләренә тугрылыклы булулары өчен зур рәхмәтле.

«Татнефть» ААҖ белән хезмәттәшлек итә торган сервис предприятиеләре хезмәткәрләре, безнең белән бергә булган, нефть чыгарырга, туган төбәгебезне төзекләндерүгә-матурайтуга ярдәм иткән төрле һөнәр ияләре — төзүчеләр, укытучылар, табиблар, авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре — иң җылы мактау сүзләренә лаек. Без компаниядә тупланган фәнни, интеллектуаль һәм җитештерү потенциалы киләчәктә дә төбәк халкының тормыш шартларын яхшыртуга, республикабызның һәм илебезнең чәчәк атуына хезмәт итәр дип ышанабыз. ■

Нефтьүткәргеч төзү, 1960 ел

ФОТОЛАРДА – ТАТАРСТАН НЕФТЬЧЕЛӘРЕНЕҢ ХЕЗМӘТ БАТЫРЛЫГЫ

Хезмәт урынында – производство инструктажы

Скважина ремонтлау.
Фоторәсемдә – Дәүләт премиясе лауреаты, яшьләрнең остазы Л.Фурштатов (сулда)



Нефть чыгару. 1960 еллар

Скважиналарны капиталь төзекләндерү бригадасы. 1960 ел

Фотолар «Татнефть» ААҖнең матбугат үзәге фондыннан

XVIII ГАСЫРДА ӘЛМӘТ ТӨБӘГЕ ҺӘМ ӘЛМӘТ АВЫЛЫ ТАРИХЫННАН

АЙДАР НОГМАНОВ,
тарих фәннәре кандидаты, Татар энциклопедиясе институтының Татарстан Республикасындагы һәм татарлар күпләп яшәгән чит төбәкләрдәге торак пунктлар тарихы бүлегенең мөдире

ТАТАРСТАННЫҢ НЕФТЬ БАШКАЛАСЫ БУЛГАН ӘЛМӘТНЕҢ XVIII ГАСЫРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫСЫНДАГЫ ТАРИХЫ РЕСПУБЛИКАНЫҢ КӨНЬЯК-КӨНЧЫГЫШЫНДА НИГЕЗ САЛЫНГАН ДИСТӘЛӘГӘН АВЫЛЛАР ЯЗМЫШЫ БЕЛӘН ОХШАШ.

Төбәктә XVIII гасырда торак пунктлары барлыкка килү Көнчыгыш Чулман аръягына күченүләр белән бәйләнгән. Бу вакытка кадәр хәзерге Сарман районының көньягында утрак тормышлы халык даими яшәмәгән диярлек. Зәй, Шушма, Кичү елгалары буендагы мәйданнар 1630 елларга кадәр нугайларның көтүләре өчен җәйләү «коридоры» булып хезмәт иткән. Көннәр җылыта башлагач, алар көньякка, Каспий диңгезенә таба күченгәннәр. Нугайлар, көтүләр белән Иделнең сулъяк яры буйлап Чулманга таба хәрәкәт иткәндә, даими рәвештә рус дәүләтенең көньяктагы чик буе районнарына һөҗүм ясап торган. Шул сәбәпле биредә яшәү өчен тыныч шартлар булмаган. Ул вакытларда кешеләр яшәгән дип фаразласак та, алар, урман эчендәге кечкенә елга һәм инешләр буена урнашып, берничә гаиләдән торган кабиләләр берләшмәсен генә тәшкил иткән. Тыныч елларда зур елга үзәннәренә чыкканнар, тирә-юньдәге җир-суларны файдаланганнар, әмма төп тору урыннары — кышлаклары — үтеп керергә авыр караңгы урман эчендә яшеренгән.

Меңнәрчә кешеләрнең гомерләрен өзгән ваба афәтеннән соң көчсезләнеп калган нугайларны XVII гасырның 30-40 нчы елларында Идел аръягы далаларына көнчыгыштан килгән калмыклар кысрыклаган. Әмма 1650 елларда калмыклар ирекле рәвештә рус дәүләте составына керә һәм Идел, Җаек елгаларының түбән агымнары буена урнаша. Нәтиҗәдә, Татарстанның көньяк-көнчыгышы Чулман аръягында яшәүче ыру-кабиләләрнең уртак биләмәсенә әверелә.

Бу җирләрнең беренче хуҗалары Уфа өязенең Казан даругасы Байлар һәм Юрма волостьларында яшәүчеләр булган дип фаразлана (хәзерге Татарстанның Минзәлә һәм аңа чиктәш район җирләре). Мондый фикер XVIII гасыр документларында теркәлгән Байлар һәм Юрма волостьларында яшәүчеләрнең әлеге территорияләрне вотчина, ягъни ата-бабалар җире дип үзләренә беркетергә омтылышларына нигезләнә. Әмма калмыкларның һөҗүм итү куркынычы сакланган шартларда, күрәсең, алар биредә даими рәвештә яшәмәгән, Дала Зәе елгасының югары агымында урнашкан җирләргә вакыты-вакыты белән килеп-китеп йөргәннәр.

XVIII гасырның беренче дистә елларында хәзерге Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарын хуҗалык ягыннан үзләштерүдә тамырдан үзгәрешләр күзәтелә. Пётр I идарә иткән чорда гади халыктан акча җыюларның, салымнарның һәм төрле дәүләт йөкләмәләренең кинәт артуы нәтиҗәсендә, игенчеләрнең икътисади хәле кискен начарланып, бирегә Урта Идел буеннан крестьяннар күченә башлаган. Кагыйдә буларак, алар елга үзәннәре буена зур булмаган авылларга нигез салган. 1719 елгы беренче ревизия материалларында хәзерге Әлмәт районы җирләрендә Аппак, Баграж-Никольское, Бута, Югары Акташ, Добромыш, Зәй чишмәсе, Илтән-Бута, Кузкәй, Кече Баграж, Рус Акташы, Ямаш авыллары теркәлгән. Шулай итеп, Әлмәттән көнбатышка һәм төньяк-көнбатышка таба урнашкан җирләр XVIII гасыр башында хуҗаларын тапкан.

Кайбер чыганаклар Әлмәт авылына 1710-1720 еллар аралыгында нигез салынган дип уйларга мөмкинлек бирә. 1840 елда сораштыру үткәргәндә, әлмәтлеләр хөкүмәт вәкилләренә авылның «121 ел элек», ягъни 1719 елда барлыкка килүе турында әйтәләр. Әлмәт авылында беренче ревизиянең халык санын исәпкә алу вакытында узганлыгы шик уятмый, әмма ул ниндидер сәбәпләр аркасында рәсми теркәлми калган. Бу авылга кадәр җан исәбен алучылар барып җитмәгән (махсус килмәгән булырга да мөмкин) яки авылда яшәүчеләр, Пётр Iнең 1719 елның 22 гыйнварында чыгарган әмере нигезендә, халык санын исәпкә алуга кертелми торган төркем вәкилләре булганнар (башкортлар, уфа татарлары, ясаклы инородецлар һ.б.).

Язма чыганакларда Әлмәт авылы беренче тапкыр Урал буенда яшәгән халыкларның 1735-1740 елларда бөтен Көнчыгыш Кама аръягын чолгап алган баш күтәрүенә бәйле вакыйгалар уңаеннан телгә алына. Ул чор документлары арасында Әлмәт исемле Нәдер волосте мулласының полковник И.Н.Татищевка баш күтәрүчеләрнең җыеннары, ниятләре һәм Нәдер волосте халкына алардан янаган куркыныч турындагы хаты сакланган. Хат 1735 елның 24 июнь көнне язылган һәм: «Бу хатны мин, Зәй ягындагы Әлмәт авылыннан Әлмәт мулла, яздым», — дигән сүзләр белән тәмамлана. Һичшиксез, документта сүз нәкъ менә Әлмәт авылы турында бара, чөнки бу вакыйгалардан алдарак та, соңрак та Дала Зәе елгасы һәм аның кушылдыклары буенда мондый исемле авыл теркәлмәгән.

Хат авторының исеме авыл атамасының килеп чыгышы турындагы серне дә ача. Көнчыгыш Чулман аръягы авыллары тарихында татар авылларының топонимнары аларга нигез салучы кеше исеменнән, рус авылларыныкы алпавыт исеменнән килеп чыкканлыгына шактый күп мисаллар китерергә мөмкин. Күрәсең, Әлмәт мулла белән дә шулай булган. XVIII-XIX гасырларда Әлмәт авылының икенче исеме очраклы гына Әлмәт-мулла дип аталмагандыр. 1746 елгы халык санын алу вакытында, Әлмәт авылында 49 яшьлек (ягъни 1697 елда туган) Сәет угылы Әлмәт исемле бер генә кеше теркәлгән. 1735 елда, хат язган вакытта, аңа якынча 38 яшь, ә 1720 елда 23 яшь була, ягъни ул, туган

җирләрен ташлап, яңа урында нигез корырга сәләтле яшьтә булган.

1740 елларда Әлмәт тормышында зур үзгәрешләр башлана. Аңа кадәр ун ел дәвамында Яңа Чулман аръягы чик буе хәрби ныгытмалар системасы төзелә. Әмма тиздән алар Самара һәм Җаек елгалары буенда төзелгән ныгытмалар карамагында кала һәм үзенә йөкләтелгән хәрби вазифаны үтәми башлый. Шулай да әлеге ныгытмалар Татарстанның көньяк районнарына кешеләр күченү өчен җирлек тудыра. 1731-1736 елларда чик буе ныгытмаларын торгызган вакытта, бирегә халык күпләп агыла, дистәләгән торак пунктлар барлыкка килә. Алар арасында Чирмешән елгасы буендагы Чирмешән ныгытмасы (хәзерге Чирмешән районының Чирмешән авылы), Шушма елгасы буендагы Шушма (шул ук райондагы Шушма Крепосте авылы), Кичү елгасы буендагы Кичү фельдшанецлары (хәзерге Әлмәт районының Кичү авылында) бар. Бу авылларга XVII гасырның 50 нче елларында төзелгән Иске Чулман аръягы чик буе хәрби ныгытмаларыннан (Иске Шушма, Яңа Шушма, Зәй һ.б.) күчерелгән йомышлы кешеләр нигез сала.

1730 елларның икенче яртысында хакимият Чулман аръягы җирләренә авыру яки яралану сәбәпле отставкага чыккан солдатларны һәм унтер-офицерларны күчерергә дигән карар чыгара. Бу планны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә, Яңа Чулман аръягы чик буе ныгытмаларыннан көньяк-көнчыгышта отставкадагы солдатларның Кече Бөгелмә, Бөгелмә, Куак һәм Печмән бистәләре барлыкка килә. Әмма Чулман аръягы киңлекләрен үзләштерер өчен, хәрбиләрнең күченүе генә җитмәгән. 1740 еллар башында Оренбург белән Казан, Мәскәү һәм Семберне тоташтыручы Яңа Мәскәү юлы (соңрак Казан тракты дип атала) салына башлый. Оренбург экспедициясе җитәкчелеге теләктәшлеге белән, салым түләүчеләргә ихтыяҗ булганлыктан, юл буйлары беренче чиратта, крестьяннарга бирелә. Бу төбәкләргә Сембер, Пенза, Казан, Түбән Новгород, Касыйм һәм башка өязләрдән крестьяннар күчеп килгән. Аларны җәлеп итәр өчен, бер елдан алып өч елга кадәр төрле түләүләрдән һәм салымнардан азат итү кебек ташламалар каралган.

Әлеге чаралар үз ролен уйнаган, әлбәттә. 1743 елда Яңа Мәскәү юлы янәшәсендә 12 яңа авылга нигез салына. Күченеп килүчеләр хисабына юл буена урнашкан авылларда, шул исәптән Әлмәттә дә, халык саны арта. Икенче ревизия чоры документларында (1746 ел) биредә 62 ир-ат теркәлә, алар арасында Нугай даругасының Мишәтамак һәм Селәнгеш авылларыннан, Казан өязе Алат даругасының Ташкичү һәм Тазлар авылларыннан (хәзерге Татарстан Республикасының Питрәч һәм Арча районнары) килүчеләр дә булган.

1744 елда Оренбург губернасы оешу белән, Көнчыгыш Чулман аръягындагы авыллар билгеле бер админстратив үзәккә беркетелә. Башта алар 1720-1740 елларда патша хакимиятеннән Дала Зәе, Кичү, Шушма, Сок елгалары буенда киң җир биләмәләре алган башкорт старшинасы Нәдер Уразмәтов исеме белән аталган Нәдер волосте составында хисаплана. Күп кенә документларда волость Уфа өязе Казан даругасының бер кисәге итеп карала. 1740 елларда Оренбургтан алып Казан губернасы чигендәге Кичү фельдшанецына кадәрге Яңа Мәскәү юлы буендагы җирләр Оренбург өязенең бер өлешен тәшкил иткән Бөгелмә идарәчелеге составына кертелә. Яңа админстратив берәмлекнең үзәге — Бөгелмә бистәсе (булачак Бөгелмә шәһәре).

Крестьяннарның күпләп агылуына карамастан, хакимият Яңа Мәскәү юлы буена халыкны күчерер өчен административ чаралар да күрә. 1747 елда бирегә Уфа өязеннән 1717 җан «качаклар» дип аталган (ягъни Уфа өязенә башка җирләрдән качып килгән) ясаклы крестьян күчерелә. Моннан тыш

Уфа провинциясенең генераль картасы. Төзүче – И.Красильников. 1755 ел
Иллюстрация «Әлмәт — Альметьевск» китабыннан

бирегә яңа чукынган авыллардан да халык килеп төпләнә. 1753 елда Яңа Мәскәү юлы буендагы авылларда 2964 җан ир-ат җенесендәге дәүләт крестьяннары хисаплана. Күчеп килүчеләрнең бер өлеше почта трактыннан ерак булмаган җирләргә төпләнә һәм аерым сословие формалаштыра. Ревизская сказка һәм башка рәсми документларда аларны «ям чабучы» яки «чемодан татарлар» дип атыйлар. Дәүләт алардан Яңа Мәскәү юлы буенча хакимият курьерларын һәм йөкләрен йөртүне тәэмин итү вазифаларын башкарта.

Юлның беренче схемасы Түбән Новгород полкы капитаны Ляхов тарафыннан 1751 елда төзелгән картада теркәлеп калган. Ул Нәдер Уразмәтов картасы буларак билгеле, чөнки, аның үтенече буенча, картада Нәдер волосте планы күрсәтелгән. Карта беренче мәртәбә Әлмәт авылы урнашу урынының билгеләнүе белән әһәмиятле, әмма ниндидер сәбәпләр аркасында ул «Махтама авылы» дип язылган. Капитан Ляховның хатасын картада, бүген дә шул төбәктәге Югары һәм Түбән Мактама авыллары һәм Махтама (Әлмәт) янәшәсендә генә урнашкан, 1950 елларда Әлмәт шәһәре составына кергән Бигәш авылы күрсәтелүе дәлилли. Алга таба бу төгәлсезлек төзәтелә һәм 1755 елда прапорщик Иван Красильников геодезиясе тарафыннан төзелгән «Оренбург губернасы атласы»ннан башлап 1950 елларга кадәрге барлык географик карталарда да Әлмәт (Әлмәт-мулла) топонимы күрсәтелә.

Яңа Мәскәү юлы салыну Чулман аръягы икътисадына уңай йогынты ясый. Төбәк тиз арада үсә башлый. Күченеп килгән халыкның (рус, татар, мишәр, чуваш, мари, удмурт, мордва) төп шөгыле игенчелек булган. Крестьяннар интенсив рәвештә Дала Зәе, Шушма, Кичү, Урсала елгалары буендагы уңдырышлы болын-тугайларны үзләштергән. Бу чорда хуҗалык эшләре өчен зур масштабларда урман кисү, мөгаен, юк дәрәҗәсендә була. Иң

киң таралган игенчелек коралы сука булган, урыны белән (аеруча татарларда) авыр агач сабан файдаланылган. XVIII гасырның икенче яртысыннан алып авыл хуҗалыгы продукцияләре, барыннан да бигрәк арыш, бодай үстерү төбәкнең икътисади нигезенә әверелә. 1764 елгы Оренбург губернасы канцеляриясе ведомостьларыннан Бөгелмә идарәчелегенең Яңа Мәскәү юлы буендагы авылларында 53 су һәм 74 чыгыр тегермәне теркәлә. Татар крестьяннары бу тегермәннәрдә тарткан икмәкне, нигездә, үзләренең ихтыяҗлары өчен тоткан. Кырыс табигать шартлары крестьян хуҗалыкларында төп иген культуралары буларак солы, арыш һәм борай чәчүне таләп итә. Үзләренә кулланырга зур булмаган күләмдә арпа, борчак, мәк һәм тары игкәннәр. Хуҗалык ихтыяҗлары өчен киндер үстерелгән. Аның орлыгыннан май ясалган, ә сабаклары бау үрү өчен яраган. Шул чордагы чыганакларга караганда, XVIII гасыр азагына уртача һәрбер ун елның бары тик ике елында гына иген мул уңган.

XVIII гасыр башында тау сәнәгате заводлары барлыкка килү төбәк хуҗалыгы тормышында мөһим вакыйга булып тора. Тау заводлары төзелүнең иң актив вакыты 1750-1760 елларга туры килә. Бу дәвердә Бөгелмә идарәчелеге территориясендәге Кичү елгасы буенда (хәзерге Әлмәт районының Кичү авылы янында) Сембер сәүдәгәре Г.И.Глазов тарафыннан Богословски бакыр эретү заводы төзелә. Ул завод өчен җирне 1756 елның июнендә Нәдер волосте Иске Нәдер авылы татарларыннан сатып ала. Сәнәгать оешмасы 1759 елның февраленнән эшли башлый, аның 4 миче уңышлы елларда 1100 потка кадәр бакыр эретә алган. Завод карамагында күп санда рудниклар һәм приискалар урнаша. Анда Глазовларның крепостной крестьяннары һәм ирекле ялланган кешеләр тир түккән. 1768 елда заводта — 266, 1815 елда — 263, 1850 елда 455 ир-ат эшләве мәгълүм.

Тау заводлары үсешенә бәйле күп кенә тармаклар алга киткән. Хуҗалык ихтыяҗлары өчен күпләп урман кисү башланган. Агач күмере бакыр эретү мичләре өчен төп ягулык чималы булган, шулай ук агачтан буалар һәм төрле сәнәгать корылмалары төзегәннәр. Көлдән пыяла, буяу ясау һәм тире иләү өчен поташ алынган. XVIII гасырның 50 нче елларына Нәдер Уразмәтов тарафыннан Көнчыгыш Чулман аръягында беренче мәртәбә нефть чыгару омтылышы ясала.

1754 елда Нәдер Уразмәтов, улы Йосыф һәм шөрәкәләре А., Х.Мәҗәковлар белән Оренбург губернасы канцеляриясенә «үзенең Уфа өязе Казан даругасы Сок елгасы буенда урнашкан биләмәсендә» нефть заводы төзергә рөхсәт итүне үтенеп гариза яза. Аның тарафыннан җибәрелгән нефть пробасы бергпробингер Г.И.Леманов тарафыннан анализлана. 60 мыскал (1 мыскал — 4,266 грамм) пробадан 14 мыскал бензин, 28,5 мыскал керосин һәм 14,5 мыскал мазут алына. 1754 елның 16 июнендә Берг-коллегия «Казан даругасы башкортлары старшина Уразмәтов белән аның улына» нефть заводы төзергә рөхсәт бирә. 1755 елда «иң кирәк очракларда гына нефть кайнатыр өчен» амбар төзелә, әмма Н.Уразмәтовның авыруы сәбәпле, завод килешенгән вакытка сафка басмый. 1757 елда Оренбург тау эшләре начальнигы, төзелеп бетмәгән заводны тикшереп, шөрәкәләрне нефть чыгару хокукыннан мәхрүм итә. Шуңа да карамастан, нәкъ менә Нәдер Уразмәтов барлык Идел-Урал буенда нефть чыгару эшен башлап җибәрүче булып санала.

Бөгелмә идарәчелеге халкы Яңа Мәскәү юлында да хезмәт иткән. Бу юл почта өчен генә түгел, ә сәүдә өчен дә менә дигән урын булган. Ямчылык хезмәтен башкару җирле халыктан зур матди чыгымнар да таләп иткән. Шуның өстенә алар дәүләт крестьяннарына йөкләтелә торган башка вазифаларны да башкарган, салымнар да җыйган. Күп кенә мөрәҗәгатьләрдән соң, 1757 елның 6 июнендәге Сенат

указы нигезендә Яңа Мәскәү юлы буенда урнашкан авылларда яшәүче татарлар рекрут йөкләмәсеннән азат ителә, әмма почта һәм хакимият курьерларын бушлай ат белән тәэмин итү мәҗбүрияте сакланып кала. Кагыйдә буенча, һәр 28 ир 3 ат бирергә тиеш була.

1757 елда «чемодан татарлар»ның (ир-атлар) саны 2001не тәшкил итә. Алар Оренбургтан алып Казан губернасы чикләренә кадәрге 16 (кайбер мәгълүматлар буенча — 14) почта станциясендә теркәлгән. XVIII гасырның 50 нче елларында бу маршрут буенча сәяхәт итүчеләр Бөгелмә идарәчелегенең бер үк вакытта почта станциясе булган (хәзерге ТР территориясендәге) Кандыз, Димскәй, Исхак, Кече Бөгелмә бистәсе, Карабаш, Тайсуган, Түбән Мактама, Әлмәт, Бигәш, Колшәрип, Иске Нәдер, Кичү фельдшанецы торак пунктлары аша узган.

Әлмәт авылында да, Бөгелмә идарәчелегенең башка авылларындагы кебек үк, ямчы татарлар бишенче ревизиядән башлап (1795 ел) аерым теркәлә башлый (162 ир-ат һәм хатын-кыз хисапланган). Элеккеге халык санын алу материалларында алар ясаклы татарлар составында күрсәтелгән. Әлмәттән кала, ямчы татарлар хәзерге Әлмәт районының Габдрахман, Бигәш, Югары Мактама, Кама-Исмәгыйль, Кичүчат, Колшәрип, Миңлебай, Яңа Кәшер, Яңа Нәдер, Сөләй, Тайсуган авылларында да яшәгән. 1829 елда ямчы татарлар дәүләт крестьяннары сословиесе составына кертелә. Алар ямчылык йөкләмәсеннән азат ителә, әмма яңадан дәүләткә рекрутлар бирергә тиеш була.

XVIII гасырда ямчы татарлар Әлмәт авылы халкының бер өлешен генә тәшкил иткән. 1795 елда халык санын исәпкә алганда, биредә 328 ир-ат һәм хатын-кыз типтәр, 99 башкорт, 78 ясаклы татар, 33 чукынган татар, 7 удел крестьяны һәм бер отставкадагы солдат яшәгәнлеге теркәлгән. Феодаль йөкләмәләрне үтәү, салымнарны түләү һәм җәмәгать эшләрен башкару кебек гамәлләрдә алар бер-берсеннән, дәүләт каршында статуслары төрле булу сәбәпле, нык аерылып торган.

Халык санын исәпкә алу документларында күрсәтелгән категорияләрнең төрлелеге Әлмәттә җирле халыкның акрынлап һәм төрле юллар белән формалашканлыгын күрсәтә. Биредә Әлмәткә нигез салучы Әлмәт Сәет угылының типтәр сословиесенә нисбәтле икәнлеген дә әйтергә кирәк. Тарихи мәгълүматларга караганда, ясаклы татарлар, югарыда телгә алынган Казан өязе авылларыннан кала, Сембер өязе Норлат, Пенза өязе Кандыз, Зөя өязе Әҗем авылларыннан да күчеп килгәннәр.

XVIII гасырның соңгы унъеллыгында Әлмәт авылында «башкортлар» пәйда була. Татарстан Республикасының Минзәлә, Актаныш, Азнакай, Мөслим, Сарман, Баулы һәм башка районнарының XVI-XVII гасырларга караган тарихи чыганакларында еш кына «башкорт», «башкорт волосте», «башкорт җирләре» дигән төшенчәләр очрый. Әмма болар хәзерге башкортларның ата-бабалары түгел. XVI гасырның урталарында «Башкорт иле» исеме белән Казан ханлыгы яулап алынган вакытта рус армиясе барып җитмәгән территорияне атаганнар. Күрәсең, аның көнбатыш чикләре Русия хакимиятенә шунда ук буйсынган җирбиләүчеләрнең территорияләреннән башланган. Болар — Чулман елгасының урта һәм Агыйделнең түбән агымы буйларында яшәгән гайнә, уран, бүләр, байлар, ирыкты, кара табын һәм танып кабиләләре. Аларның барысын да һәм болардан көнчыгышта — Урал сыртының ике як итәгенә урнашкан кабилә берләшмәләрен руслар «башкортлар» дип атап йөртә башлаган.

Исемнән кала, «башкортлар»ны Русия хакимиятенә ирекле рәвештә кушылганнан соң билгеләнгән шактый югары социаль дәрәҗә дә берләштергән. Патша хакимиятеннән алынган иң төп өстенлекне вотчина (җәмгыять) җирләренә ия булу хокукы биргән.

Моннан тыш Мәскәү хакимияте «башкортлар»ның эчке эшләренә тыкшынмау, диннәренә кагылмау, җирле халыкның гореф-гадәтләрен саклау, хакимиятне җирле кабилә түрәләренә калдыру турында вәгъдә иткән. XVII гасырда «башкорт» термины, сословие белдерүдән кала, территориаль эчтәлеккә дә ия була. Бу исем астында Уфа өязе халыклары да атала башлый. Бирегә, нигездә, Урта Идел буеннан килгән төрле социаль төркемнәр (ясаклы татарлар, типтәрләр, бобыльләр) нинди юллар белән булса да башкорт сословиесенә керергә, ягъни җир һәм салымнар мәсьәләсендә «башкортлар» кебек өстенлек алырга омтылган. Кагыйдә буларак, әлеге төркем вәкилләренең «башкорт исеме астына» керү турындагы үтенечләрен патша хакимияте канәгатьләндерә килгән. Бу очракта гозер бирүчеләрнең нинди этник төркемгә караулары мөһим роль уйнамаган. Татарстанның көнчыгыш районнарына караган XVIII гасыр документларында «башкортлар» исеме белән еш кына татарлар, чувашлар һәм марилар йөргән. Әлмәт авылындагы «башкортлар» белән дә шундый ук хәл күзәтелә.

Чукынган татарлар Әлмәттә 1790 елда гына күренә башлый. Керәшен татарлары бирегә үзләре яшәгән Зәй-Чишмә авылының тирә-ягындагы Уфа өязе Казан даругасы Бүләр волосте башкортларына караган җирләр «мәңгелеккә һәм нәсел-нәсәп карамагына» секунд-майор Дмитрий Александрович Чирковка сатылганнан соң күченә. Бу шул чор өчен гадәти күренеш булган. Мәсәлән, 1780 елларда шундый ук юл белән граф К.А.Разумовский һәм А.П.Петров-Солово Дала Зәе буендагы зур җир биләмәләренең хуҗаларына әйләнә.

Әлмәт авылына күченгән керәшен татарлары анда элек-электән яшәгән мөселманнарга шактый сизелерлек тискәре йогынты ясаган булырга мөмкин. 1795 елда халык хисабын алганда, авылда мәчет теркәлгән. Россия империясе законы буенча, мәчетләр төзү мөселманнар һәм христианнар бергә яшәгән авылларда тыелган була. Шунлыктан Әлмәткә керәшен татарларының күченүе биредәге мәчетне юкка чыгару куркынычы тудырган. Бу хәл Әби патша (Екатерина II (1762-1796 еллар)), хакимияткә килеп, самодержавиенең дин сәясәтенә берникадәр йомшарулар кертүе сәбәпле генә булмый кала.

XVIII гасыр дәвамында Әлмәт авылы тарихында шактый кызыклы яңалыклар күзәтелә. Уңайлы географик урынга — Россиянең Европа өлешеннән казах далаларына бара торган транзит юл өстенә — урнашу халыкны төрле тарихи вакыйгаларның шаһиты ясый. 1760-1770 елларда Көнчыгыш Чулман аръягының көньяк районнары аша Петербург Фәннәр академиясе тарафыннан оештырылган «Академик экспедицияләр» маршруты уза. Экспедицияләрнең төп максаты төрле төбәкләрне, аеруча Урал, Урал буе, Алтай, Урта һәм Түбән Идел буйларын өйрәнү була. Сәяхәтчеләр Россиянең табигатен, хуҗалыгын, халкының мәдәниятен һәм көнкүрешен тикшергән. Аерым районнарның икътисади торышын, агротехника дәрәҗәсен, авыл хуҗалыгының үсеш перспективаларын, урманчылык, балык тоту тармагын һәм һөнәрчелекне анализлауга аеруча зур әһәмият бирелгән. Шулай ук металлургия, тау-руда заводларының техник-икътисади торышы да игътибарга алынган, халык мәгарифе, медицина хезмәте күрсәтелү һәм этнографик материаллар хакында да мәгълүматлар җыелган.

Тукталу урыннарына карап, өч Академик сәфәр «Оренбург экспедицияләре» дип атала. Аны П.С.Паллас, И.И.Лепёхин, И.И.Фальк кебек мәшһүр галимнәр җитәкләгән. Көнчыгыш Чулман аръягы территориясе аша И.И.Лепёхин һәм П.С.Паллас, шулай ук аның ярдәмчесе, танылган тарихчы һәм географның улы Н.П.Рычков оештырган экспедицияләр маршруты узган. П.С.Палласның юлъязмасында хәзерге

Әлмәт районы җирләрендә булуы турында мәгълүмат теркәлеп калган. 1768 елның 3 октябрендә экспедициядә катнашучылар Кичү фельдшанецына килеп җитә. Паллас сәүдәгәр Г.И.Глазовның фельдшанец янындагы бакыр эретү заводында була һәм тасвирлап язып калдыра. Танылган академик һәм аның юлдашлары 1768 елның 4 октябрендә Бигәш, Әлмәт, Карабаш авыллары аша узып, шул ук көнне кичкә таба Бөгелмә бистәсенә барып җитәләр. Анда төн кунып, икенче көндә Паллас Спасс авылына бара һәм анда 11 октябрьгә кадәр П.И.Рычковта кунакта була. Палласның экспедициясе Спасс авылыннан киткәннән соң, Димскәй елгасы аша Татар Димскәе авылы янына барып чыга һәм Сок елгасының югары агымына таба юнәлә. И.И.Лепёхин кебек үк, Паллас та Чуваш Семёново һәм Камышлы авыллары янында табигый рәвештә нефть агып яткан урыннарны карый, нефть чишмәләрен һәм табылган нефтьнең җирле крестьяннар тарафыннан ничек файдаланылганлыгын сурәтли. Бу мәгълүматлар 1773-1788 елларда өч кисәктә дөнья күргән «Россия империясенең төрле провинцияләре буенча сәяхәт» исемле хезмәттә системалаштырыла. П.С.Паллас экспедициясенең иң мөһим нәтиҗәләреннән берсе — махсус әдәбиятта беренче мәртәбә (Н.П.Рычков белән) Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгының тасвирлануы.

1773-1775 елларда Әлмәт авылы, Бөгелмә идарәчелегенең башка авыллары кебек үк, Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге крестьяннар баш күтәрүендә катнаша. Баш күтәрүнең беренче чорында (1773 ел, сентябрь — 1774 ел, апрель) Чулман аръягының көньяк-көнчыгышы хәвефнең үзәгендә кала. Казан һәм Оренбург губерналары чигендәге Кичү фельдшанецы баш күтәрүчеләргә каршы 1773 елның октябрендә җибәрелгән хөкүмәт гаскәрләренең туплану урынына әйләнә. Баш командир итеп билгеләнгән генерал-майор В.А.Кар, 1773 елның 31 октябрендә бу урыннан императрицага 500 җәяүле һәм 800гә якын атлы ясаклы татарлардан торган кораллы көчләрне үзенең сафына кушуы турында яза. В.А.Карның корпусы Кичү фельдшанецыннан ноябрь башында чыга һәм яңа Мәскәү юлы буенча горур атлап Оренбургка таба юнәлә. Әмма 7-8 ноябрьләрдә Оренбургтан төньяк-көнбатыш юнәлештә урнашкан Йөзәй авылы янындагы сугышта җиңелә.

Хакимият гаскәренең Яңа Мәскәү юлы буенча даими хәрәкәтләнүенә дә карамастан, кыш башына Бөгелмә идарәчелеге территориясендә унлап баш күтәрүчеләр отряды булган. Аларның саны 15 мең кеше хисапланган, отрядларның 30 пушкасы булуы мәгълүм. Муса Мостафин, Гавриил Давыдов, Осип Енгалычев, Тимербулат һәм Ает Уразмәтовлар отрядлары иң зурлардан саналган. 1773 елның ноябрь-декабрь айларында Чулман аръягының көньяк-көнчыгыш өлеше тулысы белән баш күтәрүчеләр кулына күчкән. В.А.Кардан соң хәрби җитәкче итеп билгеләнгән генерал Ф.Ю.Фрейман, Бөгелмәдә урнашып, хөкүмәт гаскәрләренең калдыклары тупланган башка шәһәр һәм ныгытмалардан тулаем аерылган. Богословски бакыр эретү заводы да баш күтәрү уты астында калган. Аны, баш күтәрүләр тәмамланганчы, көчле отряд саклап торган.

Бары тик 1774 елның гыйнвар азагына гына генерал-аншеф А.И.Бибиковка Бөгелмә идарәчелеген үз күзәтүе астына алу мөмкинлеге туа һәм ул гаскәриләрне Бөгелмәгә китерә. Аннан ике якка таба — Оренбург һәм Уфа юнәлешләренә — һөҗүмнәр оештыру җиңеләя. Кырыс җәзалауларга да карамастан, Көнчыгыш Чулман аръягы халыклары тынычланмый. Хакимият вәкилләре авылларда булганда, крестьяннар «гаепләрен таныган», ә җәза отрядлары китеп бару белән, алар янәдән үзидарәләрен торгызган, яңа отрядлар төзегән һәм көрәшне дәвам иткән. Мондый хәл крестьяннар баш күтәрүенең

үзенә күрә бер тактикасы төсен алган. Мәгълүм булганча, Бөгелмә, Минзәлә һәм Зәй арасындагы төбәкләрдә баш күтәрүләр 1774 елның мартына кадәр актив барган.

Көрәшнең икенче (1774 ел, апрель-июль уртасы) һәм өченче (1774 ел, июль — 1775 ел) этапларында Көнчыгыш Чулман аръягында крестьяннар чуалышы элеккеге кебек колачлы һәм куәтле җәелми, партизаннар сугышы рәвешен ала. Яңа Мәскәү юлы буендагы авылларда яшәүчеләр, башкортлар белән берләшеп, Оренбург һәм Казан арасындагы юл хәрәкәтенә комачаулыклар ясаган: азык-төлек олауларын һәм башка төрле транспорт чараларын кулга төшергән, үтеп баручы офицерларны үтергән. Җәзалаучылар, хәрбиләр тарафыннан юл никадәр генә сакланса да, җирле халыкны тынычландырып булмаганлыгын таныган. Губерна түрәләре әйтүенчә, хәтта 1774 елның көзендә Пугачёв гаскәре тар-мар ителгәннән соң да, күп авылларда каршылык күрсәтүләр давам иткән.

Идел һәм Урал буйларындагы баш күтәрүләрне бастырганнан соң, Россиядә җитди админстратив-территориаль үзгәртеп корулар башлана. Җирле хакимиятнең көчен ныгыту максатыннан, Екатерина IIнең 1781 елның 23 декабрендә имзаланган Указы нигезендә, элеккеге Оренбург губернасы җирләрендә Уфа идарәчелеге оештырыла. Аның составына Уфа һәм Оренбург өлкәләре кертелә. Уфа өлкәсенә Уфа, Бөре, Минзәлә, Бөгелмә, Богырослан, Бәләбәй, Эстәрлетамак һәм Чиләбе өязләре карый. Бөгелмә өязенең үзәге шәһәр статусын алган Бөгелмә бистәсе була. 1797 елда Бөгелмәдә барлыгы 1858 кеше (868 ир-ат һәм 990 хатын-кыз) хисапланган, алар 359 йортта яшәгән. Бу дәвердә Әлмәттә 708 кеше гомер сөргән. Шулай итеп, ул үз заманы өчен шактый эре авыл саналган. Биредә почта станциясе, казна мәйханәсе, шәхси тимерче алачыгы һәм мәчет эшләгән. Һәр атнаның чәршәмбе көнендә авылда базар оештырылган.

Давыллы XVIII гасырның әлмәтлеләргә кагылышлы соңгы вакыйгаларыннан берсе — Урал буе җирләренә кантонлы идарә системасы кертелү. Хакимият әлеге чара ярдәмендә төбәкне тулысынча «тынычландырырга» һәм халык массаларының актив баш күтәрүләрен туктатырга өметләнгән. Бу яңалыкның инициаторы Уфа наместнигы генерал-поручик О.А.Игельстром була. Аның тарафыннан башкортларны һәм мещерякларны хәрби идарәгә күчерү турындагы закон проекты әзерләнә. Проект 1798 елның 10 апрелендә Павел I тарафыннан имзалана, башкортлар белән мещеряклар хәрби-йомышлы сословиегә күчерелә һәм территориаль (өяз) принцип буенча формалашкан 11 башкорт (1803 елдан — 12), 5 мещеряк кантоны барлыкка килә. Алар Вятка, Пермь, Оренбург губерналары территориясендә була һәм бары тәртип саннары белән атала. Кантоннар берничә авылны берләштергән, 700дән алып 1 меңгә кадәр ир-ат яшәгән йортларга һәм командаларга бүленә. Әлмәт һәм башка якын-тирә авылларның «башкортлар»ы Оренбург губернасының Бәләбәй, Бөгелмә һәм Богырослан өязләрен колачлап алган 12 нче башкорт кантонының 2 нче йортына кертелә.

Биредә яшәүче халыкның төп вазифасы 25тән алып 50 яшькәчә ир-атлар башкарырга тиешле хәрби йөкләмәләрне үтәү булган. Оренбург һәм Урал казаклары белән бергә, алар Тубыл елгасыннан Каспий диңгезенә кадәр сузылган Оренбург чиге буйларын саклау хезмәтен башкарган. Уртача 4-5 хуҗалыктан бер кеше чакырылган. Хәрби хезмәткә шәхси сугыш кораллары — сөңге, кылыч, мылтык, уклар һәм һәр сугышчыга дүрт ат белән килү мәҗбүри куелган. Моннан тыш үзләре белән, төрле казна эшләрендә эшләргә туры килсә дип, чалгы һәм балта да алырга тиеш булганнар. Бу коралларны авыл халкы һәм булачак хәрбиләр үз

хисабына алган. 6 айга сузыла торган хезмәт ил тыныч вакытларда чират буенча якынча дүрт-биш елдан соң килеп җиткән.

Хәрби йөкләмәдән кала, башкорт һәм мещеряклар конвой (әсирләрне саклап, озатып баручы кораллы отряд) булып йөргән. Башкорт командалары Уфа-Чиләбе юлында (Златоуст заводы аша) хезмәткә һәм сөргенгә сөрелгәннәрне озатып бару эшләренә җәлеп ителгән. Башкортлардан һәм мещеряклардан торган отрядлар Казан, Мәскәү, Петербург, ярминкә уза торган шәһәрләргә полиция хезмәтенә, шулай ук качак крестьяннарны, казак һәм башкортларны эзләүгә дә җибәрелгән. Алга таба алар эшчеләр һәм транспорт командалары составына күбрәк кертелә башлый, төзү эшләре башкара, губерна эчендә, Оренбург чиге буендагы ныгытмаларда һәм Казах даласында йөк ташый.

Шулай итеп, XVIII гасырда республикабызның көньяк-көнчыгыш ягы «Оренбург төбәге»нең бер өлеше сыйфатында кеше аз яши, уңдырышлы җирләргә бай, хакимият контроле чагыштырмача йомшак булган Россия империясенең «эчке чик буе» хәлендә була. Бу якларга Идел-Кама төбәгеннән төрле милләт вәкилләренең, бигрәк тә татарларның, күпләп күченүе күзәтелә, халыкларның яшәү ареалы киңәя. XIX гасырның 60 нчы еллары урталарына кадәр биредә 1798 елда кертелгән хәрби идарә системасы — кантоннар идарәләре — яшәп килә, шул вакытта гына хокукый һәм матди яктан крестьяннардан яхшырак көн күргән башкортлар, мещеряклар, типтәрләр сословиеләре бетерелә, алар игенче-крестьянга әверелә, «чемодан татарлар» социаль группасы исә бу вакыйгаларга кадәр чирек гасыр элек дәүләт крестьяннарына әйләндерелә.

Оренбург губернасы оешкач, хакимият җирле халык өстеннән күзәтүне, салым җыюны яхшырту буенча чаралар күрә, шуларга протест йөзеннән бигрәк тә XVIII гасырның беренче яртысында Урал буйларында татар һәм башкортларның баш күтәрүләре еш кабатлана. Пугачёв җитәкчелегендәге восстаниедә исә татарлар руслар белән бергә чыгыш ясый.

Чыганаклар һәм әдәбият

1. Акманов А.И. Земельная политика царского правительства в Башкирии (вторая пол. XVI — нач. XX вв.). — Уфа, 2000.
2. Алишев С.Х. Татары Среднего Поволжья в Пугачёвском восстании. — Казань, 1973.
3. Амирханов Р., Габдуллин И. Надыр Уразметов // Әлмәт — Альметьевск. — Казань, 2003. — С.288-297.
4. Асфандияров А.З. Введение кантонной системы управления в Башкирии //Из истории Башкирии. — Уфа, 1968.
5. Әлмәт — Альметьевск. — Казань, 2003. — 744 с.
6. Буканова Р.Г. Города-крепости юго-востока России в XVIII веке. — Уфа, 1997.
7. Иванин М.И. Описание Закамских линий // Вестник императорского Русского географического общества. — 1851. — Ч.1. Кн.2.
8. Из истории Альметьевского региона. Вып.1. — Альметьевск, 1999.
9. Исхаков Д.М. От средневековых татар к татарам нового времени (этнологический взгляд на историю волго-уральских татар 15-17 вв.). — Казань, 1998.
10. Материалы по истории Башкирской АССР. Т.IV, ч.1. — М., 1956.
11. Материалы по истории Башкортостана. Оренбургская экспедиция и башкирские восстания 30-х годов XVIII в. — Уфа: Китап, 2002.
12. Оренбургская губерния с прилегающими к ней местами по «ландкартам» Красильникова и «Топография» П.И.Рычкова 1755 года. — Оренбург, 1880.
13. Очерки истории Калмыцкой АССР. Дооктябрьский период. — М.: Наука, 1967.
14. Перетяткович Г.И. Поволжье в XVII и начале XVIII века. Очерки из истории колонизации края. — Одесса, 1882.
15. Рахматуллин У.Х. Население Башкирии в XVII-XVIII вв. Вопросы формирования небашкирского населения. — М., 1988.
16. Рычков П.И. Топография Оренбургской губернии. — Уфа, 1999.
17. Тимергазин К.Р. Очерки по истории башкирской нефти. — Уфа, 1956.
18. Черемшанский В.М. Описание Оренбургской губернии в хозяйственно-статистическом, этнографическом и промышленном отношении. — Уфа, 1859.

Русчадан ***Ленар Гобәйдуллин*** *тәрҗемәсе*

ӘЛМӘТ РАЙОНЫ БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫНДА*

АЙСЫЛУ КӘБИРОВА,
тарих фәннәре докторы, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре

БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ БАРЛЫК СОВЕТ ХАЛКЫ ӨЧЕН ИҢ ҖИТДИ СЫНАУ БУЛДЫ. КАЙГЫ-ХӘСРӘТ ҺӘМ КҮЗ ЯШЬЛӘРЕ БЕЛӘН УЛ ҺӘР ӨЙГӘ, ҺӘР ГАИЛӘГӘ ҮТЕП КЕРДЕ.

Ул елларда хәзерге Әлмәт районы территориясе өч мөстәкыйль административ берәмлеккә бүленгән булган: 1930 елның июлендә оешкан Әлмәт, Акташ һәм 1944 елның февралендә Яңа Чишмә белән Акташ районнары чикләрен үзгәртү нәтиҗәсендә оешкан Ямаш районнары. Хәзерге Әлмәт районы җирлегендә урнашкан авыллардан Бөек Ватан сугышына 18,5 мең кеше алына [1]. Аларның 8,5 меңе (һәр икенче кеше) туган якларына кайтмый, сугыш кырында ятып кала [2].

Безнең мәкаләбездә сүз хәзерге Әлмәт районының бер өлеше — ул еллардагы Әлмәт районы турында бара.

Сугышчыларның җиңүләре тылдагы якыннары өчен рухландыру үрнәге булган. «Барысы да фронт өчен! Барысы да Җиңүгә!» шигаре сугыш көннәрендә халык өчен көч-куәт биреп торган. Предприятиеләрдә, басу һәм фермаларда мобилизацияләнгән ирләр урыннарын хатын-кызлар, картлар, балалар алган. Татарстанның авыл һәм салаларына халык дошман оккупацияләгән төбәкләрдән эвакуацияләнгән. 1941 елның ноябрь аена Әлмәт районына 3500гә якын кеше һәм 2000 тирәсе бала күченеп килә [3]. Районда халыкның ихтыяҗларын канәгатьләндерерлек берничә киң кулланылыштагы продукция җитештерә торган дәүләт сәнәгать предприятиеләре ачыла: промкомбинат, азык-төлек сәнәгате, май җитештерү сәнәгате, «райтоп», урман хуҗалыгы. «Труд», «Ударник», «Зәй», «Металлпром» артельләре кергән сәнәгать кооперативы да эшли. Биредә аяк киеме һәм кием-салым, урын-җир, савыт-саба, кирпеч, арба, тәгәрмәч, тимерчелек кораллары һ.б. җитештерелә. Эшчеләрнең хезмәт шартлары бик авыр

* Эш Россия гуманитар фәнни фонды финанс ярдәме белән башкарылды, проект №12-11-16012а/В/2013.

Тылда намуслы хезмәт итүче Әлмәт районы Бигәш авылы «Дирижабль» колхозы активы. Язгы чәчүне тәмамлап, районның Күчмә Кызыл байрагын колхозга кабул итеп алу вакыты. 1944 ел. Фото Әлмәт туган якны өйрәнү музее фондыннан

була. Чимал, җиһазларга кораллар, запас частьләр җитми. Шул сәбәпле сугыш елларында Әлмәт районы сәнәгате продукциясенең, куелган тырышлыкларга карамастан, кимүе түбәндәге саннар белән раслана: 1940 елда товар җитештерү 661 мең сум булса, 1945 елда 468 мең сумга хәтле төшә (1926-1927 еллардагы бәяләр); кооператив сәнәгать өлкәсендә җитештерү күләме 1344,7 мең сумнан 1123,3 мең сумга кадәр түбән тәгәри [4].

Сугышка кадәрге чорда Әлмәт районы аграр төбәк булган, хуҗалык нигезен игенчелек һәм терлекчелек тәшкил итә. Эвакуацияләнгән халык хисабына арткан эшче кулларның күпчелеге авыл хуҗалыгында хезмәт куя. Шулай да машина, тракторлар, ир-ат куллары җитми, квалификацияле эшчеләргә, ягулык һәм майлау материалларына кытлык була.

Хәрби мобилизацияләрдән соң, хезмәткә яраклы авыл халкының саны өчтән бергә кими. Шунлыктан сугыш елларында кадрлар мәсьәләсе иң авырлардан була. Басуга яше дә, карты да чыга. Мәсәлән, Әлмәт районы «Зәй» күмәк хуҗалыгы колхозчылары сафында 1941 елның июль аенда — 49, «Ярыш»та — 37, «Ирек»тә — 35 олы яшьтәге кеше эшкә чыга. Көчләреннән килгәнчә, яшүсмерләр ярдәм итә. Әйтик, 1941 елда «Ярыш» күмәк хуҗалыгында җәйге эшләрдә — 74, «Марс №2»дә 95 мәктәп укучысы эшли [5].

1942 елның 13 апрелендә СССР ХКС һәм БКП(б)ның ҮК авыл күмәк хуҗалыкларында мәҗбүри хезмәт көннәре минимумын арттыру турында махсус карар кабул итә. ТАССР өчен әлеге минимум олы кешегә бер елга 120 хезмәт көне, 12-16 яшьлек яшүсмерләргә 50 көннән ким булмый. Бу хезмәт көннәре минимумын сәбәпсез эш калдырып өзүче колхозчыларны хөкемгә тартканнар [6].

Колхозчы хатын-кызлар сүс талку вакытында.
Фото Р.Абзалова-Сәлманованың «Иманлы төбәк җәүһәрләре» (Казан, 2008) китабыннан

Авыл хуҗалыгында хәлләр авыр булуга карамастан, авыл кешеләренең күпчелеге намус белән эшләгән. Колхозчыларның хезмәт батырлыгын сугышка кадәр чордагы хезмәт көннәрен арттырып үтәүләре исбатлый. «Социализмга» күмәк хуҗалыгыннан Фатыйма Саттарова, «Кызыл байрак»тан Шәмсениса Дәүләтшина, «Ярыш»тан Габдрахман Шәйдуллин көненә 2-3 норма үтәгән [7]. Кичү МТСында хатын-кыз трактор бригадасын җитәкләгән О.Валяеваның даны бөтен районга таралган. Бөртеклеләр һәм яшелчә культураларыннан югары уңыш җыюда «Ирек» колхозыннан Сылу Мортазина, Сталин исемендәге колхоздан Нәҗия Якупова, «Дирижабль» колхозыннан Рауза Рахмановалар зур осталык күрсәткән [8].

Гомумән, Бөек Ватан сугышы елларында мәҗбүри хезмәт көннәре минимумын үтәмәгәннәр саны, сугышка кадәрге чор белән чагыштырганда, өчтән бергә кимегән, хезмәт көннәре минимумы нормасын 300дән алып 400 көнгә җиткерелүчеләр саны — ике тапкыр, норманы 400 көннән арттыручылар саны өч тапкырга арткан [9].

Авыл хуҗалыгының торышы Әлмәт районында гына түгел, ә барлык ТАССРда фаҗигале хәлдә булган. Аның объектив сәбәпләре дип, материаль-техник базаның көчсезләнүе, техникага кискен кытлык, авылда күмәк хуҗалыкларның җитештерү көчләре, бигрәк тә МТСларның кимүен атарга кирәк. Әлмәт районы чәчүлек җирләренең мәйданы сугыш елларында өчтән бергә диярлек, ягъни 47,7 мең гектардан 37,4 мең гектарга кала [10]. Төп игенчелек культурасы исәпләнгән бодай җирләренең мәйданы 2 тапкыр, терлекчелек азыгы культуралары мәйданы 2,5 тапкырга кими. Сугыш елларында агротехника сыйфаты да түбән тәгәри: минераль ашламалар кайтарту туктатыла, басуларга органик ашлама чыгару планы үтәлми. Шунлыктан гомуми ашлык уңышы күләме — 2,5 тапкырга, ә һәр гектардан уңыш җыю яртысыннан артыкка кими.

Игенчелектә җитештерүнең түбәнәюе, терлек азыгы җитмәү, мал-туарларны карау шартлары начараю колхоз-совхозларда терлекнең баш саны һәм җитештерүчәнлек кимүгә китерә. Бу чигенеш бигрәк тә ат һәм дуңгыз үрчетү тармакларында көчле сизелә. Терлекчелекнең башка тармаклары азрак зыян күрә, бар күрсәткечләр дә сугышка кадәрге саннардан кайтыш.

Әлмәт районы Мәмәт авылында бер хуҗалык күренеше. 1930 еллар.
Фото Р.Абзалова-Сәлманованың «Иманлы төбәк җәүһәрләре» (Казан, 2008) китабыннан

Сугыш елларында Әлмәт районында атлар саны 7588дән 4152гә, мөгезле эре терлек 3839дан 2241гә, дуңгызлар саны 1309дан 600гә кала [11].

Авылның җитештерү көчләре турында сөйләгәндә, крестьяннарның бик нык хәлсезләнгән һәм фәкыйрь булуларын искәртү мөһим. Бар көчләрен фронт өчен биргән авыл кешеләре билгеле бер күләмдә хезмәт хакына өметләнми дә. Сугыш башлангач, дәүләт тарафыннан карточка системасы ярдәмендә халыкка норма белән азык-төлек тарату колхозчыларга кагылмый. Аларның кереме хезмәт көннәре күләменә бәйле булып, карточкалар фәкать авыл зыялыларына һәм эвакуацияләнгән кешеләргә генә таратыла. Әмма, архив документларыннан күренгәнчә, сугыш елларында хезмәт көннәрен язу һәм теркәү тәртибе барлык хуҗалыкларда да тиешле дәрәҗәдә булмый. Башкарылган хезмәтне исәпләү һәм тиешле хезмәт көннәрен теркәп язу ике айдан соң гына һәм тагын да соңрак башкарылган. Колхозчыларга аванс бирелгән очракларда тупас хаталар җибәрелгән.

Сугыш елларында хәрби хезмәткәр гаиләләренә пособие түләүне тоткарлау, шулай ук канун нигезендә тиешле пособиеләрне сәбәпсез түләмәү яки, киресенчә, түләү еш очрый торган күренешләрдән саналган. Болар барысы да дәүләт милкен исраф итүгә китергән. Мәсәлән, 1943 елның 1 апреленә Әлмәт райсобесының хәрбиләр пособие акчасы 38862 сум күләмендә түләнмәве ачыкланган. Моннан тыш финанс бүлегенең халыкка 30730 сум салымны дөрес салынмавы мәгълүм.

Күпчелек колхозчылар, исән калу өчен, йорт яны бакчаларына өметләнгән. Ләкин шәхси ярдәмче хуҗалыгы булганнар авыл хуҗалыгы салымын артыграк түләргә тиеш булган. Бәрәңге, җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчалары өчен дә өстәмә салым билгеләнгән. Дәүләт тарафыннан авыл кешеләренә билгеләнгән түбән суммалы хезмәт хакы акчасы ирекле-мәҗбүри рәвештә җыела торган

сугыш займнары, салымнар, акчалата яки әйбергә алыштырып лотереяларга язылу аша алынып беткән. Белгечләр исәпләвенчә, сугыш елларында халыкка җан башына ашлык һәм бәрәңге бирү күләме 3 тапкырга кимегән. Гади колхозчы күмәк хуҗалыктан көненә 200 граммнан ким ашлык һәм 100 грамм тирәсе бәрәңге алган (бер стакан ашлык һәм 1 бәрәңге) [12].

Шулай да авыр матди тормыш шартлары, ачлык әлмәтлеләрнең рухын сындыра һәм Җиңүгә ышанычын какшата алмаган. Район халкы фронтка даими ярдәм иткән: сугыш займнарына язылу, акчалата-әйберле лотереялар сату, саклану фондына һәм корал сатып алу өчен акча җыю һ.б. Мәсәлән, 1942 елда Дәүләт хәрби займына «Октябрь» колхозыннан Бакир Якупов һәм Хаттап Батталов, К.Маркс исемендәге колхоздан Гайнетдин Мостафин, «Зәй» колхозыннан Гыймай Мәгъсүмовлар язылган һәм берәр мең сум акча керткән. Бер көн эчендә — 1942 елның 15 апрелендә — «Ирек» колхозы кешеләре 74400 сумлык займга язылган. Гомумән алганда, I һәм II сугыш займнарына язылып, Әлмәт районы халкы 5 млн 300 мең сумлык акча тапшырган [13].

Шулай ук әлмәтлеләр, фронтовиклар өчен җылы кием-салым җыеп, бик зур ярдәм күрсәткән. Хәрәкәттәге армия сугышчыларына 3971 кг йон, 609 пар итек, 3601 иләнгән сарык тиресе, 376 кыска тун, 1275 пар йон оекбаш, 1875 пар бияләй, 369 мех бүрек һ.б. җибәрелгән. Акчалата ярдәм дә күрсәтелгән: ярдәм кампанияләре барышында 60231 сум акча җыелган [14].

Әлмәт районы халкы фашизмны тар-мар итүгә шәхси өлеш кертүне корал өчен акча җыеп та башкарган. Алар танк колонналарын төзү өчен — 1009000 сум, авиаэскадрильялар өчен 688354 сум җыйганнар. Хәрби техника җитештерү фондына кертелгән гомуми сумма район күләмендә 1697354 сум тәшкил иткән.

Дөресен әйтергә кирәк, халыктан акча җыю һәрдаим ирекле рәвештә алып барылмаган. Бу хактагы югары инстанцияләрнең күрсәтмәләре мәҗбүриятне күз алдында тоткан, бурыч үтәлмәгән очракта, репрессия чаралары кулланылган [15].

Чынлыкта, сугыш елларында колхозчы үстергән бар продукция диярлек төрле юллар белән тартып алынган. Әмма әлмәтлеләр, кыенлыкларга чыдам булып һәм авыр сугыш елларын зур сабырлык белән үткәргәннәр, чөнки аларның, барлык совет халкы кебек, җиңүгә ышанычлары көчле булган. Зур корбаннар хисабына авыр хезмәттән, киеренкелектән йончыган кешеләр фронт һәм тылны авыл хуҗалыгы продукциясе белән тәэмин итеп торган.

Искәрмәләр

1. Әлмәт шәһәре Ветераннар советының Сугыш һәм хезмәт даны бүлмәсе экспозициясе материаллары.
2. Память. В 28 тт. Т.3. — Казань, 1994. — С.4.
3. Әлмәт шәһәре Ветераннар советының Сугыш һәм хезмәт даны бүлмәсе экспозициясе материаллары.
4. Татарстан Республикасы нефть һәм газ сәнәгате тарихы документлары үзәге. (Әлмәт шәһәре). 1 ф. 1 тасвирлама. 56 эш. 8-19 б.
5. ТР МА (Татарстан Республиасы Милли архивы). 4580 ф.р. 3 тасвирлама. 317 эш. 4 б.
6. ТР ҮДТСДА (Татарстан Республикасы Үзәк дәүләт тарихи-сәяси докуметлар архивы). 15 ф. 5 тасвирлама. 1053 эш. 65 б.
7. ТР МА. 4580 ф.р. 3 тасвирлама. 168 эш. 37 б.
8. Социализмга. — 1941 ел. — 17 август.
9. Социализмга. — 1941 ел. — 16; 30 октябрь.
10. ТР ҮДТСДА. 528 ф. 1 тасвирлама. 273 эш. 7 б.
11. ТР МА. 4580 ф.р. 3 тасвирлама. 317 эш. 5 б; 167 эш. 13 б.
12. ТР МА. 3610 ф.р. 1 тасвирлама. 329 эш. 148-149 б.
13. ТР ҮДТСДА. 273 ф. 1 тасвирлама. 244 эш. 1 б.
14. Арутюнян Ю.В. Советское крестьянство в годы Великой Отечественной войны. Изд.2. — М., 1970. — С.341.
15. Социализмга. — 1942 ел. — 15; 23 апрель.

Русчадан ***Ренат Миңнегалиев***
тәрҗемәсе

1950-1960 ЕЛЛАРДА ТАССРДА НЕФТЬ СӘНӘГАТЕ ӨЧЕН МӘГАРИФ ИНФРАСТРУКТУРАСЫНЫҢ ФОРМАЛАШУЫ

МАРАТ МИНКИН,
тарих фәннәре кандидаты, Әлмәт дәүләт нефть институты гуманитар гыйлем һәм социология кафедрасының өлкән укытучысы

Нефть чыгару сәнәгате министрлыгы скважиналарны капиталь төзекләндерү бригадалары арасында уздырган Бөтенсоюз ярышында 3 нче урынны алган мастер А.М.Жмакинның 7 нче бригадасы (НГДУ «Азнакайнефть»). 1966-1968 еллар. Фото «Татнефть» ААҖ матбугат үзәгеннән алынды.

Татарстанда нефть чыгарыла башлау озак елларга төбәкнең икътисади, социаль һәм мәдәни үсеш стратегияләрен алдан билгеләп, республика үсешен тамырдан үзгәртте. Шул сәбәпле узган гасырның икенче яртысында Татарстан территориясендә булган вакыйгаларны, шул исәптән Әлмәт-Бөгелмә сәнәгать төйнәлеше һәм ТАССРның көньяк-көнбатыш нефть чыгару оешмаларына кадрлар әзерләүне бурыч итеп куйган мәгариф инфраструктурасының формалашу тәҗрибәсен өйрәнү зур әһәмияткә ия.

1950-1960 елларда нефть чыгара торган Әлмәт-Бөгелмә сәнәгать төйнәлеше барлыкка килү төбәктә кадрлар әзерләүнең өчбаскычлы системасы оешу белән бергә барды. Нибары ике дистә ел эчендә республиканың нефтькә бәйле мәгарифе ТАССР нефть сәнәгатен ил күләмендә иң алдынгы сафларга күтәрүгә йогынты ясарлык дәрәҗәгә җитә. Ә 1970 елларда «Татнефть» берләшмәсе углеводород чималын табу буенча беренче урынга чыгып кына калмый, ә Көнбатыш Себернең бай нефть һәм газ ятмаларын үзләштерүдә оешманың хезмәт потенциалы төп таяныч булып тора.

1940 еллар азагына кадәр ТАССРның көньяк-көнчыгышы икътисади яктан начар үскән, нигездә крестьяннардан гына торган аграр төбәк була. Сәнәгать җитештерүчәнлеге булмый диярлек. Кыска гына вакыт аралыгында нефть сәнәгате өчен кадрлар әзерли ала торган гыйльми куәт тә булмый. Болар барысы да нефть сәнәгатен кадрлар белән тәэмин итүдә җитди кыенлыклар тудыра [1].

Килеп туган хәлне үзгәртергә омтылып, сәнәгать төенләнешенең үсеше башланган чорда ук (1948-1951) илнең җитәкчелеге, Советлар Союзының нефть чыккан районнарыннан кадрлары һәм җиһазлары белән аерым оешмаларны күчереп, нефтьчеләр төркемен тупларга карар кыла. Күпмедер квалификацияле эшчеләрне Дәүләт хезмәт резервлары — фабрика-завод һәм һөнәрчелек училищелары бирергә тиеш була. Илнең профильле урта техник һәм югары уку йортларына укуларын яңа тәмамлаган яшь белгечләрне ТАССРга җибәрергә әмер бирелә [2]. Бу этапта җирле халык ярдәмче җитештерү тармагына квалификациясез эшче көчләр чыганагы буларак кына карала. Төбәк колхозларыннан алынган меңнәрчә колхозчылар иң авыр эшләрдә хезмәт куя: транспорт челтәрләре өчен траншеялар казый, йөк ташый, бораулау скважиналары өчен мәйданнар әзерли, юлларны һәм беренче чиратта мөһим булган объектларны төзүдә катнаша [3].

Әмма тиздән кадрлар проблемасын бу юл белән, читтән белгеч китереп кенә, хәл итеп булмаячагы ачыклана. Яңа оешкан сәнәгать оешмаларында аз гына эшләп, кире китүчеләрнең саны чиктән арта. Килгән эшчеләр, гадәттә, авыр хезмәткә һәм көнкүреш шартларына түзә алмый республиканы ташлап китә. Югары уку йортлары, техникумнар тарафыннан җибәрелгән яшь техниклар һәм инженерлар саны алгарыш шартларында үсә торган нефть сәнәгатенә җитмәгән. «Татнефть» берләшмәсенә эшкә җибәрелгән инженер-техник эшчеләрнең яртысыннан артыгы тиешле белемсез булган [4]. Әгәр дә беренче елларда мондый кадрларны «эшкә өйрәтү» проблемасы берникадәр хәл ителсә, сәнәгать оешмалары яңа техника белән тәэмин ителеп һәм катлаулы технологияләр гамәлгә куелып, эшчәнлекнең яңа юнәлешләре ачылгач, кадрлар мәсьәләсе яңадан кискен проблемага әйләнә һәм тиз арада хәл итүне таләп итә.

1951 елдан нефть чыгарылган төбәкләрдә кадрлар әзерләүнең күпбаскычлы системасын оештыру иң мөһим мәсьәлә була. Проблема барыннан да бигрәк тиешле матди база һәм

белгечләр булмау сәбәпле, авырдан хәл ителә. Шунысын да әйтергә кирәк: бу вакытта әле бер генә эре сәнәгать комплексының да үзенә кадрлар хәзерләү өлкәсендә мондый тәҗрибәсе булмый. Илдә үзәкләштерелгән яшь белгечләр әзерләүнең системасы эшли, яшь белгечләр планлы рәвештә кадрлар җитмәгән төбәкләргә мәҗбүри җибәрелә.

Республикада нефть мәгарифе системы формалашу Казандагы югары уку йортларында нефть факультетлары ачудан башлана. Бу проектка Казан дәүләт университеты, Химик-технологик институт һәм Гражданлык төзелеше институты җәлеп ителә. Башкалада урта техник һәм һөнәри уку йортлары да шактый була, әмма аларның нефть сәнәгатеннән ерак торган белгечлекләренең профильләрен үзгәртү максатка яраклы дип табылмый.

Кадрларга кытлык мәсьәләсен хәл итүдә мөһим адым булып республиканың нефть ятмалары чыгарылган урыннарында техник уку йортлары ачылу тора. Бөгелмәгә иң кирәкле белгечлекләр буенча эшчеләр әзерләр өчен Саратов өлкәсеннән бораулаучылар хәзерли торган уку йорты күченә. Җитештерү тармагын техниклар һәм инженерлар белән тәэмин итү эшен яшь нефть шәһәрләре Әлмәттә һәм Лениногорскида ачылган Октябрь нефть техникумы һәм Мәскәү нефть институты филиаллары башкара.

Бер үк вакытта сәнәгать оешмаларында укыту һәм квалификация күтәрүнең төрле формалары киң җәелдерелә, стахановчылар мәктәбе, инструкторлар вахталары, индивидуаль һәм бригадалы укулар оештырыла. «Татнефть»нең структур бүлекчәләрендә уку комбинатлары эшли башлый. Аларның эшчәнлекләре сәнәгать оешмалары һәм уку йортлары вәкилләреннән торган укыту-методик советлар карамагында була.

Нефть чыгару комплексы үсешенең беренче унъеллыгында эшчеләрнең гомумбелем дәрәҗәләре түбән булу һәм рус телен начар белүләре аларның һөнәри яктан әзерлекләрендә кискен каршылыклар да тудыргалаган. Аяныч хәлне республиканың көньяк-көнчыгыш районнарында эшче яшьләр өчен кичке мәктәпләр ачып хәл иткәннәр. Алар анда хезмәттән аерылмыйча гына тулы урта белем алган.

СССРда гомумбелем бирү мәктәпләрен политехнизацияләү дә уңай роль уйнаган. Н.С.Хрущёв идеясе белән башланып киткән әлеге гамәлнең төп максаты булып мәгарифне сәнәгатькә якынайту тора [5]. 1960 еллар азагына Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарындагы техник уку йортлары көндезге уку формасына күчкәч, абитуриентларны туплаганда, урта мәктәп тәмамлаучыларга өстенлек биргәннәр, алар сәнәгать тармагында да уку сәбәпле, берникадәр әзерлекле булганнар һәм күп очракта булачак һөнәрләрен уйлап сайлаганнар.

Шул ук вакытта кадрлар әзерләү системасы торгызылу процессында күп кенә кыенлыкларны да җиңәргә туры килгән. Озак вакытлар уку йортларының тиешле матди базалары булмау, укытучылар җитмәү, программаларының методик яктан нигезле булмавы укыту эшен уку-курс комбинатларында гына түгел, ә техникум һәм институтларда да сыйфатлы итеп алып бару мөмкинлеген бирмәгән. Уку йортлары һәм эш тәкъдим итә торган сәнәгать оешмалары арасында һәрвакытта да тиешле мөнәсәбәтләрне җайга салып булмаган.

Әлбәттә, яңа юнәлешне булдыруда җитешсезлекләр дә күзәтелгән. Әйтик, еш кына кадрларга мохтаҗ булган оешмалар үзләренең эшчеләренә белем алу өчен уңайлы шартлар тудырмаган, булачак яшь белгечләрнең матди хәлләре, көнкүреш тормышлары турында тиешле кайгыртучанлык күрсәтмәгән [6]. Үз чиратында, оешма җитәкчеләре килгән эшчеләрнең һәм белгечләрнең

начар әзерлекле булулары турында дәгъва белдергән. Яшь белгечләрнең кайберләре, чыннан да, хәзерлексез булып чыккан һәм эш процессы белән таныш булмаган. Шуңа да карамастан, республика, «Татнефть» берләшмәсе һәм уку йортлары җитәкчеләренең күмәк көче белән башлангыч чордагы күп кенә проблемалар шактый кыска вакыт эчендә хәл ителгән. Биредә нефть чыгару оешмаларында 1953 елда эшчәнлекләрен башлап җибәргән укыту-методик советлар аеруча мөһим рольне уйнаган. Аның составына эш бирүчеләр, җирле хакимият һәм уку йортларының вәкилләре кергән. Мондый советларның эшчәнлеге нәтиҗәсендә проблемалар тиз арада һәм уңай хәл ителгән. Бу сәнәгать оешмалары һәм белгечләр әзерли торган уку йортлары арасында хезмәттәшлек итү юлында беренче әһәмиятле адым була [7].

1960 еллар урталарына кадәр республиканың көньяк-көнчыгышында башлангыч һөнәри, урта техник һәм югары уку йортлары бары тик эшчеләрне әзерләү һәм эшләүчеләренең квалификацияләрен күтәрүгә игътибар биргән, уку процессы җитештерү тармагы белән тыгыз бәйләнештә торган. Шунысын әйтергә кирәк: 1950-1960 елларда Татарстанның нефть районнарында киң таралыш алган читтән торып һәм кичке уку формалары ихтыяҗ булганнан гына барлыкка килмәгән, ә дәүләтнең һөнәри белем бирү өлкәсендәге рәсми стратегиясен тормышка ашыру өчен ачылганнар. Соңрак уку йортларында көндезге уку бүлекләре дә оештырыла. Бу нефть сәнәгате өчен кадрлар әзерләү процессына урта мәктәпне тәмамлаган яшь буынны җәлеп итү мөмкинлеген бирә.

Шулай итеп дөрес сайланган стратегия кыска вакытта кадрлар проблемасын уңай хәл итәргә мөмкинлек бирә һәм үсеп килгән «Татнефть» берләшмәсе заман таләпләренә җавап бирерлек эшчеләр, инженер-техник белгечләр белән тәэмин ителәә. Производство белән тыгыз бәйләнештә формалашкан һөнәри белем бирү инфраструктурасы республиканың аграр көньяк-көнчыгыш төбәген югары интеллектуаль куәт белән алга киткән сәнәгать үзәгенә әверелдерүдә төп факторларның берсе була. Бүген дә тармакны кадрлар белән тәэмин итүче мәгариф системасы Татарстан Республикасының нефть чыгару комплексында иң мөһим буыннарның берсе булып кала һәм аның уңышлы үсешенә йогынты ясый. Татарстан нефтьчеләренә югары һөнәри осталык һәм зур тәҗрибә бөтен ил буенча нефть сәнәгатен тотрыклы үстерергә, техник һәм технологик мөмкинлекләрне камилләштерергә, углеводород чималының запасын һәм чыгару күләмен арттыру өстендә эшләргә мөмкинлек бирә.

Әдәбият

1. Фасхутдинов К.Ф. Формирование и развитие Альметьевско-Бугульминского промышленного узла в Татарстане // Из истории Альметьевского региона: сб.науч.тр. — Казань: Татполиграф, 1999. — С.244-261.
2. ТР ТСД ҮДА, Ф. 15. Оп. 6. Д. 2090. Л. 38-46.
3. Галлямова А.Г. История Татарстана: модернизация по-советски (вторая половина 1940-х — первая половина 1980-х гг.) — Казань: Магариф, 2010. — 223 с.
4. Князев С.Л. Нефть Татарии: рубежи, взгляд сквозь годы. — Казань: Тат.кн.изд-во, 1990. — 328 с.
5. Закон СССР «Об укреплении связи школы с жизнью и о дальнейшем развитии системы образования в стране» от 24.12.1958 г. / URL: http://www.kadis.ru/texts/index.phtml=40246
6. Лебедева М. Улучшить подготовку кадров нефтедобытчиков // Знамя труда. — 1955. — 16 ноября. — С.3.; Ахметзянов З. Рабочая молодёжь должна учиться // Знамя труда. — 1956. — 6 апреля. — С.4.; Мясоутов А. Искоренить формализм в обучении рабочих кадров // Знамя труда. — 1958. — 26 января. — С.3.
7. Цитрина Л.Н. Разрешение проблемы обеспечения кадрами нефтяной промышленности Татарии // Труды КХТИ: сб.науч.тр.: вып. 28. — Казань, 1960. — С.51.

Русчадан ***Ленар Гобәйдуллин*** *тәрҗемәсе*

ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕНДӘ ИҖТИМАГЫЙ-МӘДӘНИ ТОРМЫШ ҺӘМ МӘГАРИФ ҮСЕШЕНЕҢ КЫСКАЧА ЕЛЪЯЗМАСЫ

1953 ел

- РСФСР Югары Советы Президиумы Указы нигезендә, Әлмәт эшчеләр посёлогына шәһәр статусы бирелә.

1954 ел

- Чупай ташыннан беренче йортлар төзелә.
- «Знамя труда» газетасы басыла башлый.
- Лениногорск шәһәре балалар музыка мәктәбенең филиалы ачыла.
- БАССРның Октябрь шәһәрендәге нефть техникумының филиалы эшли башлый.

1955 ел

- «Әлмәтнефтестрой» тресты тарафыннан радиотапшырулар оештырыла (Әлмәттә 1936 елның 1 октябреннән үк радиоузел эшли башлый).
- Горький исемендәге клубта әдәби түгәрәк эшли башлый.

1956 ел

- Лениногорск нефть техникумы филиалы ачыла.
- КПСС Татарстан өлкә комитеты органы булган «Нефтяник Татарии» газетасы басыла башлый (1993 елдан — «Нефтяник Татарстана»).
- 28 октябрь «Татарская нефть» журналының беренче саны дөнья күрә.
- Губкин исемендәге Мәскәү нефть һәм газ институты читтән торып уку факультетының укыту-консультация пункты ачыла (1959 елда институтның кичке факультеты итеп үзгәртелә, 1990 елда көндезге бүлек ачыла, 1992 елда Әлмәт нефть институты оештырыла).

1957 ел

- Горький исемендәге паркта җәйге театр эшли башлый.
- Әлмәт шәһәренең генераль планы раслана.
- 1 нче номерлы татар урта мәктәбе бинасы сафка бастырыла (Әлмәт авылында татар дөньяви мәктәбе 1918 елдан ук эшли).

1959 ел

- ТАССР Югары Советының «Әлмәт шәһәре чикләрен киңәйтү турында»гы Указы чыгарыла (Бигәш авылы кушыла).
- Нефтьчеләрнең фәннитехник китапханәсе ачыла.

1962 ел

● Казан рәссамнарының беренче күргәзмәсе оештырыла.

1963 ел

● Балалар сәнгать мәктәбе ачыла.

● ТАССР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге оеша.

● Әлмәт рәссамнары күргәзмәсе оештырыла.

● «Восход» (соңрак — «Татарстан») кинотеатры төзелә.

1964 ел

● Республиканың нефть районнарында беренче музыка фестивале уздырыла.

● Музыка училищесы ачыла.

● Казан төзелеш техникумының кичке уку формасы белән филиалы ачыла (1966 елдан — газ сәнәгате техникумы, 1972 елдан — төзелеш техникумы, 1994 елдан нефть техникумы белән кушылып, политехник техникум).

1965 ел

● Халык уен кораллары оркестры оеша.

● «Хезмәт байрагы» газетасы (1931 елда — «Борьба за колхоз», 1932 елда — «Социализмга», 1957 елда — «Маяк», ә 1990 елда «Әлмәт таңнары» исемнәре белән чыга башлый).

1966 ел

● Физик тәрбия техникумы ачыла.

1967 ел

● «Әлмәтнефть» идарәсенең «Нефтяник» газетасы басыла башлый.

● Журналистлар берлеге оештырыла.

1968 ел

● Совет сәүдәсе техникумы ачыла (1992 елдан — коммерция, 1996 елдан — сәүдә-икътисад техникумы).

1974 ел

● М.Горький исемендәге клуб каршында балалар кыллы уен кораллары оркестры оештырыла.

1975 ел

● Шәһәр картиналар галереясы ачыла.

● Нефть техникумы ачыла.

● Техник училище ачыла (1996 елдан — 65 нче номерлы һөнәри колледж).

1976 ел

● Беренче троллейбус йөри башлый.

1977 ел

● Г.Баруди урамында шәһәрнең беренче мәчете оештырыла (1995 елда манара куела).

● ТАССР Композиторлар берлегенең Әлмәт бүлеге ачыла.

● 2 нче музыка мәктәбе ачыла.

● Г.Ахунов романы буенча төшерелгән «Хәзинә» нәфис фильмының премьерасы була.

1979 ел

● Әлмәт театрына, Т.Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» исемле әсәрен сәхнәләштергән өчен, ТАССР Дәүләт премиясе бирелә (Әлмәттә күчмә театр 1944 елның мартында оештырыла, 1985 елдан — Татар дәүләт драма театры).

1981 ел

● «Нефтьче» мәдәният сарае ачыла.

● Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумы филиалы ачыла.

1989 ел

● Татар иҗтимагый үзәгенең беренче оештыру конференциясе уза.

● 2 нче номерлы рәсем сәнгате мәктәбе ачыла.

1990 ел

● Пётр һәм Павел чиркәве төзелә.

● Медицина училищесы ачыла.

● С.Сөләйманова урамында китапханә ачыла. (Район китапханәсе 1935 елдан бирле эшли, 1952 елда нефтьчеләрнең профсоюз китапханәсе оештырыла.)

● 1 нче номерлы татар мәктәп-гимназиясе ачыла.

● Әлмәт радиотапшырулар редакциясендә телевидениенең беренче сигналлары эфирга чыгарыла.

1991 ел

- Үзәк балалар китапханәсе бинасы ачыла.
- Татарстан Республикасының суверенитетын яклап, митинг уздырыла.
- Р.Фәхреддин исемендәге татар гимназиясе ачыла.
- «Луч» телекомпаниясе оештырыла.

1992 ел

- Сажидә Сөләйманова музее ачыла.
- «Молодёжный коктейль» газетасы чыгарыла башлый.

1993 ел

- Яшьләр үзәге оештырыла.
- Совет урамында 2 нче мәхәллә мәчете ачыла.
- Татар-төрек лицее оештырыла.

1994 ел

- «Хәзинә» газетасы басыла башлый.
- Туган якны өйрәнү музее ачыла.
- Татар телендә белем бирә торган 3 нче музыка мәктәбе ачыла.

1995 ел

- Табигать фәннәре-математика мәктәбе ачыла.
- Чиркәү-мәхәллә мәктәбе ачыла.
- «Әлмәтнефть» нефть-газ чыгару идарәсе каршында «Әлмәт энциклопедиясе» иҗат төркеме оештырыла.

1996 ел

- Муниципаль институт ачыла.
- Курчак театры ачыла.
- «Ак калфак» хатын-кызлар җәмгыятенең җирле бүлекчәсе оештырыла.
- «Зеркало» яшьләр газетасы басыла башлый.

1997 ел

- «Яшьләр заманы» газетасы басыла башлый (2013 елның 1 гыйнварыннан — «Альметьевский вестник» — «Әлмәт хәбәрләре»).
- Милли-мәдәни үзәк оештырыла.

1998 ел

- Ш.Мәрҗани урамында Р.Галиев мәчете төзелә, мөселман мәгариф үзәге эшли башлый.
- Район мәдәният йортының яңа, заманча бинасы куллануга тапшырыла.

1999 ел

- Әлмәт шәһәре студентларының беренче конгрессы уза.
- «Город» һәм «Юго-Восток» газеталары басыла башлый.
- 1 нче һәм 2 нче номерлы сәнгать мәктәпләре ачыла.

2001 ел

- Р.Төхфәтуллин урамында мәчет ачыла.
- «Альметьевск» телестудиясе эшли башлый.

2003 ел

- Беренче «Әлмәт энциклопедиясе» нәшер ителә.

2005 ел

- ЗАГСның яңа бинасы ачыла.
- Шәһәр паркында Геройлар аллеясы ачыла.

2007 ел

- Әлмәт Россиянең иң төзек шәһәре (1 нче урын) исеменә лаек була.
- Казан Изге Ана иконасы чиркәве ачыла.

2008 ел

- Әлмәт Россиянең иң төзек шәһәре (3 нче урын) исеменә лаек була.

2009 ел

- Әлмәт шәһәренең генераль планы раслана, 2025 елга кадәрге үсеш юнәлешләре билгеләнә, «Көнбатыш капка», «Яшьлек», «Алсу», «Коньяк-кончыгыш» микрорайоннары төзелеше проектлары раслана.

2011 ел

- Әлмәт Россиянең иң төзек шәһәре (3 нче урын) исеменә лаек була.

«ТАТНЕФТЬ»НЕҢ КЫСКАЧА ЕЛЪЯЗМАСЫ

1943 ел

- Бораулау мастеры Г.Х.Хәмидуллин бригадасы тарафыннан Шөгер авылыннан ерак түгел беренче скважина бораулана һәм нефть чыгарыла.
- Баулы авылы янында беренче скважина бораулана һәм нефть чыга башлый.

1945 ел

- Республиканың беренче нефть оешмасы — Шөгер нефть промыселы оештырыла.

1946 ел

- Баулы девон нефть ятмалары ачыла.

1948 ел

- Ромашкино нефть чыганагын үзләштерү башлана.

1949 ел

- «Татарнефть» тресты оештырыла. Аның составына Шөгер, Баулы нефть чыгару оешмалары һәм «Туймазынефть» трестының 3 нче номерлы бораулау конторасы керә.

1950 ел

- «Татнефть» берләшмәсе оештырыла. Аның составына «Баулынефть», «Бөгелмәнефть» нефть чыгару трестлары, «Татбурнефть» бораулау тресты, «Татнефтепромстрой» төзелеш-монтаж тресты, «Татнефтепроект» конторасы кертелә.
- Азнакай районында нефть чыгарыла башлый.
- Яңа Елхово ятмаларыннан нефть чыгарыла башлый.

1951 ел

- Пугачёв шәһәреннән (Саратов өлкәсе) — Бөгелмәгә, ә аннары Әлмәткә бораулаучы кадрлар мәктәбе күчерелә (1995 елдан — «Татнефть»нең кадрлар әзерләү үзәге).

1952 ел

- «Әлмәтнефть» нефть һәм газ чыгару тресты оештырыла.

1953 ел

- Татарстан яшь нефтьчеләренең беренче слёты оештырыла.
- «Баулынефть»тә ТАССРда беренче мәртәбә нефть чыгару процессы автоматлаштырыла.

1955 ел

- Кама буенда нефть чыгарыла башлый.

1956 ел

- «Азнакайнефть» нефть промыселы оештырыла.
- «Татнефть» нефть чыгару күләме буенча (елына 18 млн тонна) илдә беренче урынны ала.
- КПССның XX съезды директивасы белән алтынчы бишьеллыкта ТАССРда яңа нефть ятмаларын әйләнешкә кертү турында зур бурычлар куела.
- ТатНИИнефть — Татар нефть фәнни-тикшеренү институты оештырыла.
- Нурлатта нефть ятмалары табыла.

1957 ел

- Миңлебай газобензин заводы эшли башлый.
- Бөгелмәдә «Татнефтепроект» институты эшли башлый.

1958 ел

- «Әлмәтнефть» нефть промысылы идарәсе бер тәүлектә чыгарылган нефть күләме (31400 тонна) буенча илдә беренче урынга чыга.
- «Әлмәт-Пермь» магистраль нефть үткәргече кулланылышка тапшырыла.
- «Прикамнефть» нефть промыселы оештырыла.

1959 ел

- Татарстан нефтьчеләре тәүлегенә 100 мең тонна нефть чыгаруга ирешә.
- «Әлкәйнефть» нефть промыселы идарәсе оештырыла.

1962 ел

- «Татнефтегаз» һәм «Елховнефть» нефть промыселы идарәләре оештырыла.

1963 ел

- «Лениногорскнефть» идарәсе, елына 18,2 млн тонна нефть чыгарып, илдә иң эре нефть чыгару идарәсе була.

1964 ел

- «Иркеннефть» һәм «Актүбәнефть» идарәләре оештырыла.
- Идел буе районнарыннан Чехословакия, Венгрия, Польша һәм ГДРга нефть җибәрер өчен «Дружба» магистраль нефть үткәргече төзелә.

1966 ел

- «Татнефть» җитештерү берләшмәсе Ленин ордены белән бүләкләнә.

1968 ел

- «Сөләйнефть» һәм «Җәлилнефть» нефть промыселе идарәләре оештырыла.

1970 ел

- «Татнефть» елына 100 млн тонна нефть чыгарып, беренчелек яулый. Бу беренчелек 1976 елга кадәр саклана.
- ТатНИИнефть һәм «Татнефтепроект» институтлары базасында ТатНИПИнефть — Татар нефть сәнәгате фәнни-тикшеренү һәм проект институты оештырыла.
- «Әлмәтнефть» нефть промыселе идарәсе Ленин ордены белән бүләкләнә.

1971 ел

- ТАССР нефтьчеләре бер миллиард тонна нефть чыгаралар.

1975 ел

- «Сөләйнефть» нефть-газ чыгару идарәсе максималь күләмдә — елына 9,6 млн тонна нефть чыгара.
- Республика буенча максималь күләмдә — елына 103,7 млн тонна нефть чыгарыла.

1976 ел

- «Елховнефть» нефть-газ чыгару идарәсе максималь күләмдә — елына 12,7 млн тонна нефть чыгара.
- СССР Министрлар Советы «Җир астыннан мөмкин булганча күп күләмдә нефть чыгару чаралары турында» карар кабул итә, анда нефть чыгаруда заманча технологияләрне гамәлгә кертергә кирәклеге турында әйтелә.

1977 ел

- Татарстан нефтьчеләре Көнбатыш Себер нефть ятмаларын үзләштерүдә ярдәм күрсәтә башлый.

1979 ел

- «Нурлатнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе оештырыла.

1981 ел

- ТАССР нефтьчеләре ике миллиард тонна нефть чыгаралар.
- Әлмәт бораулау эшләре идарәсе Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

1985 ел

- Көнбатыш Себер-Урал-Идел буе һәм Оренбург-Миңлебай магистраль трубаүткәргече эксплуатациягә тапшырыла

1988 ел

- «Ямашнефть» нефть-газ чыгару идарәсе максималь күләмдә — елына 2,1 млн тонна нефть чыгара.

1990 ел

- «1990-1995 елларда экология» дигән беренче киң масштаблы программа төзелә һәм эшли башлый.

1992 ел

- РФ хакимияте нефть компанияләренә табылган продукцияне реализацияләүне үзләренә рөхсәт итә.

1994 ел

- Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе арасында вәкаләтләрне бүлешү һәм чикләү турындагы Шартнамәгә нефть чыгару тармагы турында аерым килешү пункты кертелә.
- «Татнефть» берләшмәсе акционерлык җәмгыяте итеп үзгәртелә.

1995 ел

- Елына 400 мең тонна продукция чыгара торган Кичү нефть эшкәртү җайланмасы төзелә.

1997 ел

- «Рухият» фонды оештырыла.

2000 ел

- Нефть химиясе юнәлеше үсеш ала башлый.

2001 ел

- «Җәлилнефть» нефть-газ чыгару идарәсе тарафыннан 500 млн тонна нефть чыгарыла.

2002 ел

- «Татнефть-нефтехим» идарәче компаниясе оеша.
- «Татнефть газ эшкәртү» идарәсе оеша.
- Түбән Кама нефть эшкәртү заводы эксплуатациягә тапшырыла.
- «Нижнекамскшина» ААҖдә аена 1 млн 13 мең шина җитештерелә

2003 ел

- Кызу темплар белән Әлмәт шәһәрендә социаль объектлар реконструкцияләнә һәм төзелә башлый (ипподром, мәйдан, шарлавыклы буалар, ашыгыч ярдәм станциясе, флюорография бинасы, мәктәп-интернат, 10 нчы, 16 нчы мәктәпләр, балалар дәвалау учреждениеләре).
- «Татнефть газ эшкәртү» оешмасы тарафыннан 100 миллиард кубометр газ эшкәртелә.
- Түбән Камада синтетик май җитештерү заводы эшли башлый.

2006 ел

- «Татнефть» Яшәүче (Чирмешән районындагы Яшәүче авылы тирәсе) чыганагында Россиядә беренче мәртәбә куе нефть ятмаларын чыгаруны башлап җибәрә.
- «Татнефть» компаниясе — «2000-2015 елларга экологик программа» өчен «Эко-Мир» премиясе лауреаты.

2007 ел

- Пар-гравитация дренажы технологиясе белән Яшәүче чыганагыннан 1000 тоннадан артык битум чыгарыла.
- Рекордлы күрсәткеч — «Түбән Кама шина» ААҖ конвейерыннан «Кама» маркалы 300 миллионынчы шина чыгарыла.
- Татарстан нефтьчеләре 3 миллиард тонна нефть чыгара.

2008

- «Татнефть»нең структур бүлекчәсе — Бөгелмә механика заводыннан 1000 нче чылбырлы привод чыгарыла.
- «Татанефть»ААҖдә иярчен нефть газыннан электр энергиясе җитештерә торган җайланма эшли башлый.

2009 ел

- «Татнефть» ААҖ «Континенталь» немец компаниясе белән Түбән Кама тоташ металл кордлы заводында елына 1,2 млн шина җитштерә ала торган яңа производство эшен башлап җибәрә.
- «Татнефть» ААҖ һәм немец компаниясе «Прайсс-Даймлер Групп» уртак проект — «П-Д Татнефть Алабуга Стекловолокно» пыяла сүс җитештерү заводын һәм аның продукциясен тәкъдим итә.
- «Татнефть» ААҖ Белоруссиядә автомашиналарны ягулык белән тәэмин итү станцияләрен төзи башлый.

2011 ел

- «Татнефть»тә скважиналарның ремонт-ара эшләү вакыты 1097 тәүлеккә җитә. Бу өч ел ремонтсыз эшләү дигән сүз.
- «ТАНЕКО»ның беренче сафы тулы куәтенә эшли башлый.

2012 ел

- «Сколково» технопаркында «Татнефть» ААҖнең фәнни-техник үзәген ачу турында рәсми килешү имзалана.

2013 ел

- «Әлмәтнефть» нефть-газ чыгару идарәсе 600 млн тонна нефть чыгара.
- Түбән Кама тоташ металл кордлы шиналар заводында миллионынчы шина җитештерелә.

- **Татнефть» берләшмәсе тарафыннан нефть чыгарылуның үсеш этаплары:**

1) 1950-1970 еллар — төп нефть чыгару объектларын гамәлгә кертү һәм нефть чыгаруның интенсив үсеше;
2) 1970-1975 еллар — нефть чыгаруны максималь югарылыкта тотрыклы тоту;
3) 1976-1994 еллар — нефть чыгаруның күләме киму;
4) 1995 елдан башлап — нефть чыгаруны елына 24-25 млн тоннада тотрыклы тоту.

ТАТАРСТАН НЕФТЬЧЕЛӘРЕ
ГИМНЫ

Нур Әхмәдиев сүзләре
Зиннур Сафиуллин көе

Таулар ишәбез, ташлар тишәбез,
Кара алтынга кадәр төшәбез.
Коелар аша, торбалар аша
Җирнең йөрәге безгә тоташа.

Кушымта:
Син данга күмдең, бәхетле иттең
Намуслы хезмәт сөйгән халкыңны.
Язмышым минем, шатлыгым минем,
Татарстанның кара алтыны!

Без бит бәхетне табып өйрәнгән
Җир куеныннан, тирән-тирәннән.
Нефть ташкыны — куәтле елга,
Без хәрәкәттә, без һәрчак юлда.

Кушымта:
Син данга күмдең, бәхетле иттең
Намуслы хезмәт сөйгән халкыңны.
Язмышым минем, шатлыгым минем,
Татарстанның кара алтыны!

Шөгер алтыны, Азнакай, Баулы,
Әлмәт-башкала тарихта калды.
Әле никадәр яңа җыр-көйләр
Безнең батырлык турында сөйләр.

Кушымта:
Син данга күмдең, бәхетле иттең
Намуслы хезмәт сөйгән халкыңны.
Язмышым минем, шатлыгым минем,
Татарстанның кара алтыны!

ТАТАРСТАННЫҢ КӨНЬЯК-КӨНЧЫГЫШ ШӘҺӘРЛӘРЕН ТӨЗҮДӘ ЧУПАЙ ТАШ КАРЬЕРЫНЫҢ РОЛЕ

РАМИЛ ХАННАНОВ,
филология фәннәре кандидаты

Чупай таш карьерының бүгенге күренеше

XX ГАСЫРНЫҢ 40 НЧЫ ЕЛЛАРЫНДА ӘЛМӘТ РАЙОНЫ ҺӘМ АНЫҢ ТИРӘ-ЯГЫНДА «КАРА АЛТЫН» ТАБУ, АНЫ ЭШКӘРТҮ ҖАЙГА САЛЫНГАЧ, ТОРАК ЙОРТЛАР, ПРОИЗВОДСТВО КОРЫЛМАЛАРЫНА ИХТЫЯҖ НЫК АРТА. ЭЗЛӘНҮЛӘР НӘТИҖӘСЕНДӘ, ӘЛМӘТ ТОРАК ПУНКТЫ ТИРӘСЕНДӘ ТӨЗЕЛЕШ ӨЧЕН МАТЕРИАЛЛАР (ЧИМАЛ) ӘЗЕРЛӘҮНЕҢ ЙӨЗДӘН АРТЫК УРЫНЫ ТАБЫЛА. ШУЛАРНЫҢ АЛТМЫШТАН АРТЫГЫ СӘНӘГАТЬ ЯГЫННАН ӘҺӘМИЯТКӘ ИЯ БУЛА. КАЛГАННАРЫ, ЮКА ЯТМА КАТЛАМДА БУЛУ СӘБӘПЛЕ, ИГЪТИБАРДАН ЧИТТӘ КАЛА.

Карбонат пародалар (известняк) яралган урыннар Татарстан территориясендә күп түгел. Файдаланырга яраклы катлам нибары берничә метрны, сирәк очракларда дистә, йөз квадрат метрны тәшкил итә. Әлмәт төбәгендә бары Икенче Кичүчат һәм Чупай җирлекләрендә бу күрсәткеч ике мең куб метрга җитә. Күрсәткечләр заманы өчен шактый югары була. Вакыт-вакыт әлеге карьерларда табылган известняк юл төзелешендә файдаланыла торган һәм бетон җитештерүгә кирәкле ташны да алыштыра.

Заман әлмәтлеләрдән күпне таләп итә. Чупай авылы янында төзелеш өчен кыйммәтле материал табылгач, авылның көньяк өлешендә ашыгыч рәвештә, эшчеләрне яшәү урыннары белән тәэмин итү өчен, такталар арасына пычкы чүбе тутырып, бараклар, мәктәп, мәдәният йорты, ашханә, мунча, элемтә бүлеге һәм башка объектлар төзелә. Бүген инде аларның барысы да диярлек юкка чыкса да, заманы өчен таш карьерының җиде участогында тәүлек дәвамында, өч сменада, хезмәт куйган алты йөзләп эшчегә болар һәммәсе яшәү чыганагы исәпләнә.

Шул шартларда сугыштан соңгы авыр елларда Чупай авылы янында таш җитештерү карьеры эшли башлый. Биредә киселгән таш үзенең ныклыгы белән аерыла (75-150 берәмлекне тәшкил итә; чагыштыру өчен: фабрикада җитештерелгән кирпечнең ныклыгы 75-100 берәмлек). Республика дәрәҗәсендә әһәмияткә ия чимал чыганагы заманы өчен бик мөһим була.

Күрәсең, әлеге кыйммәтле төзелеш материалын җирле халык инде күптән белгән. 1917 ел революциясенә кадәр зур булмаган ташчылар артеле бу таудан үзләренә кирәк кадәр таш кискән, аны эшкәртеп, амбар-келәтләр, сирәк кенә йортлар да төзегән. Кайберләре бүген дә исән. Авыл уртасында урнашкан, колхозлаштыру елларыннан соң озак вакыт «Идарә йорты», соңрак АТС һәм китапханә бинасы булып торган атаклы Әхмәт бай йортын да шундыйлардан.

Шуны да әйтергә кирәк: ул заман ташчылары җитештергән чималны чит төбәкләргә дә озаткан. Чупай ташыннан Бөгелмә шәһәренең байлары йорт салдыруы, тирә-юньдәге мәчет-чиркәүләрнең әлеге таштан булуы сер түгел.

1950 елның маенда Чупай таш карьеры рәсми рәвештә ачыла. 1950-1953

Таш төяүчеләр эш вакытында. 1952 ел

Таш кисүче бригада.1959 ел

елларда төзелеш материалы бары тик кул көче белән җитештерелә. Балта, кувалда, чөй, таш шомарткыч эшчеләрнең тәүге кораллары була. Киселгән ташның авырлыгы 39 килограммны тәшкил итә. Бу ташлардан Әлмәт шәһәре йортларының (халыкта — «финский дом») нигезе салына.

Ниһаять, 1953 елда Бакудан Чупайга таш кисә торган тәүге машиналар кайтартыла. 1954 елдан 1968 елга кадәр биредә өч сменада ял көннәрсез 500-700 кеше хезмәт куя. Көненә 1200 кубометр таш җитештерелә. Бер таш җиде кирпечне алыштыра.

1957-1961 елларда Чупай карьерында эшләгән чупайлы Антон Алексеев әлеге елларны болай искә ала: «Баштагы елларда ташны буйга кисә идек, тора-бара аны аркылы да кисә башладык. Таләп бик зур иде. Әгәр 19х19х39 сантиметрдагы стандарттан бер генә сантиметрга арттырсаң яисә киметсәң, 8 сәгатьлек эшең тулысы белән юкка чыкты дигән сүз. Без эш көне дәвамында 450 метрга кадәр озынлыкта таш кисә

Чупай авылында Әхмәт бай йорты. 2013 ел

Л.Гобәйдуллин фотосы

Әлмәт шәһәре үзәгендә Чупай ташыннан салынган йортларның берсе. 2013 ел

идек. Ике катлы әзер таш чыгып барганны да исәпләсәң, бу — 900 метр дигән сүз».

Шул рәвешле, Чупай авылы янындагы карьер нефть чыгару өчен мөһим насос, компрессор подстанцияләре, Әлмәт, Азнакай, Лениногорск, Бөгелмә, Зәй, Баулы, Казан шәһәрләрендәге торак йортлар, Казанның «Спартак» аяк киемнәре фабрикасы, Нурлат шикәр заводы һәм башка бик күп төзелеш объектлары өчен кирәкле таш бирә. Карьер кысаларында известь җитештерү дә алга киткән була.

Чупай һәм күрше-тирә авыллардан гына түгел, бирегә чит төбәкләрдән бик күп яшьләр күчеп кайта, хезмәт куя. К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрының абруйлы артисты Хәлил Мәхмүтов та хезмәт юлын биредә башлый. Чит җирләрдән күчеп килгән төрле милләт вәкилләренең кайберләре әле бүген дә Чупайда гомер кичерә, җирле халык белән тату мөгамәләдә тормыш итә.

Авылда Чупай ташыннан икекатлы ике йорт та салына. Аларның һәрберсендә сигезәр фатир. Бүген аларда 16 гаилә яши.

1968 елда, күрәсең, Түбән Мактама, Рус Акташы эшчеләр бистәсендә кирпеч, Әлмәт шәһәрендә тимер-бетон эшләнмәләр заводлары төзелү нисбәтеннән, Чупай ташы сыйфатсыз һәм аны җитештерү артык чыгымлы дип табыла. Шулай итеп, карьер да ябыла. Бүген әлеге урында Карьер күле җәйрәп ята. Ташны кискән урында бәреп чыккан чишмәләр суыннан хасил булган карьер күлендә кешеләр бүген рәхәтләнеп балык тота, су коена.

...Әлмәт, республика шәһәрләренең һәм тирә-як нефть җирлекләренең төзелеш нигезенә яткан Чупай ташы, һичшиксез, бер истәлек ташына лаек. 1950-1968 елларда Чупай тавыннан таш чыгарылуны без онытырга тиеш түгел.

Әдәбият

1. Вишневский Л.С., Шаргородский И.Е., Покровский В.А. Месторождения минерального строительного сырья в Альметьевском районе // Альметьевский район: проблемы историко-культурного наследия. Материалы Региональной научно-практической конференции. — Альметьевск, 1999. — 200 с. — С.177-178.
2. Кашапов Р. Авылым яме. — Алабуга, 1997. — 154 б.
3. Кашапов Р. Язмышлар кочагында. — Алабуга, 2002. — 146 б.

Фотолар автор архивыннан

МӘДӘНИЯТ АЛГА КИТКӘН ҺӘРБЕР ТӨБӘКТӘ ДӘ ҖИРЛЕ ХАЛЫКНЫҢ МАТДИ ҺӘМ РУХИ МИРАСЫН, АНЫҢ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘРЕН, АТА-БАБАЛАР ҖӘҮҺӘРЛӘРЕН САКЛАУЧЫ ҮЗӘКЛӘР — МУЗЕЙЛАР БУЛА. ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА МУЗЕЙЛАРНЫҢ КҮПЛЕГЕ, АЛАРГА ДӘҮЛӘТ ҺӘМ МУНИЦИПАЛИТЕТЛАР КҮРСӘТКӘН ЯРДӘМ МАКТАУГА ЛАЕК.

ХӘТЕР САГЫНДА

(ӘЛМӘТ ТУГАН ЯКНЫ ӨЙРӘНҮ МУЗЕЕ)

Әлмәт Сабан туенда Миңлебай авылы халкы. 1940 ел

Бер төркем колхозчы-әлмәтлеләр. 1930 еллар

Л.Гобәйдуллин фотосы

Л.Гобәйдуллин фотосы

Шундый алдынгы мәдәни учакларның берсе — Әлмәт шәһәренең туган якны өйрәнү музее. Ул, төбәктә музей эшен үстерү һәм тарихи, мәдәни истәлекләрне саклау максатыннан, 1993 елда Әлмәт районы һәм шәһәре карары, ТР Мәдәният министрлыгының боерыгы нигезендә оештырыла. Музейның беренче экспонатлары — Әлмәт шәһәренең 9 нчы номерлы мәктәбендәге ябылган музейның XIX — XX гасыр башына нисбәтле хезмәт һәм көнкүреш кирәк-яраклары — сука, туку станы, самовар, сандык, кием-салым, 1930 елларда кулдан тукылган әйберләр һ.б. Фондны баету максатыннан, Әлмәт шәһәре һәм авыллар буенча экспедицияләр оештырыла, Болгар, Тайсуган, Габдрахман, Иске Кади, Сөләй авылларыннан XIX гасыр — XX йөз башына нисбәтле тукылган паласлар, чигелгән сөлгеләр, бизәнү әйберләре, савыт-саба, көнкүреш предметлары җыела. Алар татар йорты интерьерын формалаштырганда, декоратив-гамәли сәнгать күргәзмәләрен оештырганда кулланыла. Музей коллекциясен туплау — Әлмәт районында яшәүчеләрнең гражданлык активлыгына үзенә күрә бер һәйкәл. Күп кенә предметларны шәһәр һәм авыл халкы бүләк итеп бирә. Эшне оештыруда музейның беренче директоры Л.Сөбханкулова (1993-1997), фәнни хезмәткәрләр З.Рәфикова һәм Э.Галкиналарның тырышлыклары бәяләп бетергесез. Шулай итеп, 1994 елның 18 маенда музей рәсми рәвештә ачыла. 1995 елның башына музей фондындагы ядкәрләрнең саны 633 данә саклау берәмлеге тәшкил итә.

Фондларны баету төбәктән чыккан мәгърифәтчеләр, шәһәр төзүчеләр, Әлмәтнең Шәрәфле гражданнары, атказанган нефтьчеләр, язучылар турында мәгълүматлар туплау юнәлешендә дә алып барыла. Фәнни эзләнүләр шәһәр администрациясе, республика архивларын өйрәнүдән тыш, шәхси архивлардан фотодокументлар, китаплар, хатлар, кыйммәтле гаилә ядкәрләрен җыю белән үрелеп бара.

2003 елның 30 августын музейның икенче туган көне дип тә атарга мөмкин. Музей яңа урынга — 677,5 кв.м.лы элеккеге ЗАГС бинасына күчерелә. Кыска вакыт эчендә Әлмәт шәһәренең 50 еллыгына һәм Татарстанда нефть чыгарыла башлауның 60 еллыгына багышланган экспозицияләр төзелә. 1997 елдан башлап бүгенге көнгә кадәр музей белән Зәйдуллина Винера Кыяметдин кызы җитәкчелек итә. Предметларны хисапка алу, саклау һәм музей гыйлеме бүлеген З.М.Идиятова белән Э.М.Гәрәева җитәкли.

Әлмәт туган якны өйрәнү музееның экспонатларында районда яшәгән халыкларның тарихы һәм мәдәнияте, XVIII гасырда кечкенә генә татар авылы булган Әлмәтнең Татарстан нефть башкаласына әверелүе яктыртыла.

Музей экспонатлары берничә бүлеккә урнаштырылган. Төбәкнең борынгы һәм урта гасыр тарихы, Иске һәм Яңа Чулман чик буе ныгытмалары турындагы бүлекләрдә район җирләренең таш гасырдан алып XVIII йөзгә кадәрге тарихы тәфсилле яктыртылган. Биредә Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге археологик картасы, әлеге җирлектә табылган мамонтның балтыр сөяге,

теш казнасы, бизонның баш сөяге һәм мөгезе, таштан, сөяктән, металлдан эшләнгән әйберләр, иллюстрацияләр, борынгы кешеләрнең яшәү урыннары схемасы һ.б. урын алган. Б.э.к. II меңьеллыкның урталарына нисбәтле Югары Акташ каберлегеннән туфрагы белән китерелгән бала кабере (мәетнең тулысы белән сакланган скелеты һәм азык тутырып җирләнгән савыт) төбәктә борынгы чорларда яшәгән кешеләрнең дөньяга карашларын тагын да җентеклерәк күзалларга мөмкинлек бирә. Шулай ук витриналарда Идел буе Болгар дәүләте чоры һөнәрчелек һәм сәүдә әйберләрен, XV-XVI гасырларга караган «Тайсуган хәзинәләре»н (эш кораллары, ат дирбиясе детальләре һәм казан), XVII-XVIII гасырларга караган Иске һәм Яңа Кама чик буе ныгытмалары схемасын, Әлмәт авылы турында иң тәүге язма мәгълүмат — мулла Әлмәт Сәетовның полковник И.В.Татищевка язган хатының рус телендәге күчермәсен күрергә мөмкин.

Музейдагы экспозицияләрнең зур өлеше XVIII гасыр — XX йөз башында аграр төбәк халыкларының көнкүрешен һәм традицион мәдәниятен чагылдыруга багышланган. Ир-ат һәм хатын-кыз якларына бүленгән традицион татар йорты интерьеры музейның күрке булып тора. Әлмәт ягы — татар, рус, чуваш, мордва һәм керәшен татарларының гомер бакый аралашып, дус-тату яши торган төбәк. Гасырлар дәвамында формалашкан халыклар һәм төрле дин тотучыларның үзара килешеп яшәүләре музей экспозицияләрендә дә чагылыш тапкан — аларның традицион киемнәре, бизәнү әйберләре аша экскурсоводлар халыклар дуслыгы турында сөйли.

Музейда XX гасыр тарихы, аеруча Совет дәвере, киң яктыртылган. Колхозлар оештыру кампаниясе, 1921-1922 еллардагы ачлык, 1941-1945 елларда әлмәтлеләрнең Ватан бәйсезлеге өчен сугышулары һәм тылдагы хезмәт батырлыгы, 1943 елда Шөгердә беренче тапкыр нефть чыгарылу, 1948 елда Ромашкино нефть ятмалары ачылу һәм 1953 елда Әлмәтнең шәһәр статусын алуы, аннан соңгы елларда илебез, республикабыз, район үсеше өчен зур хезмәтләр куйган данлыклы шәхесләрнең тормыш юлы күпсанлы экспонатлар аша күрсәтелә. Әлмәт нефтьчесенең 1950 еллардагы шәһәр фатиры интерьеры аерым экспозициядә күрсәтелсә, шагыйрә Саҗидә Сөләйманова бүлмәсенең эчке күренеше шул чор нефть каласында әдәби-мәдәни тормышны үстерүгә өлеш керткән татар зыялыларын фидакарь хезмәте турында хәтер яңарту үзәге булып тора.

Музей даими рәвештә төрле мәдәни чараларда катнаша. Әйтик, 2010 елда «Һәр буынның яшь парлары, берләшегез!» грант проекты кысаларында аерым залда экспозиция оештырыла. Әлмәтнең күп кенә парлары нәкъ менә шушы залда язылышуны өстенрәк күрә. Экспозициядә татар, рус, чуваш, мордва милләтләренең XX йөз башына һәм 1950-1990 елларга караган туй күлмәкләре тәкъдим ителгән. Музейга килүчеләр туй йолалары, кияү-кәләш киемнәре белән генә танышып калмый, ә алар өчен Әлмәт районында яшәүче милләт вәкилләренең туй сынамышлары һәм йолаларына бәйле мәдәни чаралар да уздырыла.

2011 елда музей хезмәткәрләре күргәзмәләр эшчәнлеге номинациясендә «Мин — оста» дип аталган проект белән Татарстан Республикасы хакимияте грантына лаек була. Бу проектның максаты — төбәктә милли мәдәниятне, һөнәрчелекне үстерү һәм музей фондын тулыландыру. Грант татар халкының декоратив-гамәли сәнгатенең бер күренеше булган нәфис керамиканы үстерү мөмкинлеген биргән. Музейга килүче өлкәннәр өчен — бер, балалар өчен алты чүлмәк әйләнәсе, махсус мич сатып алынган, «Сихри остаханә» исемле почмак та оештырылган. Кече яшьтәге

Колхоз бинасы төзелешенә почта алып килү. 1933 ел

мәктәп балалары өчен кызыл балчыктан төрле әйберләр ясау түгәрәге уңышлы гына эшли башлаган.

Фоторәсемнәр коллекциясе — туган якны өйрәнү музееның зур байлыгы. Бу хәзинә «Әлмәт — буыннар күзлегеннән» акциясе кысаларында шәһәр һәм авыллардан җыелган. 2012 елның 29 октябрендә башланып киткән акциянең инициаторы — Әлмәт муниципаль районы башкарма комитеты. Шулай итеп, музей фондына Әлмәт районының иҗтимагый-мәдәни тормышы, кешеләрнең хезмәте һәм көнкүреше турында 1932-2000 елларга нисбәтле 400дән артык фотодокумент туплана. Әлеге фотолар төрле күргәзмәләр һәм белешмә әдәбият эшләгәндә, төбәкнең үсеш-үзгәрешен чагылдыра торган мөһим чыганак буларак файдаланыла. (48 нче һәм 51 нче битләрдәге фотоларда әлеге акция нәтиҗәсендә тупланган мирас белән танышырга мөмкин.)

Туган якны өйрәнү музеендагы тагын бер, тарихи яктан шактый әһәмитле, уникаль экспонатка тукталып үтәсе килә. Ул — 1960 елның 22 апрелендә суга төшерелгән «Әлмәт» йөк ташый торган судносының (сухогруз) кыңгыравы. Балтик пароходчылыгына караган әлеге судноның юлы Төньяк диңгездән алып Төньяк Америка, Куба утраулары аша Көньяк Америкага кадәр сузылган булган. 25 елдан соң судно Кытайга металлоломга сатыла, ә кайбер предметлары елга порты музеена тапшырыла. Судноның капитаны булган Игорь Александрович Мальковскийның улы Ростислав Мальковский «Әлмәт. 1960» дигән язулы кыңгырауның металлоломга тапшырылуын күреп кала һәм аны сатып ала. Шулай итеп, егерме ел чамасы кыңгырау капитан улының Санкт-Петербург каласы янындагы дачасында саклана. Озак еллар флотта хезмәт иткән Ростислав Мальковский бу кыңгырау турында Әлмәт туган якны өйрәнү музеена хәбәр итә. СССР үсешенә зур өлеш керткән Татарстан нефтьчеләре хөрмәтенә «Әлмәт» дип аталып, океаннар гизгән судноның кыңгыравы бүген музей фондында саклана. Ул да — Әлмәт нефтьчеләренең данлы хезмәте турында бер тарихи ядкәр.

Гомумән алганда, музейда тарихи-мәдәни кыйммәткә ия 5700 данә предмет тупланган (01.01.2013 елга). Әлмәт туган якны өйрәнү музее милли мирасыбызны саклауда һәм аны халкыбызга җиткерүдә әйдәп баручы үзәк ролен башкара. Бирегә килгән һәр кеше үз җанына рухи азык таба, үткән буыннар турында хатирәләрен яңартып, киләчәккә олы максатлар куя.

***Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.*

Фотолар Әлмәт туган якны өйрәнү музее фондыннан

ӘЛМӘТ РАЙОНЫНДА ТӨБӘКЧЕЛЕК ГЫЙЛЕМЕНЕҢ ҮСЕШЕ

ӘЛФИЯ ГАЛЛӘМОВА,
тарих фәннәре докторы, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының баш гыйльми хезмәткәре

РОССИЯ ИҖТИМАГЫЙ ТИРӘЛЕГЕНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ СӘЯСИ ЯКТАН ДА, КӨНДӘЛЕК ТОРМЫШ ЯГЫННАН ДА ШАКТЫЙ КУПКЫРЛЫ ҺӘМ КАРШЫЛЫКЛЫ БУЛУЫ СЕР ТҮГЕЛ. БУ ҮЗЕНЧӘЛЕК ИЛДӘ ТӨРЛЕ ЦИВИЛИЗАЦИЯЛӘР БЕРГӘ ЯШӘҮ БЕЛӘН АҢЛАТЫЛА. ШУНЫҢ ӨЧЕН РОССИЯНЕҢ ҮТКӘНЕ ТУРЫНДА ФИКЕР ТУПЛАГАНДА, ТӨБӘКЛӘР ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮ БИК МӨҺИМ. ЛОКАЛЬ СИСТЕМАЛАРГА КАГЫЛЫШЛЫ ТАРИХИ ЭЗЛӘНҮЛӘР ТӨБӘКЛӘРДӘ НӘТИҖӘЛЕ СӘЯСӘТ ҮТКӘРҮ ӨЧЕН ДӘ КЫЙММӘТЛЕ НИГЕЗ БУЛЫП ТОРА.

Бу уңайдан «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыятенең соңгы ике дистә ел дәвамындагы эшчәнлеге мактауга лаек. Билгеле булганча, үз эшендә «Татнефть» берләшмәсе алгы планга табигатьне саклау, социаль һәм нефть төбәгендәге кешеләрнең тормыш шартлары проблемаларын куя. Мәдәният үсешенә дә даими игътибар бирелә. Дөньяда һәрбер халык үзенең тарихы, күренекле ватандашлары белән горурлана. Шуны истә тотып, «Татнефть» ААҖ һәрдаим халыкның рухи, интеллектуаль куәтен тергезү һәм үстерү турында кайгыртты һәм кайгырта.

Билгеле булганча, узган гасырның 90 нчы елларында, советлардан соңгы чорда, илдә төбәкчелек гыйлеменең кискен күтәрелеше күзәтелде. Әлеге күренеш, күптән калыплашкан кыйммәтләр революцион үзгәреш кичергән шартларда җәмгыятьнең үзен яңа социаль мәйданда табарга омтылып, дөньяны тануда таяну ноктасы итеп кече ватанны күрү белән аңлатыла дисәк, ялгыш булмас. Бу елларда Россиянең күп өлкә һәм аерым торак пунктларында төбәк тарихы буенча төрле дәрәҗәдәге басмалар дөнья күрде. Җәмгыятьтә төбәк тарихын яктырткан энциклопедияләргә ихтыяҗ көчәйде. Шушы уңайдан уз-

ган гасырның 90 нчы еллар урталарында «Татнефть» ААҖ һәм Әлмәт шәһәре админстрациясе инициативасы белән «Әлмәтнефть» нефть-газ чыгару идарәсе базасында «Әлмәт энциклопедиясе» иҗат төркеме оештырылды. Бу иҗат төркеменең эшчәнлеге, һич кенә дә арттырусыз, Татарстанның нефть чыгару төбәге тарихын өйрәнүгә фәнни нигез салды.

Иҗат төркеменең үзәген нефть чыгару төбәге тарихын өйрәнү әйдәманы Р.Х.Әмирханов җитәкчелегендәге җирле белгечләр тәшкил итте. ТР Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты каршында «Әлмәт энциклопедиясе»нә теләктәш Казан үзәге оештырылды. Бу үзәк Казан архивларындагы чыганакларны барлау, туплау һәм Әлмәт районына фәнни экспедицияләр оештыру белән шөгыльләнде.

«Әлмәт энциклопедиясе» эшли башлаганчы, төбәкнең борынгы һәм урта гасырлар тарихы буенча гомуми күзаллаулар белән чикләнелә иде. Әлеге өлкәдә фәнни-эзләнү эшләре күренекле археолог, тарих фәннәре докторы Е.П.Казаков һәм аның укучысы, тарих фәннәре кандидаты Земфира Рафикова тарафыннан актив алып барылды.

Археологик тикшеренүләрнең нәтиҗәләре буенча, Көнчыгыш Чулман аръягының борынгы тарихын яктырткан фәнни-популяр китап басылды [1]. Китапта Дала Зәе, Шушма елгалары, шулай ук Шушма, Кичү һәм Баграж елгаларының уң як кушылдыклары буенда ачылган барлык археологик ядкәрләрнең тасвирламалары бирелгән. Нәтиҗәдә, әлмәтлеләр таш, бронза, тимер гасырның башлангыч дәверендә һәм шулай ук урта гасырларда ата-бабаларының яшәеше турында фәнни күзаллау мөмкинлеге алды.

Россиядә XVIII-XIX гасыр сәнәгать оешмалары бик сирәк очракта гына археологик өйрәнү объектына әйләнә. Әйтик,



Әлмәт – Альметьевск: Посвящается 50-летию образования города Альметьевска. – Казань: Идель-пресс, 2003. – 740 с.

Көнбатыш Европа илләрендә мондый ядкәрләрне күптәннән уңышлы казыйлар, эзләнүләр техника, сәнәгать һәм көнкүреш тарихына нисбәтле, шулай ук ядкәрләрнең археологик тәртиптә урынын билгеләү мәсьәләләре буенча бай материал бирә. Энциклопедияне хәзерләү кысаларында, тарих фәннәре кандидаты И.Л.Измайлов җитәкчелегендә 1759 елда Кичү елгасы буенда эшли башлаган Боголовски бакыр эретү заводы хәрабәләрендә археологик казу эшләре экспедициясе оештырылды. Казу эшләре барышында бакыр эретү миче калдыклары, бакыр эшкәртү өчен ясалган күп сандагы чүкеч ватыклары, кайбер эш кораллары (сөймән, тау чүкечке һ.б.) табылды.

Филология фәннәре докторы М.И.Әхмәтҗановның күпсанлы фольклор экспедицияләре нәтиҗәсендә бай фольклор материал тупланды: төбәкнең танылган шәхесләре, шагыйрьләр, халык батырлары, авылларга нигез салучылар турында кыйммәтле риваятьләр,

этнонимик һәм тарихи легендалар, мәзәкләр җыелды. М.И.Әхмәтҗанов төбәктә табылган нәсел шәҗәрәләрен беренче тапкыр системалаштыру, тасвирлау һәм анализлау буенча зур эш башкарды. Аның тарафыннан җыелган йөзләрчә кулъязма һәм басма китап, 60 нәсел шәҗәрәсе ТР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханәсендә саклана. Бу мирас, шулай ук галим теркәгән меңнән артык татар, рус, чуваш, мордва эпиграфик истәлекләре татарның этник һәм бу төбәк халыкларының тарихлары буенча дистәләгән фәнни мәкаләләр, ике китап язуга нигез булды [2].

Сәнгатьне комплексны өйрәнү экспедицияләре тарафыннан халыкның декоратив сәнгате, архитектурасы һәм музыкасы буенча бай чыганаклар тупланды. «Әлмәт энциклопедиясе»н язу Әлмәт районында халык сәнгатен тикшерә башларга мөмкинлек бирде.

Шулай ук төбәктә көн итүче татарларны төрле яктан өйрәнү максатыннан, диалектологик экспедицияләр дә оештырылды. Бу экспедицияләр эшчәнлеге нәтиҗәсендә, гаилә һәм календарь йолалар, аларның атамалары, туган-тумачалык терминнары, кием-салым һәм бизәнү әйберләренең исемнәре, көнкүреш лексикасы — савыт-саба, азык-төлек (ритуал һәм көндәлек ризык), үсемлек исемнәре, Сабантуй һәм Җыен бәйрәмнәре турында мәгълүматлар җыйналды. Филология фәннәре докторлары Д.Б.Рамазанова һәм Ф.С.Баязитова тарафыннан тупланган бай чыганакларны анализлау һәм гомумиләштерү нигезендә, шулай ук яңа фәнни хезмәтләр дөнья күрде [3].

Гомумән алганда, «Әлмәт энциклопедиясе»н әзерләү барышында, 20дән артык аерым фән тармагын һәм төрле юнәлешләрне колачлаган комплексны экспедицияләр уздырылды. Район җирлегендәге тарихи-мәдәни мирас ядкәрләре барланды: саклану сызыклары, төбәк тарихындагы күренекле вакыйгалар, онытылган яңа шәхесләр, төбәкнең үткәненә бәйле кайбер вакыйгаларны яңача аңлатырга мөмкинлек биргән фактлар һәм дәлилләр ачыкланды.

Республиканың көньяк-көнчыгышы — Татарстанның башка төбәкләреннән үзгә, үзенчәлекле табигый һәм географик зона да ул. «Әлмәт энциклопедиясе», районның табигатен һәм географиясен өйрәнү максатында, 1999-2002 елларда дүрт экологик экспедиция уздырды. Алар туплаган мәгълүматлар Татарстан Республикасының көньяк-көнчыгыш төбәге табигатен җентекләп һәм төрле яктан яктырткан «Әлмәт энциклопедиясе»нең беренче томын язарга нигез булды [4].

«Әлмәт энциклопедиясе» иҗат төркеме архивларда да киңкырлы фәнни эзләнү алып барды. Моңа кадәр фәнни әдәбиятта төбәкнең XVIII-XIX гасырларга караган тарихы чагылыш тапмаган иде. Республикабыз галимнәре әлеге дәверләрне өйрәнгәндә, гадәттә, фәкать Казан шәһәренә һәм Казан арты төбәгенә игътибар бирделәр. Бу күренеш, барыннан да бигрәк, язма чыганакларның Мәскәү, Санкт-Петербург, Самара архивларында саклануы, аларны фәнни әйләнешкә кертүнең шактый зур чыгымнар таләп итүенә бәйле булды. Шуңа күрә архивларда эшләү белән бәйле барлык транспорт, чыганакларның күчермәләрен алу, экспедиция чыгымнарын «Әлмәтнефть» нефть-газ чыгару идарәсе каплады.

Шушындый хезмәттәшлек нәтиҗәсендә, Татарстанның көньяк-көнчыгышына халык күченүен, демографик барышны өйрәнү өчен мөһим булган бай архив чыганаклары фәнни әйләнешкә кертелде. Төбәктәге яңа җирләр күпләп сөрелү, почта һәм сәүдә трактлары салыну, яңа һөнәрчелек тармаклары барлыкка килү, ярминкәләр оештырылу, беренче тапкыр нефть



Әхмәтҗанов М.И. Үлгәннәрнең каберен бел. – Казан, 2000. – 158 б.



Проблемы изучения истории заселения и образования населённых пунктов Альметьевского региона: Сборник статей. – Казань, 2000. – 208 с.

(Нәдер Уразмәтов) һәм металлар (И.Глазовның бакыр эретү «заводы») табарга омтылыш, халык баш күтәрүләре һәм социаль конфликтлар кабыну (1704-1711, 1735-1740 еллардагы татар-башкорт восстаниеләре, 1773-1775 елларда Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге крестьяннар сугышы, 1885 елда Сөләй авылы бунты) шартларында икътисадның бу чорда тиз үсеп китү үзенчәлекләре ачыкланды.

Татарлардагы мәктәп-мәдрәсәләр, башка халыклардагы земство, чиркәү-мәхәллә, миссионерлык, министрлык (Халык мәгарифе министрлыгына караган) мәктәпләре аша ул чор мәгариф системасын күзаллау мөмкинлеге туды. XVIII-XIX гасырларга караган вакыйгаларны фәнни тикшерүнең бер нәтиҗәсе булып төбәкнең беренче карталарын өйрәнү тора. Архивларда эзләнүләр бу гасырларда Әлмәт төбәге белән бәйле тарихи шәхесләрнең эшчәнлеген тулырак яктырту мөмкинлеген тудырды. Шундый шәхесләрнең берсе — Идел-Урал төбәгендә нефть чыгару өлкәсендә беренче адымны һәм тәҗрибәне ясаган Нәдер Уразмәтов. Архивлардагы фәнни тикшеренүнең тагын бер мөһим нәтиҗәсе Әлмәт авылына нигез салыну датасын ачыклау булды.

XX гасыр вакыйгалары турында мәкаләләр язганда, Татарстан Республикасы архивларын өйрәнү киң колачлы оештырылды. Нигездә, ТР Үзәк дәүләт тарихи-сәяси документлар һәм ТР Милли архивлары фондлары документлары өйрәнелде. Аерым темаларны, проблемаларны яктыртканда, Дәүләт куркынычсызлыгы комитеты һәм Эчке эшләр министрлыгы архивлары материаллары файдаланылды. Шулай ук Әлмәт районы оешмалары архивлары, хәзер аның составына кергән элекке Акташ, Ямаш архивлары тикшерелде. Эзләнүләр районга караган гомуми пландагы чыганаклар буенча

гына түгел, ә аерым хуҗалыклар, оешмалар һәм торак пунктларның үткәне белән бәйле документлар аша алып барылды. Район, авылларның тулы, тәфсилле тарихын язу максатында, барлык торак пунктларга бәйле архив чыганаклары өйрәнелде, юкка чыккан авыллар турында махсус сораштырулар үткәрелде. Әйтергә кирәк, хәзерге Әлмәт районы җирлегендә барлыгы 160 торак пункт булган, бүген шуларның 100е яшәвен дәвам итә.

Тарих — тормыш мөгаллиме, дигән гыйбарә бар. Җәмгыять аннан хакыйкатьне матур итеп кенә яктыртуны көтә алмый. Узган вакыйгалар безнең хөкемгә яки хуплауга мохтаҗ түгел, әмма алар безгә шул чорларда килеп чыккан социаль проблемаларны аңларга мөмкинлек бирә ала. Тарихыбызның кара сәхифәле битләре турында оялып дәшми калу кешеләрдә гражданлык җаваплылыгын үстерергә һич кенә дә ярдәм итми. Шуңа күрә Әлмәт районындагы күмәкләштерү кампаниясенең фаҗигале сәхифәләрен аерым китапта яктыртырга карар кылынды [5]. Бу китап, басылып чыгу белән, иң кадерле хезмәтләрнең берсенә әверелде, аңа ихтыяҗ Әлмәт районында гына түгел, ә башка, ерак төбәкләрдә дә күзәтелде.

Мисал өчен, «Әлмәт эше» турындагы китап хакында уңай бәяләмәләр ишетеп, Россия Фәннәр академиясенең Россия тарихы институты директоры А.Н.Сахаров Казан мэриясенә, бу хезмәтне җибәрүләрен үтенеп, хат яза. Галим, постсовет чоры тарихи әдәбиятына аналитик күзәтү ясаганда, әлеге китапны совет чорына караган историографиянең иң мөһим уңышларыннан берсе дип атады. Әйтергә кирәк, ул Татарстанда басылып, А.Н.Сахаров тарафыннан игътибарга алынган бердәнбер китап булды.

Совет чоры әдәбияты дәшми калган, анда яктыртылмаган тарихи сюжетларга җентекле игътибар биреп, без төбәкнең совет дәверен тискәре яктан күрсәтергә омтылмадык. Әлмәтлеләрнең тыныч хезмәттә һәм сугышта уңышлары, аеруча талантлы җитәкчеләрнең, белгечләрнең, җәмгыятьтә ихтирам казанган кешеләрнең эшчәнлекләре яктыртылды. Һичшиксез, үзәк урында нефть сәнәгате үсешен, аның төбәк тарихындагы ролен күрсәтү торды. Энциклопедик басманы әзерләү кысаларында язылган һәм дөнья күргән фәнни мәкаләләрдә, китапларда бу темалар өлешчә чагылыш тапты [6].

«Әлмәт энциклопедиясе»н хәзерләү барышында уздырылган фәнни-тикшеренү эшләре, экспедицияләрдә һәм архивларда тупланган күп сандагы яңа чыганаклар белгечләрне җәлеп итеп тикшерүне таләп итте. Шул максат белән 1999-2003 елларда 5 фәнни-гамәли форум — Әлмәт шәһәрендә өч конференция һәм Тарих институты гыйльми шурасының ике мәртәбә киңәйтелгән утырышы уздырылды. Аларда «Татнефть» ААҖ, «Әлмәтнефть» нефть-газ чыгару идарәсе, шәһәр администрациясе җитәкчеләре, Казан шәһәре фәнни оешмаларыннан танылган галимнәр катнашты. Докладчылар арасында ТР ФА Тарих институтының директоры Р.С.Хәкимов, галимнәрдән А.Ә.Борһанов, И.Р.Таһиров, Э.Р.Таһиров, М.Г.Госмановлар бар иде. Конференцияләрнең җыентыклары басылып чыкты [7].

«Әлмәт энциклопедиясе» грифы белән барлыгы 20 фәнни һәм фәнни-популяр басма нәшер ителде. Алар арасында 2003 елда Әлмәт шәһәренә нигез салынуның 50 еллыгы уңаеннан дөнья күргән «Әлмәт — Альметьевск» китабы аеруча игътибарга лаек [8]. Бу китапта җәмгыятьнең һәм кешеләрнең күпкырлы эшчәнлеге яктыртылган, социаль тормыш төрле каршылыклары һәм катлаулылыклары белән ачылган. Гомумән, китап гуманитар тикшеренүләр методологиясе өлкәсендәге соңгы казанышлар нигезендә язылган. Халык арасында әлеге китапны еш кына «Әлмәт

энциклопедиясе» дип тә атыйлар. Дөрестән дә, белгечләрнең һәм фәнни җәмәгатьчелекнең бәяләве буенча, бу күмәк хезмәт — тарих, мәдәният, икътисад мәсьәләләрен киң колачлавы һәм тирәнлеге ягыннан төбәкчелек әдәбиятында республикабызда гына түгел, ә Россиядә бердәнбер шундый басма.

Китапта төбәкнең табигате турында да бай мәгълүмат табарга мөмкин, биредә Әлмәтнең шәһәр статусын алганчыга кадәрге тормышы тулы яктыртылган, шулай ук хаклы рәвештә республикабызның нефть башкаласы исемен йөртүче Әлмәт шәһәренең иң яңа тарихы да дәлилле күрсәтелгән. Язмышлары Әлмәт белән тыгыз бәйләнгән, шәһәрнең шәрәфле гражданнары исемен йөрткән шәхесләр турындагы язмалар да зур әһәмияткә ия. Китап күпсанлы иллюстрацияләр белән баетылган, хронология һәм исемнәр күрсәткечләре бирелгән.

Басма универсаль белешмә характерында булуга карамастан, иҗат төркеменең шактый башкарган хезмәтләре калды, алар энциклопедиянең икенче томында урнаштырылачак дип уйланылган иде. Бүген 1000 бит чамасы җыелган һәм анализланган материаллар әле дә каралама хәлендә. Шул сәбәпле киң җәмәгатьчелеккә нефть чыгару төбәге турындагы бөтен тулылыгы белән фәнни нигезләнгән мәгълүматларны җиткерү мөмкинлеге кулдан ычкындырыла. «Татнефть» ААҖ һәм Әлмәт шәһәре администрациясе җитәкчелеге идеясе нигезендә хәзерләнгән фундаменталь хезмәтнең мәдәни-тәрбияви мөмкинлеге файдаланылмый ята.

Беркем өчен дә сер түгел: бүгенге яшьләр, туган як, туган авыл тарихына караганда, Россия һәм Көнбатыш илләр тарихын яхшырак белә. Ләкин булачак гражданнар тарихи барышта үз урыннарын аныклый алсын өчен, тарих дәресләрендә төбәкчелек элементлары, һичшиксез, булырга тиеш. Нәкъ менә тарихка үзеңнең катнашың булуны тою, узган буыннарның эшләренә хөрмәт белән карау, туган як белән горурлану, аның язмышына битараф булмау шәһәрнең мәдәни йөзен билгели.

Әдәбият

1. Казаков Е.П., Рафикова З.С. Очерки древней истории Восточного Закамья. — Казань, 1999. — 120 с.
2. Әхмәтҗанов М.И. Дастаннар ватаны. — Казан, 1999. — 158 б.; Әхмәтҗанов М.И. Үлгәннәрнең каберен бел. — Казан, 2000. — 158 б.
3. Рамазанова Д.Б. Татары Восточного Закамья: их распространение, особенности говора. — Казань, 2001. — 207 с.; Баязитова Ф.С. Татары Альметьевского края. — Казань, 2001. — 287 с.
4. Альметьевская энциклопедия. Юго-восточный регион. — Т.1. Природа. — Казань, 2006. — 455 с.
5. Альметьевское дело. Трагические страницы из истории крестьянства Альметьевского района (конец 20-х — начало 30-х гг.) Сборник документов и материалов. Составители А.Г.Галлямова, Р.Н.Гибадуллина. Вступит. статья «Альметьевщина» — горький урок коллективизации, А.Г.Галлямовой — Казань, 1999. — 192 с.
6. Уразманова Р.К. Быт нефтяников-татар юго-востока Татарстана. 1950-1960 гг. — Альметьевск, 2000. — 158 с.; Амирханов Р.Х. История нефтепромысла «Миннибаево». Нефтепромысел №2 треста «Бугульманефть», 1950-1952 гг. — Казань, 2000. — 192 с.; Назипова К.А. Татарские нефтяники: начало большого пути. — Казань, 2004. — 152 с.
7. Альметьевский регион: проблемы историко-культурного наследия: Тезисы выступлений научно-практической конференции. — Альметьевск, 1999. — 200 с.; Альметьевский регион: проблемы историко-культурного наследия: Сборник статей. — Альметьевск, 1999. — 240 с.; Проблемы изучения истории заселения и образования населённых пунктов Альметьевского региона: Сборник статей. — Казань, 2000. — 208 с.
8. Әлмәт — Альметьевск: Посвящается 50-летию образования города Альметьевска. — Казань: Идель-Пресс, 2003. — 740 с.

Русчадан ***Ленар Гобәйдуллин*** *тәрҗемәсе*

СУФЫЙ БУЛАРАК ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ*

СӘЕД ДАМИР ШАҺАБИ,
фәлсәфә фәннәре кандидаты, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының иҗтимагый фикер тарихы һәм исламны өйрәнү бүлеге мөдире

Шиһабетдин Мәрҗанинең үзенең тарихи-биографик хезмәтләрендә йөзләрчә шәех һәм галим телгә алынган. Кагыйдә буларак, ул ишан һәм шәехләрне яхшы яктан искә алган һәм суфыйчылыкка каршы чыкмаган. Еш кына Ибне әл-Гарәби хезмәтләреннән өзекләр китерә, аның турында зур хөрмәт белән искә ала. Үзенең «Вафийат әл-әслаф...» китабында: «Бу кеше, Аллаһы рәхмәте белән, хакыйкать диңгезе, галимнәрнең горурлыгы, тәкъва мөэмин иде. Ул Коръән һәм Сөннәтне бик яхшы белә иде, аның шәригать һәм дөньяви гыйлемнәрдә белемнәре зур иде. Анда кайвакыт бөек илһам балкышлары була торган иде...» [41], — дип яза. Баһаветдин Нәкшбәнд турында да яхшы сүзләр генә язып калдырган: «Ул — иң атаклы суфый шәехләренең берсе, үз заманының иң күренекле укымышлыларыннан, Нәкшбәндия тарикате башлыгы иде... Аның юлы һәм фикерләре хак диндә, шәригатькә туры килгән, батыйллыкка каршы фикерләр иде ... Бездә аның тарикате белән бәйләнеш бар...» [42]. Мәрҗани татар суфыйлары турында да язып калдырган. Мәсәлән, Әбү Мөхәммәд Касыйм әл-Казани (1581 елда вафат) турында: «Танылган суфый шәехләреннән берсе, үз чорында тугры юлда торучы күренекле кешеләреннән берсе иде. Диндарлык, дин тоту, тәкъвалык мәсьәләләре буенча аңа мөрәҗәгать итәләр иде... Исеме дан алган, бик билгеле кеше иде, аны олылыйлар һәм хөрмәт итәләр иде, Болгардан, Мәвараэннәһердән, Хәрәземнән аңа килә торган иделәр... Ул бөек шәех Габделвәли әл-Кухзари тарикате тарафдары булып китте...» — дип искә ала [43]. Үзенең дини хезмәтләрендә Мәрҗани Ибне әл-Гарәбинең «әл-Футухат әл-мәккиййа» («Мәккәдәге илһам балкышлары»), әл-Җәминең «ад-Дурра әл-фахира» («Данлы энҗе бөртекләре»), Әбү Нугайманың «Хилйат әл-әулийә» («Изгеләр бизәкләре»), әл-Газалиның «әл-Мөнкыз мина-д-далал» («Заләләттән коткаручы»), әл-Мәккиның «Кот әл-кулюб» («Күңел азыгы»), әс-Сирхиндинең «Мактубат мөҗәддидийә» кебек танылган сафиларның әсәрләреннән өзекләр китергән.

1898 елда Мәрҗанинең хаҗ сәфәрен тасвирлап язган «Рихләт әл-Мәрҗани» исемле китабы басылып чыга [44]. Истанбулда булганда, ул Әбү Әййүбә әл-Әнсари (пәйгамбәребез Мөхәммәднең (аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!) сәхабәсе) мәчетендә, аның каберендә, пәйгамбәрнең (аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!) шәхси әйберләре сакланган урыннарда була.

* Ахыры. Башы 7 нче санда.

Әл-Искәндәриядә ул танылган суфый әл-Босайри мәчетендә була. Боларга Мәрҗани гади бер кызыксыну белән генә килеп йөргән булырга тиеш түгел. Каһирәдә дә ул танылган мәчетләрдә һәм зиратларда булып, анда догалар кылган. Мәдинәдә ул Пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!) һәм аның кызы Фатыйма җирләнгән урында булып, анда да дини йолалар башкарган [45]. Шул ук шәһәрдә Мәрҗани тәсаувыф өлкәсендәге өченче остазы булган Мәзһәр шәехне очрата. Бу китапта сурәтләнгән вакыйгалар 1880 елда була. Бу язмаларга нигезләнеп без олы татар галименең гомере азагына кадәр суфыйлар тәртибе буенча яшәгәнлеге турында фикер йөртә алабыз, ягъни ул гомере буена суфыйчылык традицияләренә тугры булып калган.

Мәрҗани китапларында суфыйчылыкны, аеруча аның кеше теләкомтылышлары, үз кимчелекләре белән көрәшүдә корал булу ягын югары бәяләгән. Бу мистик юл Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһының хәер догасы һәм сәламе булсын!) сәхабәләре (әсһаб) һәм аларның дәвамчылары юлына (табигун) туры килә дип раслаган.

Мәрҗани хезмәтләрендә еш кына суфыйларның Аллаһы Тәгаләне танып белү өлкәсендә фәкый һәм мөтәкәллимнәрдән өстенрәк икәнлекләрен ассызыклап әйткән, суфый галимнәре идеяләрен башка дини галимнәр идеяләреннән өстенрәк күргән. Ибне Халдун кебек үк, ул суфыйчылыкны (тәсаувыфны) шәригать фәннәренең берсе дип исәпләгән һәм бу турыда үзенең «Мөкаддимат вафийат әләслаф фа тахият әл-әхлаф» хезмәтендә җентекләп аңлаткан. Шәһәр Шәрәф язганча, Ш.Мәрҗани шәкертләргә тәсаувыф белән шөгыльләнергә дә комачаулык ясамаган, аларга ишаннарны мактап сөйли торган булган [46]. Мөридләренең аз санлы булуыннанмы, әллә инде аның үзенең исламга карата алган аерым позициясе нәтиҗәсендәме, Мәрҗани суфый шәех буларак танылу алмаган. Казанда 1915 елда нәшер ителгән «Мәрҗани» җыентыгы авторларыннан берсе Габдрахман Гомәри Мәрҗанинең, гомумән, мөридләре юк иде, дип яза. Ул Габдрахман бине Гомәр әл-Әстерхани атлы бер Коръән укучының (карыйның) сүзләрен дәлил итеп китерә. Дагыстаннан булган Мәхмүд ишан бу карый үткәргән мәҗлесләрнең берсендә Шиһабетдин Мәрҗанинең, мистик юлда шулкадәр югары дәрәҗәгә ирешеп тә, мөридләр тәрбияләмәвенә гаҗәпләнүен белдерә. Мәрҗани вакыты җитмәү белән аклана [47]. Бу сүзләр Мәрҗанинең мөридләре булмавын һич кенә дә дәлилләми, чөнки башка мәгълүматлар моның киресен сөйли. Бу мәгълүмат бары тик аның рухи шәкертләре аз булуын, суфыйның мөршидләр белән даими рәвештә шөгыльләнмәгәнлеген дәлилли. Шуңа да кайбер замандашлары Ш.Мәрҗани суфыйчылыктан читтә торган, дип яза [48]. Г.Гомәри, үз фикерләрен башкаларның сүзләре белән ныгытып, Мәрҗани шәкертләренә махсус суфый вирдларын (билгеле бер дога һәм Коръән аятьләрен) укырга мәҗбүр итмәгән дип раслый. Чынлыкта бу мантыйкка туры килә, чөнки әлеге шәкертләр аның мөридләре булып саналмаганнар. Шул ук вакытта Габдрахман Гомәри шәкертләр үз мөгаллимнәренең һәркөнне вирд укыганын күргәннәре турында хәбәр итә, Мәрҗанинең, гадәттә, мәҗлесләрдә, билгеле бер очракларда һәм һәркөнне намаздан соң укый торган Коръән аятьләрен һәм сүрәләрен санап үткән. Ягъни Габдрахман Гомәри Мәрҗанинең вирды бары тик Коръән уку гына, суфыйларның махсус зикер әйтүенә бер дә охшамый иде, дип әйтергә теләгән. Ә без Мәрҗани андый зикерне үзе генә

Элекке Мәрҗани мәдрәсәсе бинасы. Казан, хәзерге З.Солтан урамы, 4 нче йорт. 2010 ел

калганда, беркем дә күрмәгән вакытта укыган, дип әйтә алмыйбызмы? Аятьләр уку суфый вазифасының бер өлеше булырга мөмкин, ул рухи күнегү буларак башкарыла. Габдрахман Гомәри Мәрҗанинең суфыйчылыкка карашын тасвирлаган бүлек азагында аның ишаннарга карата тискәре карашта булуы хакында да хәбәр итә. Бервакыт Мәрҗани төрки телләрдәге «ышанмак» фигыленең боерык формасына («ышан!») ишарәләп, ниндидер бер ишан сүзләренә җавап итеп: «Алар үзләренә «ишан» дип яхшы ат кушканнар», — дип әйтүен яза [49]. Шуннан соң ул «Мөкаддимат вафийат әл-әслаф фа тахият әл-әхлаф»тан ишаннарны тәнкыйть иткән, аларны мөселман җәмгыятенең бәлаләрендә һәм аның артта калуында гаепләгән бер өзек китерә. Ләкин бу очракта Мәрҗанинең тәнкыйте бары тик байлык һәм хакимлек максатларында үзләрен ялган суфый шәехе итеп күрсәткән ишаннарга, ягъни икейөзлеләр һәм шарлатаннарга гына кагылган. Ә ул вакытта андыйлар аз булмаган, күрәсең. Ул, әлбәттә, атаклы суфый шәех абруйларын күз алдында тотмаган.

Шәһәр Шәрәф сүзләренә караганда, Ш.Мәрҗанинең суфыйчылыкка чакыруы яки тарикатькә керергә үгетләве турында мәгълүматлар юк [50]. Ул шәкертләргә күбрәк Коръәнне укырга, аның мәгънәсен аңларга тырышырга киңәш итә иде, дип яза [51]. Беренче карашка, Мәрҗани тарикатькә керергә каршылык күрсәткән кебек тә тоелырга мөмкин. Ләкин бу алай түгел. Шулай итеп, безнең фикер буенча, Ш.Мәрҗани кешеләрне суфыйчылык практикасыннан аермаган гына түгел, ә тәкъвалыкка җиңелрәк юлны күрсәткән һәм, Аллаһы Тәгалә белән мөнәсәбәтләр ягыннан караганда, тарикать юлы буенча баруның кеше өчен бик җитди сынау булуын аңларга мөмкинлек биргән. Суфыйчылык юлын кабул итеп тә, аннан кире тайпылуга караганда, бу юлга бөтенләй басмауны күпкә яхшырак дип исәплиләр [52].

Икенче яктан карганда, һәрбер мөселман да суфый булырга лаек та түгел һәм һәрбер кеше дә мөрид булу өчен зарур бар сыйфатларга да ия була. Тәсаувыфны тикшерүчеләргә классик суфыйчылыкта бары тик

сайлап алынган аерым кешеләрнең генә суфыйлар булып китүләре һәм тарикатькә фатиха алулары билгеле. Алда әйтеп кителгәндәге кебек, күпләр шәехләрдән бары тик сабаклар алу белән генә чикләнә, чөнки андый җитди адымга барырга, диндарлыкның җитеп бетмәве сәбәпле [53], әзер түгелләр. Шуңадыр да инде, мөгаен, тарикатьне ике төргә бүлү гамәлдә: саликун (Аллаһны тану юлындагы мистик суфыйлар), мөтәбарикун (фатиха алырга теләүчеләр). Соңгылары тарикатьнең пассив әгъзалары булып торалар, тарикатьне камиллеккә һәм рухи тазарынуга илтә торган юл итеп кабул итәләр, тик аның бар мөмкинлекләрен дә файдаланып бетермиләр [54].

Мәрҗани Коръән укуга зур әһәмият биргән, башкаларны да шуңа өндәгән. Исламда Коръәнне уку сөннәт эш булып исәпләнә. Моның савап гамәл икәнлеге турында күп кенә хәдисләр бар. Ислам дине турындагы әдәбиятта андый укуның мөселманнарга бар яктан да уңай тәэсир итүе турында сөйләнә. Күп шәехләр Коръәнне башыннан алып ахырына кадәр күп тапкыр укып чыгарга тәкъдим итәләр [55]. Мәрҗанинең замандашлары аның бер көн эчендә өч җөзьә (Коръәннең 1/30 өлешен), ягъни бер ай дигәндә Коръәнне өч тапкыр укып чыкканлыгы турында искә алалар [56]. Шуның өстенә, бер җөзьәне биш тапкыр намаз вакытында укыганлыгын сөйләп калдырганнар [57]. Шәһәр Шәрәф шундый бер кызыклы вакыйга турында сөйли. Мәрҗанинең шәкертләреннән булган Гыймран бине Сәгыйд әл-Багиши мулла, тарикатькә керергә теләк белдереп, галимнән иң камил суфый остазның (мөршид камилнең) кем булуын күрсәтүне сорый. Мәрҗани аңа: «Иң яхшы мөршид — Коръән. Көн саен бер җөзьәдән дә ким булмаган өлештә Коръәнне укыгыз. Укыган вакытта мәгънәсен аңларга тырышыгыз. Тулылык өчен ышанычлы берәр Коръән тәфсире дә алып укыгыз. Һәм шул сезнең мөршидегез булыр», — дигән [58]. Габделхәмит Мөслими, «Шура» журналында бу өзекне [59] шәрехләп, Мәрҗанинең әлеге сүзләре аның суфыйчылык һәм суфыйчылык тарафдарлары турында уңай мөнәсәбәттә әйтелгән башка сүзләренә каршы килми, дип аңлата. Алга таба ул Мәрҗанинең бер шәкерте аннан шулай ук камил мөршидне әйтүен үтенгәне турындагы хикәят китерә. Мәрҗанинең җавабы алдагысына охшаган була, тик ул бу юлы: «Әгәр дә безнең заманда чын (хакыйкый) мөршид булса, мин үзем аннан башка тора алмас идем», — дип өсти. Габделхәмит Мөслими бу мәгълүматны Мәрҗанинең төп биографы Шәһәр Шәрәфкә әйтүе, ләкин аның билгесез сәбәпләр аркасында бу сүзләрне төшереп калдыруы турында билгеләп үтә.

Югарыда сөйләнгәннәрдән шул ачыклана: Мәрҗани үзе яшәгән чорда югары рухи дәрәҗәләргә ирешкән шәехне күрмәгән. Аның рухи остазы Габделкадыйр бине Нийаз ул вакытларда инде вафат булган була һәм шуңа күрә дә камил мөршид эзләүчеләрне аңа җибәрү мөмкинлеге булмый. Бу сүзләргә нигезләнеп, без Мәрҗани үз заманы шәехләре һәм ишаннарының барысыннан да күңеле бизгән, алай гына да түгел, чын мөршидләр заманы инде тәмам булды дип белдергәнен раслый алмыйбыз. Ә Габделхәмит Мөслими нәкъ менә шуны исбат итәргә теләгән дә. Аның фикеренчә, чын суфыйчылык турында кайбер бозык фикерләр барлыкка килгән соңгы чорларда инсанның суфыйлыгына [60] карап хөкем йөртеп булмый.

Суфыйчылык әдәбиятында мөршид һәм шәехләр заманы хисаб көненә кадәр дәвам итәчәк, дип языла. Бу җәһәттән Нәкшбәндия тарикате тарафдарларыннан булган авторлар әр-Раббани әс-Сирхинди имамның: «Минем мөридләрем аша Нәкшбәндия тарикате ахырзаманга кадәр дәвам

итәчәк. Бу юлда йомгаклау булып соңгы имам Мәһди булачак», — дигән сүзләрен һәм Коръән белән Сөннәттән дәлилләрен китерәләр [61]. Тәсаувыф фәнен өйрәнгән вакытта, Мәрҗани бу турыда, һичшиксез, белгән һәм суфый шәехләр заманы тәмам булган дигән фикердән ерак торган булырга тиеш. Шунысы кызык: Россиядә Нәкшбәндия тарикате шәехләренең берсе, Дагыстанның Буйнак районындагы Чиркәй авылыннан булган Сәедәфәнде дә (1937-2012) бүген камил шәехләр юк дип исәпли. Бу очракта ул, иң беренче чиратта, үзен күз алдында тота. Ләкин шул ук вакытта ул камил мөршидләрдән рөхсәт алып та камиллеккә ирешә алмаган мөршидләр үз эшчәнлекләрен алып барырга хокуклы һәм алып барырга тиеш икәнлегенә дәлилләр китерә [62].

Габделхәмит Мөслими чын һәм бозып аңлатылган суфыйчылык турында язган мәкаләсендә Мисыр мөселман реформаторлары фикерен нигез итеп алган. Шуңа да без турыдан-туры Мөхәммәд Габдүһ сүзләренә мөрәҗәгать иттек һәм бу сүзләрдә мөршидлекнең зарурлыгы турында җавап та таптык. Реформатор Коръән һәм сөннәткә туры юл белән баручы инсан мөршидкә мохтаҗ түгел, дип яза. Шул ук вакытта әгәр дә мөэминмөселман үзенә мөршид таба алмаса, аңа тугры юл өчен шәригатьтә каралган юл белән барса, җитә, дип тә билгеләп үтә. Алга таба, әгәр дә мөселман үзенә лаек мөршид табып, бу остаз хезмәте өчен акча сорамаса, аның мөриде булып китәргә тиеш, дип әйтә [63]. Ягъни Мөхәммәд Габдүһ үз вакытында аларга ант итәргә һәм алардан өйрәнүче суфый шәехләр булу мөмкинлеген кире какмаган. Шул ук вакытта ул тәкъва мөршидләр кыяфәтен алган шарлатаннарны тыңлаудан кисәткән. Монда без Мәрҗани белән Габдүһнең карашлары туры килгәнлеген күрәбез.

Ш.Мәрҗанинең тәрҗемәи хәлен язучы аның суфыйчылык белән мавыгуының төп сәбәбе Әбү Хәмид әл-Газәли имам булган дигән фикердә тора. Әлеге имамның хезмәтләре белән Мәрҗани Урта Азиядә җентекләп танышкан булган. Ул шул ук вакытта аңа Урта Азия суфыйлары, алар арасында дини остаз Әбү Сәгыйд бине Габделхәй әс-Сәмәрканди [64] кебек шәхеснең дә йогынтысын кире какмый. Һичшиксез, Мәрҗани булып кайткан төбәкне суфыйчылыкның көчле йогынтысында булган, дип әйтергә була. XIV гасыр Бохара суфыйчылыгының иң күренекле вәкилләреннән берсе, мөселман дөньясында иң киң таралган (Кадыйриядән [65] кала) тарикать, Нәкшбәндиянең эпонимы Баһаветдин Нәкшбәнднең туган ватаны икәнлеген дә онытырга ярамый. Алда әйтеп үтелгәнчә, Мәрҗани заманында Нәкшбәндия тарикате Идел-Урал төбәгенең дини һәм интеллектуаль тормышында өстенлек алган булган. Шуңа да үзе яшәгән тирәлектәге суфыйчылык мохите бу татар галименең дини карашлары формалашуга һәм яшәү рәвешенә йогынты ясамаган дип күз алдына китерү мөмкин дә түгел. Ә Мәрҗанинең үз хезмәтләрендә суфыйчы авторларның чыганакларын сылтама итеп китерүе аның суфыйчылыкка интеллектуаль дәрәҗәдә бәйлелеген күрсәтә.

Шулай итеп, алда әйтелгәннәр безгә Шиһабетдин Мәрҗани мөселман мистицизмы практикасы белән җитди шөгыльләнгәнлеген, суфыйчылык идеяләре тарафдары һәм аны тромышка ашыручы да булганлыгын расларга нигез бирә. Тик ул бу идеяләрне ачык формада, турыдан-туры тормышка ашыручы булмаган, үз мөридләрен ачыктан-ачык укытмаган, рухи остазларыннан алган белемнәрен яшереп тотарга мәҗбүр булган. Ш.Мәрҗани үзен күпсанлы җаһил ишаннар, ялган суфыйлар, шарлатаннар белән бер рәттә санауларын теләмәгән.

Искәрмәләр һәм әдәбият

41. Фәхретдинов Р. Ибне Гарәби. — Оренбург: «Вакыт», 1912. — 128 б.

42. Кара: Мәрҗани Ш. Вафийат әл-әслаф. Кулъязма. 4 Д., 43а бит; Мәрҗани Ш. Вафият әл-әслаф фа тахият әл-әхлаф (Элгәргеләр турында җентекләп һәм киләсе буынга тәбрикләр). А.Н.Юзеев публикациясе. Гарәп теленнән тәрҗемә, комментарийлар, кереш мәкаләсе, искәрмәләр А.Н.Юзеевныкы. — Казан: Иман, 1999. — Б.31-32.

43. Шунда ук. — Б.78-79; Кара: Ибраһим К.Т., Солтанов Ф.М., Юзеев А.Н. Гомуммөселман контекстта татар дини-фәлсәфи фикере. — Казан, 2002. — Б.116.

44. Кара: Мәрҗани Ш. Рихлат әл-Мәрҗани. — Казан, 1898; Фәхретдин Р. Болгар вә Казан төрекләре. — Б.117-137; Шиһабетдин Мәрҗани. — Казан: Рухият, 1998. — Б.122-137.

45. Анда алар исеменә шәмнәр куйган һәм пәйгамбәргә (аңа Аллаһының хәер-догасы һәм сәламе булсын!) һәм аның кызына сәлам җиткергән (турыдан-туры, икенче затта). Бүген биредә ул йолаларны башкару мөмкин эш түгел. Ваһһабитлар андый гамәлләрне тыялар.

46. Кара: Шиһабетдин Мәрҗани. — Казан: Рухият, 1998. — Б.76-77; Мөслими ‘Абд әл-Хәмид: «Мәрҗани» // Шура. — 1916. — №4. — Б.101 (бу мәкаләдә автор Шәһәр Шәрәфтән өзек китерә, ул өзеккә аңлатма бирә).

47. Кара: Гомәри Габдрахман. Бөек остаз Мәрҗани хәзрәт хакында хатыйратым (хатирәләрем) // «Мәрҗани» җыентыгы, Казан: «Иман», 2001. — 2т. (1915 елгы басманың транслитерациясе). — Б.53.

48. Габдрахман Гомәри мәкаләсендә дә бу күренә (кара: шунда ук. — Б.53-55).

49. Шунда ук. — Б.54; шулай ук кара: Саттар-Мулилле Г. Татар исемнәре ни сөйли? (Татар шәхси исемнәренең аңлатулы тулы сүзлеге). — Казан: Раннур, 1998. — Б.119. Гомуми фикер буенча, «ишан» сүзе фарсы теленнән алынган.

50. Суфыйчылыкка, нигездә, прозелитизм һәм миссионерлык рухы хас түгел. (Кара: Эрнст К. Суфизм. — Б.183-187).

51. Кара: Шиһабетдин Мәрҗани. — Казан: Рухият, 1998. — Б.77.

52. Кара: аль-Чиркави Саид. Сокровищница благодатных знаний. — М.: Ихлас, 2002. — С.351.

53. Һәрхәлдә элек шулай булган. Хәзерге шәехләр, кагыйдә буларак, үз тарикатьләренә керүне беркемгә дә тыймыйлар. Ләкин моның өчен бүгенге шартлар һәм вакыйгалар белән бәйле сәбәпләр бар.

54. The Concise Encyclopedia of Islam. — London: Stacey International, 1991. — P.290.

55. Исламда билгеле шәхесләргә багышланган кайбер биографик җыентыкларда да бу шәехнең үз гомерендә Коръәнне ничә тапкыр укып чыгуы турында мәгълүмат китерелә.

56. Коръәнне тулысынча укып чыкканнан соң (хәтем), аерым догалар укыла.

57. Кара: «Мәрҗани» җыентыгы. — Казан: Иман, 2001. — 2 т. — Б.171-172.

58. Кара: «Мәрҗани» җыентыгы. — Казан, 1915 ел. — Б.73; Шиһабетдин Мәрҗани. — Казан: Рухият, 1998. — Б.77 (әмма монда «мөршид камил» гыйбарәсе «тугры юл» дип тәрҗемә ителгән, ә бу исә гыйбарәне төгәл мәгънәсеннән читкәрәк алып китә).

59. Кара: әл-Мөслими Габделхәмид. Мәрҗани // Шура. — 1916. — №4. — Б.101-102.

60. Аның ишаннар һәм суфыйчылык турындагы фикерләре турында кара: Maras I. Turk Dunyasinda Dini Yenilesme. — S.171-74.

61. Мәсәлән, кара: аль-Чиркави Саид. Сокровищница благодатных знаний. — М.: Ихлас, 2002. — С.226.

62. Кара: шунда ук. — Б.226-227.

63. Хивар фи-т-тәсаувыф вә-л-вилайа // ‘Абдух Мөхәммәд. әл-А‘мал әл-камила. — Каһирә: Дар аш-Шурук, 1993. — 3т. — 548-549 бит. Бу сүзләр М.Габдүһ шазилийа суфый мәзһәбе вәкиле белән әңгәмә үткәрер өчен барган Мисыр авылларының берсендә 1904 елның июлендә әйтелгән.

64. Кара: Шиһабетдин Мәрҗани. — Казан: Рухият, 1998. — Б.77.

65. Кара: Акимушкин О. Накшбандийййа // ИЭС. — М.: 1991. — С.187.

Русчадан ***Нияз Сабирҗанов*** *тәрҗемәсе*

Әдәбият

Шигърият ул — хиснең язмышыдыр,
Төп тылсымы сөю дәверемнең.
Язмышсызга язмыш яза-яза,
Дәвер әсиренә әвереледем.

Флёра Гыйззәтуллина

ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНА 50 ЕЛ

РУХИ ДӨНЬЯ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

ИЛҮСӘ НӘБИУЛЛИНА,
ТР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге җитәкчесе,
Р.Төхфәтуллин исемендәге әдәби премия лауреаты

МӘГЪЛҮМ БУЛГАНЧА, БЫЕЛ ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕНЕҢ 60 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЕ. ШӘҺӘРНЕ РЕСПУБЛИКА КАЛАЛАРЫННАН ҮЗГӘ — КАРА АЛТЫН БАШКАЛАСЫ ИТКӘН ТАТАРСТАН НЕФТЕ ЧЫГА БАШЛАУГА 70 ЕЛ. МЕНӘ ШУШЫ ЮБИЛЕЙЛАРНЫ ГОРУРЛАНЫП ҺӘМ ЗУРЛАП УЗДЫРЫРЛЫК ИТКӘН, ДАНЛЫ ХЕЗМӘТ ЮЛЫ УЗГАН КОЛЛЕКТИВЛАРЫБЫЗ ДА КҮП БЕЗНЕҢ. КАЛАБЫЗНЫҢ БАТЫР УЛЛАРЫН ШИГЫРЬ ЮЛЛАРЫНДА ДАНЛАГАН ШАГЫЙРЬЛӘРЕБЕЗ, ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА КЕРТКӘН ЯЗУЧЫЛАРЫБЫЗ БАР. ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНА БЫЕЛ 50 ЕЛ.

...Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.

Г.Тукай

Адәм баласы, күпмедер гомер иткәч, узганнарга борылып, башкарган эшләрен барлый. Ә бөтен бер коллектив юбилеен билгеләгәндә? Коллектив та үткәненә күз ташлап ала, ягъни эшләрен барлый, алардан чыгып нәтиҗәләр ясый, киләчәккә планнар билгели.

Язучылар оешмасы да — данлы үткәне, матур бүгенгесе һәм өметле киләчәге булган зур бер коллектив! Коллективның да нindie әле! Ун районга сибелгән булса да, бер максат, бер омтылыш белән яшәүче, олпат шагыйрьләрдән, язучылардан торган иҗади коллектив.

Әлмәт авылы кала булып үсеп киткәч һәм нефть ягы башкаласына әверелгәч, шушы чорның күренекле хезмәт романтикасын нәфис сүз кысаларына салучы язучылар, шагыйрьләр каланың үзендә дә туа, Девон шавы аларны төрле төбәкләрдән дә тартып китерә.

Бу яклардагы әдәби иҗат тамырлары гасырлар төпкеленә барып тоташа. XVIII гасырда ук Тайсуган авылында мәдрәсә эшләве һәркемгә мәгълүм. Бу мәдрәсәдә татар милли хәрәкәте җитәкчесе Батырша укыган. Татар әдәбияты классигы Дәрдмәнднең дә шәҗәрәсе Тайсуган белән бәйле. Биредә аның нәселенең җиде буыны гомер иткән. Кичүчат авылы дөньяга акыл иясе, язучы, рухани-мөгаллим Риза Фәхреддинне бүләк иткән. Ә

Миңлебай авылында Гыйльман ахун гаиләсендә күренекле язучы, журналист, мәгърифәтче Фатих Кәрими туган. XX гасыр башында Әлмәттә Һади Атласи, Фазыл һәм Кәбир Туйкиннар иҗат иткән. Габдрахман авылында Башкортстан Язучылар берлегенә нигез салган Афзал Таһири үскән. Язучы, җәмәгать эшлеклесе Ләбиб Гыйльминең Әлмәт районы Елховой авылында тууы һәркемгә мәгълүм. Локман Бадыйкшан — Әлмәтнеке, Хисам Камал — Кама-Исмәгыйльдән.

«Татарстан яшьләре» газетасының үз хәбәрчесе сыйфатында фронтовик шагыйрь Әдип Маликов хатыны Саҗидә Сөләйманова белән 1955 елда Әлмәткә күченеп килә. Шул ук елның октябрендә Әдип ага Горький исемендәге клубта яшь язучыларның әдәби түгәрәген оештырып җибәрә. Түгәрәккә талантлы эшче яшьләр тартыла. Нефтьче-оператор Җәмит Рәхимов, токарь Илдар Әхсәнов, рәссам Сәет Кальметов, журналист Фазыл Мостафин, эшче-төзүче Шамил Бикчурин, шулай ук төзүче Клара Булатова түгәрәкнең беренче әгъзалары була. Тора-бара алар һәммәсе дә күренекле шагыйрьләр һәм язучылар булып өлгерделәр, нефть төбәге, анда

САННАР ҺӘМ ФАКТЛАР

Әлмәт язучылар оешмасында җаваплы сәркатип (җитәкче) булып түбәндәге язучылар эшләде:

Гариф Ахунов — 1963-1965;
Әдип Маликов — 1965-1967;
Гариф Ахунов — 1967-1968;
Равил Фәйзуллин — 1968-1972;
Әдип Маликов — 1972-1982;
Әхәт Гаффар — 1982-1987;
Нур Әхмәдиев — 1987-1993;
Разим Вәлиуллин — 1993-2003;
Зөфәр Дәүләтов — 2003-2006;
Данил Салихов — 2006-2010;
2010 елның 15 декабреннән Әлмәт язучылар оешмасын **Илүсә Нәбиуллина** җитәкли.

Сулдан уңга: Шәүкәт Галиев, Рафаил Төхфәтуллин, Энҗе Мөэминова, Шамил Бикчурин, Гомәр Бәширов, Зәки Нури, Саҗидә Сөләйманова, Сәет Кальметов, Гариф Ахунов, Әдип Маликов. Әлмәт шәһәре. 1968-1970 еллар

яшәүче кешеләр турында матур-матур әсәрләр иҗат иттеләр.

Казаннан килгән өлкән әдипләрнең берсе: «Әгәр бу түгәрәккә йөрүчеләрдән бер генә Язучылар берлеге әгъзасы чыкса да, ул үзенең бурычын үтәде дип санар идек», — дигән булган. Әлмәт язучылар оешмасында 62 язучы әгъза булып торды. Алар барысы да безнең оешмада үсеп, канат чыгарып, чыныгып, ТР Язучылар берлеге әгъзалары булдылар. Димәк, бурыч 62 мәртәбә арттырып үтәлгән дигән сүз.

1955 елда М.Горький исемендәге клубта патриот шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган зур кичә гөрләп уза. Бу матур башлангыч каләм ияләрен эшчеләр һәм нефтьчеләр арасына алып керә, әсәрләре «Хезмәт байрагы» газетасы битләрендә даими күренә башлый. Шул ук елны «Татарстан яшьләре» дә төбәк каләм ияләренең иҗат үрнәкләрен «Әлмәтнең әдәби кичәләре» исемле баш астында халыкка җиткерә. Бер елдан соң «Совет Татарстаны» газетасы да аларга җылы фатиха бирә.

Ел саен әдәби хәрәкәткә яңа талантлар өстәлә бара. Энҗе Мөәминова, Саҗидә Сөләйманова, Клара Булатова, Рәшит Әхмәтҗанов — шундыйлардан.

Татарстан Язучылар идарәсе дә әлмәтлеләргә һәрчак ярдәм итеп тора. Әледән-әле шәһәргә Хәсән Туфан, Афзал Шамов, Гомәр Бәширов, Мөхәммәт Садри, Зәки Нури, Атилла Расих, Габдрахман Әпсәләмов, Әмирхан Еники һәм башка язучылар килеп тора. Бер үк вакытта Лениногорск, Азнакай, Мөслим, Сарман, Сарман районы Җәлил бистәсендә, Баулы һәм Бөгелмәдә дә әдәби түгәрәкләр эшли.

1957 елда СССР Язучылар берлеге әгъзасы Гариф Ахунов, ике елдан соң СССР Язучылар берлеге әгъзасы Рафаил Төхфәтуллин Әлмәткә күченеп килә. Аларга Гамил Афзал, Юныс Әминов килеп кушыла. Әдәби түгәрәк әдәби берләшмәгә әверелә.

Ниһаять, РСФСР Язучылар идарәсе карары белән 1963 елның 23 мартында Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге ачыла. Беренче утырышта ук бүлекнең бюросы раслана. Бюрога Гариф Ахунов (җаваплы сәркатип-җитәкче), Әдип Маликов, Рафаил Төхфәтуллиннар сайлана.

1964 елда «Правда» газетасында Әлмәт авторларына багышланган әдәби бит дөнья күрә. «Бүген «Правда»да әлмәтлеләр сүз ала, — дип яза үзәк газета. — Әлмәт язучылары үзләренең иң әйбәт әсәрләрен якташларының батырлыкларына багышлыйлар».

Нефть төбәге язучылары укучыга, татар әдәбиятына меңнән артык китап бүләк итте. Соңгы ун елда гына да шушы якларда яшәп иҗат итүче язучыларыбызның 500 китабы дөнья күрде. Әлмәт язучылар оешмасының 40 еллыгы уңаеннан ул вакыттагы җаваплы сәркатип Разим Вәлиуллин берничә җыентык әзерләгән иде. «Әлмәт җырлый» китабының башта беренче, аннан икенче, өченче тупламалары Разим абый үзе исән чакта дөнья күрде. Өченче том гел Әлмәт турындагы җырлар һәм шигырьләрдән генә тора. Үзе китап чыгарган кеше белә: бу зур көч-куәт, түземлелек сорый торган, мактауга лаек хезмәт.

Кайчагында рухи тормыш өлкәсендә, мәдәнияттә кемнең өлеше мөһимрәк: бер атаклы фикерне тудырган зур мәгърифәтчеме, матур әсәрләр язган язучымы, әллә шул фикерне таратучы, китапларны укучыларга җиткерүче мөгаллимме дигән уй килә. Әлмәттә яшәп иҗат итүче, 38 китап авторы Клара Булатова 50 ел төрле мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында балаларга белем һәм тәрбия бирде. Мөслимдә яшәп иҗат итүче балалар шагыйре Мөҗәһит Әхмәтҗанов 30 елдан артык мәктәптә укытты, директор вазифасын башкарды, язучы, 40ка якын китап авторы Альберт Хәсәнов озак еллар «Ватаным Татарстан» газетасының махсус хәбәрчесе булып эшләде, Әсхат Салахов 30 елдан артык газетада журналист, ун елын «Әлмәт таңнары» газетасының

мөхәррире, Г.Тукай премиясе лауреаты Фоат Садриев журналист; шагыйрь Таһир Шәмсуаров 40 ел мәктәптә балаларга белем һәм тәрбия бирә, шагыйрә Минзифа Әхмәтшина Әлмәт дәүләт нефть институтында әдәби кунакханә алып бара, шагыйрә Резеда Шәрипова — «Маяк» газетасы журналисты. Мәктәптә, югары уку йортларында эшләмәсә дә, шагыйрь, егермедән артык китап авторы Илдус Гыйләҗев — җир кешесе, безгә икмәк ашатучы. Зөфәр Дәүләтов — төзүче, матур китаплар белән беррәттән күркәм йортлар сала.

Хөкүмәт һәм әдәби җәмәгатьчелек Әлмәт язучыларының җитди хезмәтен югары бәяләде һәм бәяли. Аларның күбесе орден, медальләр белән бүләкләнде. Барысы да диярлек Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, дүртесе — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

Әдәби хәрәкәттә, Әлмәт язучылары иҗатында нефть темасы һәрвакыт калку яңгыраш таба. Соңгы елларда оешма бу төбәкнең сәнгать, җир асты байлыклары ягыннан гына түгел, ә әдәбият-сәнгать көчләренә бай булуы ягыннан да атаклы һәм мәртәбәле икәнен күрсәтү буенча иҗтиһат итә. Моның өчен берничә гасыр элек тарих төпкелләреннән башлап, бүгенге көннәргә кадәр мөрәҗәгать итү, репрессиягә эләгеп, көчләп онытгырылган, мираслары юкка чыгарыла язган, әмма дөнья тәрәккыятенә, татар милләтенең әдәбимәдәни байлыгына зур мирас калдырган мәшһүр шәхесләребезнең исемнәрен, иҗатларын, кылган гамәлләрен мәңгеләштерү буенча эзлекле җитди эш алып барыла. Зур әзерлек белән шәхесләребезнең юбилейлары, төрле форумнар, конференцияләр уздырыла.

Мәшһүр якташларыбызның тормыш һәм иҗат юлларын, аларның хезмәтләрен тәфсилләп язу бер мәкалә кысаларында гына мөмкин эш түгел. Аларны санап китү өчен генә дә шактый вакыт кирәк булыр иде. «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыятенең «Рухият» рухи яңарыш фонды ярдәме белән «Рухият» нәшриятында галим, мәгърифәтче, язучы, тарихчы, педагог, биобиблиограф, археолог, мөхәррир, публицист, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, гомумән, мөселман дөньясының

иҗтимагый фикере үсешендә тирән эз калдырган шәхес, йөзләрчә китап авторы Р.Фәхреддиннең «Җәвамигулкәлим», «Дин вә иҗтимагый мәсьәләләр», «Мәшһүр адәмнәр», «Асар» һәм башка китаплары (җәмгысе сигез китап) дөнья күрде. Шулай ук XX йөз татар әдәбиятын үстерү, яшь буынны тәрбияләү һәм халкыбызның рухи байлыгын саклап калуда күп көч куйган бертуган Туйкиннар турында да шушы ук «Рухият» нәшриятында, варисларының тырышлыгы белән, «Бертуган Туйкиннар» дигән китап чыкты. «Фатих Кәрими» исемле җыентык чыгып, укучыларга тәкъдим ителеп таратылды. Әдипләребезнең юбилейлары уңаеннан дөнья күргән китаплар да, гомумән, «Рухият»тә басылган китаплар ел азагында Яшьләр үзәгендә укучыларга тәкъдим ителә.

Ни кызганыч, Әлмәт язучылар оешмасы барлыкка килеп яши башлавыннан алып, безнең көннәргә кадәр 25 күренекле әдибебезне югалтканбыз. Соңгы ике елда оешманың элеккеге җитәкчесе, шагыйрь һәм композитор Разим Вәлиуллин һәм язучы Азат Ганиевлар арабыздан китте. Шактые Казан, Чаллы язучылар оешмаларына күчкәннәр. Бүген Әлмәт язучылар оешмасында 20 әгъза бар.

Әлмәт язучылар оешмасының 50 еллыгы уңаеннан, «Рухият» фонды ярдәме белән, «Рухият» нәшриятында ун районда яшәп иҗат итүче язучыларыбызның һәм иҗат түгәрәкләренә йөрүчеләрнең җыентыгы (ике йөздән артык кешенең иҗат җимешләре) чыгачак.

2011-2012 елларда гына да Әлмәт төбәгендә яшәп иҗат итүчеләрнең «Рухият» нәшриятында — 12, Татарстан китап нәшриятында — 8, башка нәшриятларда — 20, «Кызыл каурыйлар» иҗат берләшмәсе әгъзаларының 20 китабы, җәмгысе 60 китап чыкты.

«Рухият» фонды «Яшь дулкын», «Моя Татнефть», «Яшьләр авазы» дигән, үз эченә нефть районнарында яшәп иҗат итүче һәвәскәр, әмма талантлы һәм өметле йөздән артык яшь иҗатчының иң яхшы әдәби әсәрләрен туплап нәшер итте. Китап чыккач, ул зур бәйрәм рәвешендә укучыларга тәкъдим ителде.

2006 елда «Татнефть» акционерлык җәмгыяте һәм Язучылар берлеге белән берлектә күренекле шагыйрәбез Саҗидә апа Сөләйманова исемендәге әдәби премия булдырылды. Җиде ел эчендә әлеге олуг бүләккә утызга якын каләм иясе лаек булды, шуларның яртысы — Әлмәт язучылар оешмасы әгъзалары.

2011 елда, Халык шагыйре Гамил Афзалның юбилее уңаеннан, Татарстан Язучылар берлеге Актаныш муниципаль районы белән берлектә, әдипнең премиясен булдырды. Беренче премиягә Туфан ага Миңнуллин лаек булды.

1994 елда Әлмәт шәһәре хакимияте белән Әлмәт язучылар оешмасы язучы-фронтовик Р.Төхфәтуллин исемендәге премия булдырган иде. Әлеге премиягә безнең Әлмәттә яшәүче барлык язучыларыбыз да, шулай ук «Таң җиле» романы өчен Мөслимдә яшәп иҗат итүче Фоат Садриев лаек булды.

1981 елдан Татарстан Язучылар берлеге һәм Мамадыш муниципаль районының Шәйхи Маннур премиясе бирелеп килә. 2013 ел башында әлеге премиягә «Җырлы чишмә» китабы өчен Җәлил бистәсендә яшәп иҗат итүче безнең шагыйрәбез Рухия Ахунҗанова лаек булды.

С.Сөләйманова, Р.Төхфәтуллин премияләре лауреаты, кырыкка якын китап авторы Клара Булатовага 2013 елда Әлмәтнең Мактаулы гражданины дигән олуг исем бирелде.

Хәзер китаплар күп чыга, интернет заманы булгач, балалар китап укымыйлар, диләр. Соңгы елларда «урам нәшрияты» дигән яңа сүз дә килеп чыкты. Чыннан да, элек Татарстан китап нәшрияты, «Мәгариф» китап нәшрияты гына булса, хәзер исә Казанда да, Чаллыда да, башка шәһәрләрдә дә, акчаң булса, китап чыгару авыр түгел. Шәхсән мин үзем китап нинди генә нәшриятта

чыкса да, аны зурлыйм. Ул барыбер Китап. Һәр китапның үз укучысы бар. Халкыбызның «Ачның күзе — икмәктә, тукның күзе — хикмәттә», дигән бик матур, зирәк мәкале бар. Китап чыга икән, димәк, халыкның икмәккә тамагы туйган, аның күзе хикмәттә. Ул китап яза, җыр чыгара. Димәк, аның күңеле көр. Бу — яхшы фал. Мин акчаның автомат яки бомбага түгел, ә таба астына куярдай булса да китап чыгаруга китүе яклы. Начар кешегә яхшы сүз әйтсәң ни дә, эт муенына энҗе-мәрҗән таксаң ни. Надан кеше ул Габдулла Тукайны да, Һади Такташны да, Гамил Афзалны, Мөхәммәт Мәһдиевне дә таба астына куярга мөмкин.

...Тормыш дәвам итә. Аның һәр мизгеленә, әлбәттә, иң беренче чиратта, үз сүзен язучы әйтә. Язучы — яшәешнең рухи балансын тоючы индикатор ул. Без үзебез яшәгән төбәкнең — авылмы ул, бистәме, шәһәрме — үсеш юлында, сәясәтендә, татар мохитен булдыруда өлешебезне кертергә тырышабыз. Әсгать Салаховның «Каеннар юлы», «Соңгы вальс» китаплары татар һәм рус телләрендә, Нур Әхмәдиевнең «Аксак төлке», шулай ук татар һәм рус телләрендә «Мөнирстан», Зөфәр Дәүләтовның «Красота жизни», Мөҗәһит Әхмәтҗановның «Зирәк булу кирәк» дигән табышмаклар, «Батыр буласым килә» дигән балалар өчен шигырьләре, Фоат Садриевның «Бәхетсезләр бәхете» романы, «Авылдан хатлар» дигән публицистикасы, Таһир Шәмсуаровның «Гомер дисбесе», «Яу кырыннан хатлар», «Моң коесы», Илдус Гыйләҗевнең «Күкрәгемә тургай оялады», «Үземә кил», Минзифа Әхмәтшинаның «Сары яулык», Клара Булатованың «Камилә дигән матур кыз», «Гайшә белән Рамазан» дип аталган балалар өчен китаплары, «Келәү» шигырьләр җыентыгы һәм ике томлык сайланма әсәрләре басылып чыкты. Илүсә Нәбиуллинаның балалар өчен «Бәхет утравы», Рәмзия Габделхакованың «Тау артында кояш бар» романы, Альберт Хәсәновның «Данәгөл» романы, шулай ук яшь һәм башлап язучыларыбызның китаплары төрле нәшриятларда дөнья күрде.

«Рухият» ярдәме белән чыккан «Хәзинәле җирдә җыр туа» дигән компакт дискны җыр сөючеләргә тәкъдим итү, Муса Җәлил, Тукай көннәре, шигырь бәйрәмнәре «Татарстан нефтенә 60 ел» исемендәге шәһәр паркы белән берлектә дә зурлап билгеләп үтелә. Паркка яшүсмерләр клубларыннан балалар, мәктәп укучылары чакырыла, мул табын артында әдәби-музыкаль кичә уза. Балаларга язучылар белән аралашу, сөйләшү, сораулар бирү мөмкинлеге тудырыла, барлык катнашучыларга да истәлекле бүләкләр тапшырыла.

Күренекле каләм осталары Клара Булатова, Альберт Хәсәнов, Илдус Гыйләҗев, Марсель Гариф, Нур Әхмәдиев, Фоат Садриев, Мөҗәһит Әхмәтҗанов, Дамир Гарифуллин, Әсгать Салахов, Рәмзия Габделхакова, Таһир Шәмсуаров, Роза Хәбибуллина, Резеда Шәрипова, Минзифа Әхмәтшина, Зөфәр Дәүләтов, Фәйрүзә Исмәгыйлева, Мәүлет Борһанов, Әхтәм Фәтхи, Илдус Мәрдәншин һәм башкалар иҗат учагын сүндерми. Әгъзалыкка кандидатлар Зәлидә Зарипова, Рухия Ахунҗанова, Нәфисә Сабирҗанова, Лилия Садриева, Гөлнара Әюпова, Фәнис Мотыйгуллиннар яңа әсәрләре белән сөендерә.

Әлмәт язучылар оешмасына караган 10 районның һәрберсендә иҗади түгәрәкләр, әдәби берләшмәләр эшли. Аларның җитәкчеләре — каләм ияләре. Әлмәттә — «Кызыл каурыйлар» (җитәкчесе — Минзифа Әхмәтшина), Лениногорскида — «Чишмә» (Рәсим Хәбибулла), Мөслимдә — «Зөлфәт» клубы (Лилия Садриева), Азнакайда — «Гөлстан» (Резеда Шәрипова), Бөгелмәдә — «Моңсар» (Флёра Шәрипова), Баулыда — «Яңарыш» (Сәгъдия Васикова), Җәлилдә (Сарман) — «Җәлил чаткылары» (Илдус

Мәрдәншин), Чирмешәндә — «Илһам чишмәсе» (Рәмзия Мөхәммәтҗанова), Ютазыда — «Күңел җәүһәрләре» (Резеда Ахунова), Яңа Чишмәдә — «Бөреләр» (Гөлнур Латыйпова). Зур эшләребезнең берсе итеп әнә шул иҗади берләшмәләр белән элемтәгә керү, аларның эшләре белән даими танышып, кулдан килгән кадәр ярдәм итеп торуны саныйм. Өстә әйтеп үтелгән берләшмәләргә йөрүчеләрнең соңгы дүрт елда гына да берничә дистә китабы чыкты. Китап авторлары балалар бакчаларында, мәктәпләрдә, китапханәләрдә, югары уку йортларында даими очрашуларда булып, әдәби-тәрбияви эш алып баралар.

Ирек Бәдретдиновның моннан унике ел элек чыгарган «Син дә шагыйрь, мин дә шагыйрь» дигән китабында мондый юллар бар: «Шигырьләре китапка кергән авторларның күбесе инде пенсиягә чыккан яки шул яшькә якынлашып килүчеләр. Яшьләр күбрәк кирәк иде, яшьләр. Бардыр әле алар да, чәчрәп чыгарга ашыкмыйлардыр гына, дип юаныргa гына кала. Һәм күңелендә шигырь очкыны булган яшьләрне табарга, урыннардагы әдәби берләшмәләр эшенә ныграк тартырга кирәк. Олуг Тукаебызның эпиграф итеп китерелгән сүзләре хәзерге чорга да карыйдыр бит. Печән салучылар безнең татарда бервакытта да бетмәс анысы, атны җырлап әйдәүчеләр кирәк». Бар алар, атны җырлап әйдәүчеләр, диюем. Табып та торабыз без аларны. «Рухият» фонды ярдәмендә, «Рухият» нәшриятында чыккан йөздән артык авторны берләштергән «Моя Татнефть», «Яшьләр авазы», «Яшь дулкын» китаплары шуларга мисал түгелмени?!

Татар гимназияләрендә, татар мәктәпләрендә белем алган, мәктәптә укыган чакта, төрле бәйгеләрдә катнашып, призлы урыннар яулаган, төрле җыентыкларда иҗат җимешләре басылып чыгып, исемнәре газета-журналларда күренгән яшь каләм ияләре, мәктәпне тәмамлагач, каядыр юкка чыгалар шул. Аларны да аңларга була. Чөнки аларга югары уку йортларына керергә, русча белем алырга, аннан рус телендә генә сөйләшә торган оешма-предприятиеләрдә эшләргә кирәк. Шигырь, хикәя язып кына тамак туйдырып булмаганын хәзерге яшь буын, замана балалары бик тиз аңлап ала.

Әлмәт татар гимназиясе ачылып эшли башлавына, шәһәрдәге татар мәктәпләренең ачылуына егерме елдан артык вакыт узып китте. Татар җәмәгатьчелеге аларга зур өметләр баглаган иде. Гасырлардан торган тарих өчен ике дистә ел вакыт ул мизгел генә. Егерме ел эчендә беренче сыйныфка кереп, урта мәктәпне күпме укучы тәмамлап чыкты. Никадәрле бала (гимназиядә меңнән артык бала белем ала) ана телендә, татар телендә рәхәтләнеп сөйләшә, яза, җырлый. Дөрестән дә, әдәби иҗат һәм музыкаль иҗат белән мавыгучылар беренче елларда күп булды. Гимназиядә шагыйрә Клара Булатованың татар телен укытуы, анда «Офык» дигән газета чыгуы да балаларның иҗатка тартылуында зур роль уйнады. Байтагының халыкка барып ирешкән иҗат җимешләре дә бар. Гимназиядә, татар мәктәпләрендә белем алган барлык балаларның да үсеп өлгерүләре, кемдер булып китүләре өчен вакыт һәм шартлар кирәк. Бала, яшүсмер чакта әдәбият-сәнгать белән шөгыльләнгән, шигырьләр язган бөтен кеше дә язучы, шагыйрь яки композитор булып китә дигән сүз түгел бит әле. Әдәбиятта актив укучы, фикер йөртүче дә кирәк. Әдәби түгәрәкләргә йөрү, шигырьләр язу ул эзсез калмый.

Тагын бер зур эшебез дип язучы Гариф Ахуновның кызы Наилә Ахунова белән тыгыз элемтәдә торуыбызны әйтер идем. Моңа кадәр әле безнең рус телендә язучыларыбыз ничектер читтәрәк булып, алар үз «казаннарында» кайныйлар иде. Һәр ел саен март башында Вероника Тушнованың туган көне уңаеннан «Белая ворона», «Белое перо», Әлмәт язучылар оешмасы белән берлектә

Сулдан уңга. Басканнар: Фоат Садриев, Илдус Гыйләҗев, Нур Әхмәдиев, Әхәт Хәбибуллин, Мөҗәһит Әхмәтҗанов; утырганнар: Әсхәт Салахов, Роза Хәбибуллина, Альберт Хәсәнов, Илүсә Нәбиуллина, Дамир Гарифуллин. Әлмәт шәһәре. 2011 ел

Әлмәтнең 18 нче мәктәбе базасында «Планета любви» дип аталган фестиваль уздырыла. Анда Татарстанның барлык районнарыннан, Саратов һәм Магнитогорск шәһәрләреннән (интернет аша) йөзгә якын бала катнаша.

Рус телендә язучыларны шулай ук Тамара Бочина да үз канат астына берләштерә. Аның түгәрәгенә дә егермедән артык каләм тибрәтүче йөри.

Әлмәт язучылар оешмасына нәтиҗәле эшләү өчен «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыяте, җирле хакимиятләр белән тыгыз элемтәдә булу сорала. 20 язучысы булган зур оешманың барлык проблемаларын, бәйрәм кичәләрен үткәрү өчен без аларга мөрәҗәгать итәбез, матди һәм мораль ярдәм сорыйбыз. Безнең әдипләребезне олылап, юбилей кичәләрен тиешле югарылыкта үткәрүдә ярдәмнәре өчен «Татнефть» ачык акционерлык җәмгыятенә, аның генераль директоры Шәфәгать Фахразый улы Тәхаветдиновка, «Рухият» рухи яңарыш фондына, аның башкарма директоры Флёра Әбелмәгъдән кызы Шәйхетдиновага, Әлмәт, Азнакай, Мөслим, Лениногорск, Сарман хакимиятләре башлыкларына, барлык шәһәр һәм районнарның мәдәният идарәләре җитәкчеләренә рәхмәтләребез әйтеп бетергесез.

Уйлый китсәң, югалып каласың... Илле ел эчендә Әлмәт язучылар оешмасы меңләгән әдәби-музыкаль кичә уздырган, оешма эшчәнлегендә бик күп шәхесләр катнашкан. Язучылар һәрвакыт җәмәгатьчелек, әдәбият-сәнгать сөючеләр арасында кайнаган. Кечкенә генә язмада барлык исемнәрне, кылган гамәлләрне атап үтү мөмкин эш түгел. Үз исемнәре телгә алынмаганнар гафу итсеннәр.

Әлмәт үзенең олуг әдипләре, галимнәре белән дә, бүген яшәп иҗат итүче күренекле әһелләре белән дә горурлана ала. Бу киләчәктә дә шулай булыр. Безнең әдипләребез чын мәгънәсендә халыкка хезмәт итә.

Әлмәт язучылар оешмасы — ул Татарстан Язучылар берлегенең бер бүлеге. Ә Татарстан Язучылар берлеге — ул безнең халкыбызның рухи терәге, халыкка хезмәт итү, әдәбиятыбызны үстерү һәм туган телебезне саклау берлеге. Язучылар өчен, татар язучысы өчен, болардан да изге һәм игелекле бурыч булырга мөмкинме соң?! ■

ХАТЛАР БУЛЫП КАЛГАН ХАТИРӘЛӘР

ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!
СЕЗНЕҢ ИГЪТИБАРГА ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНЫҢ КҮРЕНЕКЛЕ ШӘХЕСЛӘРЕ — ПРОЗАИК РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИН ҺӘМ ШАГЫЙРЬ, ПРОЗАИК, ДРАМАТУРГ ФӘНИС ЯРУЛЛИННЫҢ 1960 ЕЛЛАРДА ҮЗАРА ЯЗЫШКАН ХАТЛАРЫН ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ.

РЕДАКЦИЯДӘН

РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИННЫҢ ХАТЫ

Фәнис туган!

Бүген генә Сезнең турында «Яшь ленинчы» газетасыннан укыдым һәм бик дулкынландым, шул ук вакытта бик шатландым да. Сезнең авыр язмышыгыз йөрәкләрне әрнетеп җибәрсә дә, шул авыр язмышны геройларча җиңә алуыгыз чын-чыннан куандырды. Ә инде шул ук газетада шигырьләрегезне укыгач, куанычым икеләтә артты.

Молодец Сез, Фәнис туган! Бирешмәгез, нык торыгыз, яңа җиңүләр яулагыз! Шундый авыр хәлегездә дә сокланырлык матур шигырьләр язуга ирешкәнсез икән, бу — Сезнең бик зур җиңүегез. Ишәйгәннән ишәя барсын Сезнең ул җиңүләрегез!

Марс Шабаев әйткәнчә, Сезнең янга пионерлар килеп йөрсә, алар Сезнең шигырьләрне күчереп язуда ярдәм итсәләр, тегe-бу йомышларыгызны үтәсәләр, бик әйбәт булыр иде. «Яшь ленинчы» чыгуыннан соң, бу нәкъ шулай булыр да дип ышанып калам. Шулаймы?

Мин Сезнең хәлне, Фәнис туган, ихтимал, кемгә караганда да яхшырак аңлыймдыр кебек. Мин, Ватан Сугышы инвалиды, башым яраланып, бик авыр көннәр кичердем, хәзер дә даими дәваланып торырга туры килә. 1959 елда, шул ярам аркасында кабатлангалап тора торган приступларымның берсендә, күкрәк умырткамны сындырдым, айлар буе гипста яттым, хәзер корсет белән йөрим. Һәркөнне физзарядка, салкын обтирание, күңелгә аз гына да боегырга ирек бирмәскә омтылу бик зур ярдәм итә. Шулай итеп акрын-акрын эшләп ятам. 1959 елдан бирле әдәби иҗат белән шөгыльләнәм.

Әйдә, Фәнис туган, язмыш дигәненә аз гына да буйсынмыйча, чын тормыш, ялкынлы иҗат, зур җиңүләр дәрте белән яшик!

Сезгә сәламәтлек һәм сәламәтлек теләп, күп сәламнәр белән
Р.Төхфәтуллин.
22 февраль, 1962 ел,
Әлмәт шәһәре



Рафаил Төхфәтуллин. Яңа Кенәр. 1955 ел

ФӘНИС ЯРУЛЛИННЫҢ ХАТЫ

Рафаил абый!

Сезнең шулай туганнарча якын итеп хат язуыгыз мине бик сөендерде әле. Мин Сезне моңа кадәр бик таза кешедер дип күз алдыма китерә идем бит. Чөнки Сезнең язган әсәрләрегездән яңгырдан соң нарат урманыннан бөркелгән тәмле, саф һава кебек, тормыш шатлыгы, күңелне иркәли торган җылы хисләр бөркелеп тора бит. Дөрес, Сезнең әсәрләрегезгә бәя бирер өчен мин әле бик яшь, тавыкны йомырка өйрәтү булыр иде, шулай да шуны әйтеп ... (сүз аңлашылмый, «китәсем» булуы ихтимал. — Ред.) килә: бик йөрәккә үтеп керерлек итеп язасыз Сез. Минем дә шундый матур әсәрләр тудырасы килә дә, көч җитми. Кайвакыт матур хыялларга

бирелеп, кулга ручка аласың, башта ниндидер бик әйбәт фикерләр дә була, ләкин яза башласаң, үзең бирергә теләгән нәрсә килеп чыкмый да тагын каушыйсың. Янда бер дә ярдәм сорардай, киңәшләшердәй кеше булмау да бик начар. Кайвакыт гади генә нәрсәләрне төшенә алмый да бик озак баш ватарга туры килә. Бигрәк тә белем җитмәү үзен сиздерә. Дөрес, мин әдәбиятка кагылышлы тәнкыйть мәкаләләрен, рецензияләрне, китап күзәтүчеләрне берсен дә калдырмыйча укып барырга тырышам. Ләкин андый нәрсәләр дә матбугатта сирәк күренәләр. Аларны укып кына язучы булып булмый бит әле, общий кругозор дигән нәрсә таррак ахры миндә. Минем дә Сезнең кебек повестьлар, хикәяләр язасы килә, язгалап та карыйм, барып чыкмый, үземә дә ошамый язган нәрсәләремнең кайберләре. Кешеләр белән аралашып булмау да комачаулый. Никадәр күп укысаң да, тормышны ныклап белү өчен ул гына җитми. Һәрвакыт кешеләр белән бер тормыш казанында кайнасаң гына, чын тормышны язып була. Хәзер, теге газетада язганнан соң, укытучылар, укучылар, авыл комсомоллары киләләр. Язган әйберләрне күчереп язарга ярдәм итәләр. Кешегә диктовать итеп яздыру бик кыен нәрсә икән ул. Берүзең тыныч кына уйлап язуга җитәме соң! Шуңа, начар язсам да, менә бу хатымны да үз кулым белән язам.

Минем янга февраль азакларында Әлмәт артистлары килеп киткәннәр иде. Алар Сезне дә, Гариф Ахуновны да, Әдипне дә яхшы беләләр. Минем берничә яңа шигырьне дә язып алганнар иде шундагы язучыларга күрсәтербез дип. Мин аларга: «Берәрсе килеп китсен әле минем янга, әйтегез», — дигән идем. Берәр яхшырак больницага урнаштыра алырлар бәлки. Синең үтенечне әйтербез, дип киткәннәр иде алар. Әллә инде кайту белән минем турыда оныттылар, ... (сүз аңлашылмый. — Ред.) хәбәрләре юк. Минем бу хатымны алгач, Гариф Ахунов беләнме яки башка кеше белән сөйләшеп карасагыз иде, бәлки минем янга килеп чыгарлар, Әлмәт ерак түгел бит, өч сәгатьлек юл.

Үзегез килә алмассыз инде, сәламәтлегегез бик шәптән булмагач. Юлда йөрү кешене бик вата бит ул. Минем янга Марс Шабаев килеп китте, ике көн бездә булды, шигырьләрне бергә тикшердек, бик күп киңәшләр бирде, бик яхшы консультация биреп киткән иде. Ләкин ике көндә нәрсә генә сөйләшәсең инде. Без бары язылган шигырьләр турында гына сөйләштек, ә бит язылмаган, башта гына йөри торганнары, шайтан белми, күпме әле аның. Алар һаман туа торалар.

Минем 5-6 шигырь «Совет әдәбияты»нда басылачак бугай әле апрель санында. Марс Шабаев шулай дип язган иде. Мин хәзер бөтен яңа шигырьләремне шуңа җибәреп торам. Рафаил абый, Сез Казанга еш барасыздыр инде, шунда барган вакытта Марс Шабаевка минем шигырьләрне редакцияләргә ярдәм итсәгез иде. Минем инде хәтсез шигырь бар. Әле кичә генә берничәне җибәрдем тагын. Сездән тагын шуны сорарга теләгән идем: Сез профессионал язучымы, әллә башка берәр вазифа башкарасызмы? Сезнең әсәрләрегез бик күп чыга бит, ничек шулкадәр яза аласыздыр?!

Мин Сезгә үземнең кечкенә генә бер мәсәлемне җибәрәм, үз фикерегезне язарсыз инде, хат язганда.

Кайчы белән инә
(Мәсәл)

Бер нәзек инәгә кайчы
Болай дип дәшкән көлеп:
— Син шулкадәрле кечкенә,
Үсә алмыйсың һич кенә.
Зур булып, минем кебек.
— Син, кайчы дус, үзең дәү дә,

Гариф Ахунов, Рафаил Төхфәтуллин, Әдип Маликов. Әлмәт шәһәре. 1962 ел, октябрь

Бары кисәсең генә,
Ә мин әйберләрне тегәм,
Зурайтам, матурлыйм, чигәм, —
дип җавап биргән инә.

Сезгә сәламәтлек, озын гомер теләп, кайнар сәлам белән
Фәнис Яруллин
7 март, 1962 ел

РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИННЫҢ ХАТЫ

Исәнме, Фәнис туган!

Күп сәламнәр һәм изге теләкләр күндереп калам.

Хатыңны алдым, җавапны бераз соңлабрак язам, кайбер нәрсәләрнең ачыклануын көттем. Ачыклабрак әйткәндә: без, Әлмәттәге иптәшләр, синең янга барып чыгарга уйлыйбыз. Әдип Маликов белән Гариф Ахунов өйдә юклар иде, инде җыелгач сөйләштек тә апрель аенда барырга булдык. Шунсыз һич бушап булмый, гафу ит, туган. Гариф — яңадан Казанга, Әдип — Заинскига, үзем иртәгә Азнакайга чыгып китәм.

Гарифка «Совет әдәбияты»ндагы синең шигырьләр турында кайгыртуны, Язучылар союзында сине дәвалау чарасын күрүне сөйләшүне йөкләп җибәрдек. Нәтиҗәләре турында ул кайткач хәбәр итәрбез әле.

«Кайчы һәм инә» мәсәле турында берничә сүз. Төзелеш ягыннан матур гына эшләнгән. Биш юллык строфа һәм рифмаларның үзенчәлекле яңгырашы (2-5, 3-4) эзләнүеңне күрсәтә, мәсәл өчен уңышлы үлчәү тапкансың. Ләкин, Фәнис туган, мәсәлеңнең мәгънәсенә игътибар итеп бетермәгәнсең. Кайчы да һәм инә дә — алар эш кораллары, бер-берсенә ярдәмчеләр. Аерым-аерым алар берсе дә тулы эш күрсәтә алмыйлар. Димәк, бер-берсен кимсетергә, үзләрен генә өстен күрсәтергә маташулары урынлымы? Бу турыда уйлап кара әле. Бәлки, беребез зур, беребез бәләкәй булсак та, бер үк зур эшне башкарабыз, беребездән башка ялгызыбызның хезмәте ярты-йорты гына булыр иде, дигән уртак фикергә килсәләр яки укучыны шул фикергә этәрердәй сюжет корсаң, әйбәтрәк булмасмы? Ә бу килеш матбугатка тәкъдим итми торырга киңәш бирер идем.

Мин үзем әйберне язып бетергәч, беразга кадәр, редакцияләргә җибәрмичә, «суынырга» куеп торам. «Су-

ынгач», алып укып карыйм да үзем үк күп кенә ялгышларымны, уйланып бетмәгән җирләрне табам. Шулай кабат эшләгәч, соңыннан редакцияләр белән бәхәс-мазарлар да бик кими.

Үзең тагын нәрсәләр язасың? Тазалык алга бармыймы?

Фәнис туган, күңелгә аз гына да боегырга ирек бирмик! Язмыш дигәнен арт ягына тибеп, үз дигәнебезчә нык торыйк, Фәнис!

Иң изге теләкләрдә калучы:
Р.Төхфәтуллин
26 март, 1962 ел, Әлмәт

ФӘНИС ЯРУЛЛИННЫҢ ХАТЫ

Исәнмесез, Рафаил абый!

Сезгә кайнар сәлам җибәрүче ерактагы якын танышыгыз Фәнис. Хатыгызны алгач, бер сөенгән идем, укып, Сез язган җылы хәбәрләр белән танышкач, икенче сөендем. Инде Сезнең мәшәкатьләнеп йөрүегезнең уңай нәтиҗәсен күреп булсын иде.

Үзем хәзергесе көндә беркилеш кенә ятам. Әз генә дә сәламәтләнеп булмый әле. Аннары минем бит бернинди дә дару принимать итмәгәнгә дә ике еллап инде. Бернинди врач күзәтүе астында ятмагач, ничек төземлек кирәк!

Шигырьләр язам, булдыра алган хәтле. Ләкин булдыра алуым чамалы, ахры. Нишләптер, соңгы вакытта газеталарда да минем шигырьләр күренми башлады әле.

«Социалистик Татарстан» газетасында басылырга тиеш иде берничәсе. Моннан бер айлар чамасы элек җибәрелгән шигырьләрне һаман да тозлап яткыралар әле, бер дә басылмаса язган нәрсәләр, ышанычны (үземә булган) югалта башлыйм мин. Күңел үсми башлый, кайвакыт бөтен дөньясына кул селтисе килә башлый.

Әле менә соңгы вакытта 9 нчы класс дәреслекләрен укыштыра башладым. Тел фәннәреннән булса да кабатлыйм әле. Бәлки сынау биреп тә булыр.

Әлеге язганымча, хәзер укытучылар яныма килеп йөриләр. Үзең турында әз генә булса да кайгыртуларын тойсаң, яшәргә дә более менее күңеллерәк икән.

Минем язган шигырьләр турында үзегез килгәч бәхәсләшербез инде. Минем зур күләмле әсәрләр язып караганым юк, аңарга мин көчсез әле, үзем дә сизәм. Ә кыска шигырьләр хәтсез бар инде, сыйфаты гына ничектер. Яңа шигырьләрнең күбесен Марс Шабаевка җибәреп барам.

Тик соңгы көннәрдә аңардан да хәбәр юк әле. Ул шигырьләрнең һәрберсенә бик каты анализ ясап җибәрә торган иде.

Кыскача минем хәлләр шуннан гыйбарәт.

Озак итеп үзегез килгәч сөйләшергә әзерләнеп торам. Үзегез дә озакламассыздыр инде.

Хәзер берничә кыска шигыремне язам.

Тарту көче

Җирнең үзенә тарту көче барлыгына
Ышанмыйча тора идем моңа кадәр.
Чит җирләргә киткән идем
ялгыз гына —
Һәркөн үзенә тартып тора
туган шәһәр.

Күз яше

Күз яше дә кайчак кибә икән,
Еласаң да чыкмый һич кенә,
Ул шулвакыт бик күп түгел икән —
Кайгы булган чакта кечкенә.

Эпиграмма

Мөртәткә бит белем кирәкми,
Ялагайлык җитә аңарга.
Өйрәнгән ул акыл бушлыгын
Елмаюы белән ямарга.

Ык елгасы ярында. Сулдан уңга: Рафаил Төхфәтуллин, Мәхмүт Хәсәнов, Гариф Ахунов башкорт язучылары белән. 1966 ел

*****

Кем дус булса шешә белән —
Таныша башта кесә белән.
Аннан «дуслык» кулын суза,
Ә кесәгез бушагач, сыза.

Менә шулар хәзергә минем язасы килгән сүзләр. Үзегез хат язганда, Гариф Ахуновның нинди хәбәрләр белән кайтканын язарсыз инде. Иҗатыгызда имәндәй тамыр җәеп, алмагачтай чәчәк атуыгызны теләп калам.

Фәнис Яруллин
30 март, 1962 ел

Җавабыгызны көтәм.

ФӘНИС ЯРУЛЛИННЫҢ ХАТЫ

Сәлам Кызыл Ярдан

Исәнмесез хөрмәтле Рафаил абый.

Дуслык сәламнәре юллап, эшегездә уңышлар, тормышыгызда сөенчеләр теләп калучы хат аша танышыгыз Фәнис.

Сезнең апрель аенда килеп чыгарбыз, дип язган хатыгызны алгач, менә-менә килеп чыгарлар дип, һәркөнне көттем. Әллә инде вакытыгыз шулкадәр кысрык, әллә башка берәр сәбәп чыктымы, мин ни уйларга да белмим инде. Хат булса да язып салсагыз иде.

Үземнең хәлләр һаман үзгәрешсез дияргә ярый. Май аенда шактый гына күңелдә калырлык вакыйгалар булып алды: Язучылар союзыннан Гомәр ага Бәширов, Сибгат Хәким, Рәшит Гәрәй һәм «Совет әдәбияты» журналының редакторы Абдулла Гумеровлар килеп киттеләр. Тик вакытлары бик кыска булды. Озаклап сөйләшеп утырып та булмады.

«Совет әдәбияты»нда минем шигырьләрнең дә берничәсе булдылар — 6 нчы санында.

Алардан элек Мәхмүт Хөсәеннәр килеп киткәннәр иде. Алар Сезнең янга да барабыз дигәннәр иде, бәлки барганнардыр. Алар белән шактый гына шигырьләрне укып-тикшереп чыктык. Мин белгән колхозчылар белән очрашу кичәсе үткәрделәр. Халык бик яратып калды үзләрен.

Ф.Яруллин Кызылъяр авылында укучылар белән очрашу вакытында. 1970 ел

Үзем һаман булдыра алган кадәр шигырьләр язгалыйм. Соңгы вакытта язылган шигырьләрне Сибгат Хәкимнәр дә укыган иде — ошаттылар. Бер дәфтәрне алып киттеләр үзләре белән.

Менә шулай әкренләп яшәп яткан булам.

Үзегез турында хәбәр бирегез әле, бу хатны алгач.

Минем укытучылар Сезнең адресны алганнар иде, хат язмакчылар бугай. Язмадылармы?

Менә соңгы вакытта язылган бер шигыремне язып җибәрәм, үз фикерегезне әйтерсез.

Дуслар белән

Дуслар белән уртаклашсам гына,
Ләззәт бирә миңа шатлыгым.
Бүлешмәсәм әгәр шатлыгымны,
Таплана күк күңел сафлыгым.

Кояш нурларыннан качкан гөлдәй
Йотлыгып яшәүләрне сөйлим мин.
Кайгымны мин әйтмим сорамыйча,
Шатлык килсә түзмим, сөйлимен.

Бөтен нәрсәдән дә тыелып була,
Рухи көчне ныклап җиккәндә.
Тик күз яшен тыеп булмый икән,
Кайчак күңел йомшап киткәндә.

Ярый, шуның белән хатым тәмамлыйм.

Хушыгыз. Сәлам белән Фәнис Яруллин

3 июнь, 1962 ел

ФӘНИС ЯРУЛЛИННЫҢ ХАТЫ

Рафаил абый!

Бу хатны Сезгә Фәнис Яруллин яза.

Минем кечкенә генә күләмле бер повесть бар иде, шуны Сезгә җибәрсәм, укып, үзегезнең фикерләрегезне әйтмәссезме икән?

Мин аны беренче кат язганнан соң «Казан утлары»на илткән идем, анда Яхъя Халит укып, замечаниеләрен язган иде. Хәзер кабат яздым. Әгәр укыйм дисәгез, мин шул әйберне Сезгә почта белән җибәрер идем.

Хәзергесе вакытта мин авылда. Җәй айларын монда үткәрергә уйлыйм.

Якын тирәдә киңәш-табыш итәрдәй кеше юк. Сез минем хикәяләр җыентыгын да рецензияләгән кеше, иҗатым белән әзме-күпме таныш. Ләкин Сездән укытырга үтенечем аның өчен генә түгел, ә әсәрләрегезне

ярату. Әгәр, вакыт табып, шул әйберне укысагыз, мин бик шат булыр идем. Риза булсагыз, миңа шушы адрес белән хат язгыз, мин, җавабыгыз килү белән, повестьны җибәрермен.

Баулы районы, Кызылъяр авылы, Яруллин Ф.
Сезгә ихтирам белән, ФәнисЯруллин
13 июнь (елы мәгълүм түгел. *—Ред.*)

49 ЕЛ УЗГАЧ

Мин, Рөстәм Төхфәтуллин, әтинең архивында Фәнис Яруллинның хатларын күргәч, интернеттан аның адресын һәм телефон номерын эзләп таптым, шалтыратып, әти турында берничә сүз яза алмассызмы дип сорадым. Берничә көн үткәч, миңа Фәнис абыйның китабы һәм хаты белән бандероль килде.

50 ел узгач, шул ук урында очрашу (кара: журналның 73 нче битендәге фото). **Наилә Ахунова, Рөстәм Төхфәтуллин, Әнвәр Маликов – классик әдипләрнең балалары. 2012 ел**

ФӘНИС ЯРУЛЛИННЫҢ ХАТЫ

Хөрмәтле Рөстәм әфәнде!

Сезнең хатыгызны алганга берничә көн узса да, җавап яза алмый тордым, чөнки бик каты авырып ята идем. Әйе, Сезнең әтиегез Рафаил Төхфәтуллин белән берничә хат алыштык. Ул киң күңелле, олы җанлы — кешеләргә ярдәм кулы сузарга һәрвакыт әзер торучы чын кеше иде. Минем матбугатта чыккан беренче шигырьләрне күреп алып һәм шуларга үзенең бәясен биреп, мине рухландыручы язучыларның берсе булды Рафаил абый.

Мин барлык әсәрләрен укып барырга һәм аңардан үрнәк алырга, иҗатымда аның кебек осталыкка, камиллеккә ирешергә тырыштым.

Сезнең әтиегез Рафаил абый тормышны яхшы белә һәм тормыш чынбарлыгын әдәбият кануннары аша укучы күңеленә нечкә психологик юллар белән ярып сала белә иде. Соңгы елларда аралышып яшәмәсәк тә, ул — минем күңелдә якты эз калдырган кеше. Соң булса да, Рәхмәт, Рафаил абый Сезгә!

Рөстәм, минем «Сөенечләр бүлешү» дигән китабымда Рафаил абый турында кайбер истәлекләр бар (25-26 биттә).

Почеркым бик начар, гафу итегез.

Рөстәм әфәнде, сезнең барлык гаилә членнарына: хатыныгыз Сәҗидәгә, балаларыгызга һәм оныкларыгызга сәлам белән

Ф.Яруллин
3 гыйнвар, 2011 ел

Хатларны басмага Р.Төхфәтуллинның улы ***Рөстәм Төхфәтуллин*** *әзерләде.*

КҮЛАРТЫ ПОСЁЛОГЫ

КЛАРА БУЛАТОВА,
шагыйрә, Әлмәт шәһәренең мактаулы гражданины,
С.Сөләйманова һәм Р.Төхфәтуллин исемендәге әдәби премияләр лауреаты

VII сыйныфта Тукай дәресе. Укытучы – К.Булатова. Әлмәт районы Колшәрип авылы (кулаклардан калган йортны сипләп, 1928-1965 елларда эшләгән мәктәп бинасы). 1963-1964 нче уку елы

I

Күларты посёлогы дип
Ул чакта бу җир йөрде.
Финский, московские –
Бараклар төрле иде.

Кайсында – кызлар торагы,
Кайсында – егет-җилән,
Кайсында – семьялылар –
Төрлесе төрле җирдән.

Күларты посёлогының
Киеме чуар, теле:
Татар, рус, мари, мордва,
Украин, чуваш теле.

И нинди җырлар җырланмый,
Тыңласаң колак салып,
Үзара тату, күңелле,
Шат яши иде халык.

Баракта, уртак кухняда
Аш пешә, коймак пешә.
Кичен бүлмәдән бүлмәгә
Кунакка йөрү китә.

Сые шул: хуҗа бәрәңге,
Гөмбә кыздырган була.
Кунагы тозлы балыгын
Күтәреп кергән була.

Буямый идек табынны
Шешәле агу алып.
Эчми дә күңел күтәреп,
Шат яши иде халык.

Барысы да гади, беркатлы,
Эчкерсез кеше иде.
Төрлесе төрле милләттән –
Бертуган төсле иде.

Вахталар таңнан кузгала,
Шул халык йөри иде,
Шул халык нефть чыгара
Һәм шәһәр төзи иде.

II
Шушында үткән гомернең
Яшь чагы, юләр чагы,
Акылга мохтаҗ булмыйча,
Рәхәттә йөргән чагы.

Иңнәргә төшкән дулкын чәч,
Билләргә төшкән толым,
Чәчләрдән таныйлар иде
Күларты посёлогын.

Кимәдек лаклы туфли дә,
Исебез китми иде.
Биюдә безнең кызларга
Берәү дә җитми иде.

Биш чакрым Горький клубы —
Танцыдан калмый идек.
Җәяүләп шунда йөрүне
Гадәти саный идек.

«Төн буе нинди йөрү», — дип,
Әтиләр әрләмәсен —
Шыпыртын ачып керәсең
Баракның тәрәзәсен.

Ятасың аннан тын алмый,
Йоклаган, «үлгән» булып.
Ә иртән эшкә китәсең
Кара таң белән торып.

Кич белән тагын шул ук хәл:
Аруны-талчыгуны
Ташлый да танцыга чаба
Күларты посёлогы.

III
Шул чуар итәкле кызлар,
Шул җиңел егет-җилән
Күкләргә кадәр Әлмәтне
Күтәргән тигез җирдән.

Безнең яшьлекне үзенә
Фундамент иткән шәһәр —
Улларыбызга мирас ул,
Кызларыбызга мәһәр.

Яшьлеккә кире кайтарыр
Сукмаклар юк та югын.
Яшьлегем итеп хәтерлим
Күларты посёлогын. ■

Әлмәт районы Мәмәт урта мәктәбендә очрашу. К.Булатова, Г.Ахунов, Ш.Бикчурин. 1970 ел

Әлмәт язучылар оешмасында утырыш. 1960 еллар ахыры

ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ХАТЛАРЫ

РӘШИТ РӘХМӘТИ АРАТКА

Рәшит Рәхмәти Арат (1900-1964) — иҗаты татар халкына әле кайтарылмаган күренекле шәхесләрнең берсе. Ул — дөньякүләм билгеле галим, тюрколог. Күпсанлы гыйльми хезмәтләр белән беррәттән, Р.Арат шигырьләр, хикәяләр дә иҗат иткән. Беренче әсәрләрен Кызылъярда (Петропавелда) мәктәптә укыганда ук балалар өчен чыгарылган «Берлек», «Яшьлек таңы» журналларында бастырган. Харбинда яшәгәндә, «Ерак Шәрекъ» дигән журналны оештыруда катнашкан. Берлин университетында укып йөргән елларында Р.Рәхмәти бик күп шигырьләрен, нәсерләрен Гаяз Исхакый чыгарган «Милли юл» (соңыннан «Яңа милли юл») мәҗмугасында бастырган. 70 нче елларда Төркиядә татарлар чыгарган «Казан» журналында да Р.Аратның кайбер әдәби әсәрләре дөнья күргән.

Чит илгә киткәч, Г.Исхакый берничә мәртәбә татарча матбага оештырырга омтылыш ясап карый. Бу теләгенә ул бары тик 1928 елда гына ирешә. «Милли юл» мәҗмугасының беренче саны 1928 елның 23 декабрендә дөнья күрә. Бу матбага мәйданга чыкканчы, Г.Исхакыйның Европаның төрле илләрендә милләттәшләрен барлап, оештырып, «Идел-Урал» комитетлары төзеп йөрүе билгеле. Әдип аеруча Европа университетларында белем алучы милләттәшләренә игътибарын юнәлтә. Мәҗмуганың булачак авторларыннан берсе Рәшит Рәхмәти Арат белән ул Берлинда таныша. Шуннан соң алар хат алыша башлый.

Р.Арат иҗат иткән нәсерләр мәҗмуганың «Әдәби язулар» сәхифәсендә басылып бара. Ләкин Г.Исхакый моның белән генә канәгать түгел. Ул аңа милли мәсьәләләр, татар теле турында гыйльми мәкаләләр язарга киңәш бирә. Кем белә, Г.Исхакыйның хатларда да, әңгәмәләшкәндә дә телләр турындагы фикерләре, бәлки, яшь егетнең күңеленә оеткы салгандыр, Рәшит Рәхмәти Аратның киләчәктә галим-тюрколог булып китүенә этәргеч ясагандыр.

«Яңа милли юл» мәҗмугасында Р.Аратның 50 әсәре басылып чыккан. Шуларның 11е — шигырь, калганнары — нәсер, публицистик, тәнкыйди мәкаләләр. Журналда авторның үз исеме күренми. Ул псевдоним-тәхәллүс белән яки имзасыз яза. М.Х.; М.Ф.; Ф.; Гали; Гали Биктимер; Шакир Йосыф; Ш.Й. — менә аның тәхәллүсләре. Мин Р.Аратның «Милли юл»дагы әсәрләрен профессор Әхмәт Тимер ачыклаган шушы тәхәллүсләре буенча туплаган идем. 2001 елда Төркиядәге Әхмәтвәли Мәнгәр вакыфының матди ярдәме белән Казанда дөнья күргән «XX гасырның күренекле тюркологы Рәшит Рәхмәти Арат» дигән китапта галимнең мәҗмугадагы эшчәнлеге турында безнең дә мәкаләбез урын алган иде. «Яңа милли юл» журналы 11 ел дәвамында, 1939 елның октябренә кадәр чыгып килә. Мәҗмугада Р.Рәхмәтинең соңгы язмалары исә 1934 елга туры килә. Берлин университетында хәзер инде үзе дә студентларга белем бирүче Р.Арат 1933 елда Төркия Мәгариф министрлыгы тарафыннан Төркиягә эшкә чакырыла. Г.Исхакый исә Төркиягә 1939 елның көзендә килә. Бу илдә яшәгәндә дә олы әдип белән яшь галим аралашып тора.

Рәшит Аратның вафатыннан соң, аның китапханәсе, архивы Анкарадагы профессор Әхмәт Тимер җитәкләгән Төрек мәдәниятен өйрәнү институтына тапшырыла. 1994 ел ахырында, Төркиягә баргач, минем үземә дә шул архивта бераз казынырга туры килгән иде. Р.Арат Г.Исхакыйның революциягә кадәр чыккан әсәрләрен конспектлап укыган икән, кыска-кыска фикерләрен дә язып барган. Галимнең архивында Г.Исхакыйга кагылышлы башка материаллар да очрый. Мәсәлән, әдипнең «Локман хәким» дигән хикәясенең татарча тексты нәкъ шул архивтан табылды. Г.Исхакыйның укучыга тәкъдим ителә торган әлеге хатлары да шул архивта сакланган.

Финляндиядән язган беренче хатында ук Г. Исхакыйның Р.Аратка зур өметләр баглавы аңлашыла. Шулай ук бу хатларда Г.Исхакыйның «Милли юл» мәҗмугасын оештыру юлындагы эшчәнлеген чагылдырган кыйммәтле мәгълүматлар да бар. 1930 елның 14 ноябрендә язылган хаттагы бер хәбәр игътибарны аеруча җәлеп итә: «Монда хәзер французчага, ләһчәгә бер пропаганда әсәрне тәрҗемә иттерәбез. Шуның өчен дә харита булу лазем», — дип хәбәр итә Г.Исхакый. Бу «пропаганда әсәре»нең 1933 елда Парижда рус һәм француз телләрендә, 1934 елда япон телендә, 1938 елда поляк телендә чыккан «Идел-Урал» очеркы икәнлеге шик калдырмый. Димәк, Г.Исхакый бу әсәрен 1930 елда ук язып тәмамлаган булган. Кызганыч ки, очеркның татарча тексты сакланмаган. (Бездә «Идел-Урал»ның татарчасы шагыйрь Ркаил Зәйдулла тәрҗемәсендә басылып таралды.) Г.Исхакый брошюрасында хатларда телгә алынган «Идел-Урал» картасы да урнаштырылган.

Хатлар гарәп язуыннан күчерелде.

БЕРЕНЧЕ ХАТ

Рәшид!

Киткән вакытта синнән әллә кемнәрнең адресларыны алып бетердем. Үзегезнекен алырга онытканмын. Шуның өчен бу хатны кеше адресы берлә генә язам. Минем төрле йирләрдәге тәмасларым (бәйләнешләрем), әлбәттә, катгый бер нәтиҗә биргәне юк. Ләкин өметсез түгел. Мәйданда мәҗмуга булганда, аз-чук (азмы-күпме) дустлык күрсәтерләр кеби тоела. Мөнәсәбәтләрне баглап йөрим. Илемезгә кертү мәсьәләсе шактый юлга керә. Акса Шәрекъ (Ерак Көнчыгыш) берлә мөнәсәбәт тә җиңеләер кеби хис ителә. Төенләнеп эш башлагач та, насыйп булса, дәвам итәчәк. Эстониядә кечкенә генә нигез салдык. Монда да кечкенә-кечкенә оячыклар корамыз. Идел-Урал җөмһүриятенең харитасы (картасы) бик лазем икән. Һәрбер тәмаста зур ихтыяҗ бар, шуны эшләп куя алсагыз, шәп булыр иде. Ләкин чикләрне тәгъйиндә (билгеләүдә) бик саран булмаңыз. Ул йирләр бит барысы да безнең бабайларның йорты булган. Көтепханәдә бәгъзе бер материаллар, әлбәттә, бардыр. Доктор берлә киңәшләшеңез әле. Әлегә хушыңыз. Рәбига ханымга бик күп сәлам. Хөсәен[нең] докторлыгы мөбарәк булсын. Ибраһимга миннән сәлам языгыз.

Гаяз Исхакый

Адресым: Һилсингфорс,

Сити Пассаже, 13, Назар.

Финляндия.

Нарва шәһәренең музәсендә «Казанны алу» исемендә бер рәсем бар, күчертергә тиеш иде, ләкин бик зур.

26 июль, 1928

ИКЕНЧЕ ХАТ

Хөрмәтле Рәшид әфәнде!

Китабыңызны алган идем. Аннан соң мәктүбеңез дә килеп чыкты. Соңгы мәҗмугада мәкаләгез дә күрелде. Шулай итеп, бу соңга калган мәктүбтә һәммәсенә бердәм җавап бирергә тугры килде. Китабыгыз өчен бик зур рәхмәт. Болар бит безнең үземезнең гыйлем юлында Аурупа дөньясында эшли башлауның беренче карлыгачлары. Шуның өчен Ягкуб Шинкевич һәм

дә сезнең китапларны алмаенча чыккан профессор Василнең «Татарлар» дигән рисаләсене тәнкыйть иткән булып, Аурупада төрек-татар кәнҗенең (яшьләренең) гыйльми хезмәте дип, бер мәкалә язу бик лазем иде, бәлки, һәммәсенә бераз булса бер-ике мәкалә язарга кирәк иде. Бу китапларны тәнкыйди тәхлил итәрлек (тәнкыйди анализ ясарлык) анда бер кешемез дә юкка, шуны үз арамыздан берәүнең язуы лазем иде. Инде сезнең анда калуыңызга килгәндә, бу бигүк начар эш түгел. Хәзерге көндә безнең илләрдә милләтчеләргә эшләүнең никадәр авыр икәнен белми торгансыздыр. Хәзер анда төрек-татар илләрендә «партияне тазарту» эше бара. Шунда мулла йә мөәзин баласы булу гөнаһе кәбаирдән (зур гөнаһтан). Гәзитәләрне тәгкыйб иткәндә (күзәткәндә), унар ел бергә хезмәт иткән егет-әгъзаны чыгарып ташлауларына бик күп очрыйсың. Хосусән, хәзерге «партияне тазарту» башы-эчәге берлә милләтчеләрне куып чыгарыр өчен ясала. Галимҗан Шәрәфне шул арада яптылармы, ябалармы — бер эш эшлиләр. Гөнаһысы — латинчылыкка хилафлык (каршылык), голяма (руханилар) берлә элемтә ясау.

Ләкин Берлин дарелфөнүнендә мөмкин кадәр төплерәк урынлашырга тырышырга кирәк. Ул вакытны әрәм итү булмас, билгакес (киресенчә), гыйльми сахада (мәйданда) бер казаныш булыр. Инде безнең мәҗмуга кую эшләренә килгәндә, акрын гына итеп һаман алга атлыймыз кебек күренә. Ләкин безнең халыкның, гомумән, арпа камырыннан ясалган булуы мондый тәшкилат (оештыру) эшләренә өйрәнмәгән булуы, әлбәттә, шактый комачаулый. Эшләрнең теләгән кадәр тулы чыкмавына вә күршеләремез алдында үземезнең сикъляте изафиемезне түбәнрәк күрсәтергә сәбәп була. Нишлисең, гасырлар буе килгән урысның безне бозуыны, әлбәттә, тиз генә төзәтеп ташлап булмый. Бәлки, бара-бара, эшли-эшли, эш үз юлын алыр. Ләкин безнең вазифамыз аңарга карамаенча эшләү вә кулда булган көчне урынына сарыф итәргә гайрәт итү булырга тиештер. Бу тиешлек, әлбәттә, сезгә дә гаиддер (кагыладыр). Шуның өчен шул милли эшнең башлануында эшкә чакырылган сезнең кебек хәзерлекле яшьләремез без картларга караганда зур тәхәррык (дәрт), гайрәт берлә җиңне сызганып тотынырга кирәк иде. Үзенә төшкән, төшәчәк вазифаларны үзе белеп тә эшләргә кирәк иде. Бу, мәгаттәәссеф (үкенечкә), болай булмады. Әлбәттә, шуңарга бик күп формаль җаваплар хәзердер. Ләкин болар һәммәсе дә: «Ник намаз укымыйсыз?» — дигән сөальгә: «Ничек укыйм, тәсбихем юк бит»,– кабиленнәндерләр.

Инде үткән эшләргә салават. Килик киләчәккә. Безнең шул алган юлда муаффәкыятьле (уңышлы) рәвештә алып баруымыз барымыз өчен дә шәрәф булачактыр. Аның ярты юлда өзелүе барымыз өчен дә йөз кызыллыгы булачактыр. Шуның өчен башланган эшнең дәвамына хезмәт итү барымызның да бурычы, хосусән, сез яшьләрнең өстенә йөкләнгән фарыздыр. Менә сез шул фарызларны үти башлавыңызга сөендем. Моннан соң, әлбәттә, дәвам итәчәксез. Эшләр шактый киңәеп барганга, төрле-төрле эшләр алга басып торалар. Шул эшләрдә сезнең сызганып эшләүчеләр арасында булуыңыз лаземдер. Шул ук харита (карта) эшендә, әлбәттә, сезнең хезмәтеңез Әкъдәснекеннән[1] тагы төплерәк, гыйльмирәк булачак иде. Илемезне тану, таныту юлында сезнең казынырга имкяннарыңыз (мөмкинлекләрегез) тагы күбрәк, хәзерлекеңез тагы тулырак, методларыгыз тагы тугрырак иде. Мәҗмуга хакында да фикереңез, каләмеңез берлә иштиракыңыз (катнашуыгыз), әлбәттә, файдалы иде,

[1] Әкъдәс — Әкъдәс Нигъмәти Курат (1903-1971), тарихчы.

матлуб иде (сорала иде). Моңарга яшьләрдә бик күп сахалар (бу урында: мөмкинлекләр) бар. Боларның барысын да мәктүбтә санап бетереп булмый. Әгәр тәшрике мәсагый (хезмәттәшлек) итәргә ниятеңез тулыдан булса, табигый, сөйләшермез, язышырмыз, бер карарга килермез. Хәзергә шуның берлә хушыгыз. Рәбига[2] ханымга бик зур сәлам. Фуадка[3] (булса), Ибраһимга күп сәлам.

Гаяз Исхакый
11 март, 1929. Варшава

ӨЧЕНЧЕ ХАТ

Рәшид әфәнде!

Сезнең ике мәктүбеңезгә дә бик озак җавап бирә алмадым. Минем хәзер эшем бик күп тә, вак-төяк кечкенә мәсьәләләр вакытны эстиләр дә, кирәк эшләр читтә кала бирә. Бу да шулай булды. Гафуыңызны үтенәм. Мәҗмугада яза башлавыгызга бик рәхмәт, күптән шулай кирәк. Мәҗмуга һәммәмезнең көче берлә генә барса бара ала, югыйсә, бер-ике кеше мәҗмуга чыгару модасы инде үткән. Безнең, башлап китеп, күп язулар юлга чыгарырга ниятемез. Ләкин мәкаләләрегездә арасыйра (ара-тирә) милли хәлләремезгә күчкәләргә кирәк иде. Мәсәлән, төрек-татар теленең байлыгы, эластичныйлыгы, аһәңле мәгънә хакында Аурупача карап, Аурупа лисан (тел) галимнәренә таянып, берме-берничәме мәкалә кирәк иде. Бу безнең матур телемезне бозып ята торган ахмак татар малайларына бер гыйбрәт булыр иде. Бу кирәк һәм дә сезнең кебек лисаниятче бер кешенең каләменнән чыгарга кирәк. Моны, әлбәттә, үзеңез дә уйлый торгансыздыр.

Байракка килгәндә, җибәргән үрнәгеңез өчен бик рәхмәт. Мин аны бик матур, мәгънәле таптым. Ләкин, мәгаттәәссеф (үкенечкә), бераз соңга калган. Монда, безнең яши торган мәмләкәттә шуңарга зур бер ихтыяҗ булганга, без кышкы мәҗлесебездә аны мөзакәрә итеп (тикшереп), ике төстә һәм дә Алтын Урда тамгалы иттереп кабул иткән идек вә шуны мондагы мөәссәсәләргә (оешмаларга) җибәргән идек. Хәзер инде аны үзгәртү уңайсыз бер хәл ала. Харита (карта) хакындагы фикерегез бик тугры. Бу хакта анда сездә көтепханәдә мәнбәгъләр (чыганаклар) бик күптер. Монда миндә әүвәлан (электән), унсигезенче гасырда Амстердамда басылган татар харитасы бар. Шуның копиясен алдырып ятам. Алар берничә дәвергә гаид (карый), берничә төрле, аларны сезгә җибәрермен. Икенче — этнография харитасына ярый торган Парис әллисани шәркыйа (Париж Көнчыгыш телләре) мәктәбе мөдәррисе (...) Дениненң «Төрек грамиры»на («Төрек грамматикасы»на) бастырган лисанның таралуы харитасы бар. Өченчесе — аннан-моннан гына булса да туплап басылган Әкъдәс Нигъмәтнең «Төрек елы»ндагы харитасы бар. Ләкин боларның барысы да безгә материал гына булырга ярыйлар. Безнең киләчәк дәүләтемезнең ходудларына (чикләренә) мөмкин кадәр иске тарихи йирләремез керү кирәк һәм дә дәүләтемез эчендә урыс гонсырының (элементының) аз булуы кирәк. Шул ике нокта бер-берсенә тискәре килә дә йөдәтә. Минемчә, Казан, Әстерхан, Оренбур, Уфа вилаятьләре тәмаман (тулысынча), Иделнең агуы берлә барганда, Азия ягындагы Сембер, Самара, Сарытау губерналарының өязләре вә аңа Пиремнең татар өязләре керергә тиеш. Шәрекътәге ходудымыз Урал елгасы булса, Шәркый шималидә (Төньяк-көнчыгышта) ходудымызны ничек теләсәк, шулай киңәйтергә имкян (мөмкинлек) бар. Чөнки анда без үземезнең Себер татарларымызга таба чикләтәмез. Урыс гонсыры анда үзе дә бик сыек. Идел буенда, хосусән, Самара, Сарытау губерналарында гына хәлемез авыр. Ләкин Әстерханны читтә калдырып, Каспий

---

[2] Рәбига — Р.Рәхмәтинең хатыны.

[3] Фуад — Фуад Туктар (1880-1938), сәясәтче, журналист.

диңгезеннән озакта калып, хәзерге Татарстан, Башкортстан ходудында калу, әлбәттә, бернигә дә ярамый. Ул диңгезгә чыкмаган мәмләкәт, үзенең кардәшләре берлә контакт ясый алмаган мәмләкәтнең яшәве бик авыр. Шул кулыңыздагы материалларны җыеп, мөмкин кадәр тизрәк бер этнографик харита, бер дәүләт харитасының проҗәсен (проектын) хәзерләгез әле. Язга таба, дәресләр беткәч, үзем дә Берлинга барып чыгармын дип торам. Шунда мөзакәрәгә куяр идек. Бу да бетте.

Ибраһим нишли? Әгәр теләсә, аны монда гаскәри доктор иттереп урынлаштырып булыр иде дип уйлыйм. Шул хакта үзенә хат язып сораңыз әле. Ләкин инде ул Ләһстанга йирләшү — большевик дәверендә Русиягә кайтудан колак كактым, дигән сүз була. Акса Шәрекътән (Ерак Көнчыгыштан) беркем дә хат язмады. Шуңарга бераз гаҗәпсенебрәк торам. Аннан укырга килергә теләүче чибәр егетләр юкмы? Алай итеп, болай итеп, Ләһстан дарелфөнүненә тәхсыйсатлы таләбә (стипендияле студент) иттереп кабул иттерә алыр идек. Шул хакта уйлашыңыз әле. Хуш.

Рәбига ханымга, Фуадка, Ибраһимга бик күп сәлам.

Гаяз
28 апрель, 1929

ДҮРТЕНЧЕ ХАТ

Хөрмәтле Рәшид әфәнде!

Мәктүбегезне алганга шактый вакыт үтте. Җавап яза алмадым, гафу итәсез. Эшләр бик күп булды. Зөһрә Кошайга[4] зур эш эшләп булмады. Моннан үз арада туплап, 120 марка кадәр бер суманы Таһир адресына күндердек. Аңарга Финляндия адресыны бирдем. Румыниядә «Әмәл» мөдире Мөстәҗаб Фазыл әфәндегә язсаңыз, бәлки бер нәрсә чыгарыр. Анкарада Кәмал Локман бер эш эшли алыр, ләкин минем аларга язып сорашырга, мәгаттәәссеф (үкенечкә) вакытым мөсәгыйд түгел (мөмкинлек бирми). Бу бетте.

Икенче мәсьәлә. Мәҗмугада сезнең мәкалә-фәлән чыкмады. 15 октябрь хакындагы хисап та Ләбибнекенә[5] охшый. Күптән инде, сәркатиблек исеменә дип, монда хариталар алып булу хакында мәктүб язылган иде, җавап булмады. Шул эшләрне, булдыгы кадәр юлга куеп, эшләрнең баруы төртелми торган гарызда (рәвештә) хәл ителүе матлубтыр (сорала-дыр). Моңгынчага кадәр җыелышып утырышуларыңыздан да һичбер хатхәбәр булмады. Табигатьләр килеп җитмәсә дә, эш өстендә, эш ягыннан карап, эшчелектә иптәшлек ясау авыр нәрсә түгелдер, шуны мөмкин кадәр мөлаемәнә идарә итеп алып баруыңызны үтенәм.

Харита мәсьәләсе фәүкылгадә (чиктән тыш) мөһим бер хәлгә керде. Монда хәзер французчага, ләһчәгә бер пропаганда әсәрен тәрҗемә иттерәмез. Шуның эчендә харита булу лазем. Бу хакта материал алышуга, бу яктан ярдәм итеп була иде. Ләкин сезнең тарафтан һичбер хәрәкәт сизелмәде. Киләчәк мәҗмугага, мохаккак (һичшиксез), бернәрсә кертеңез һәм дә киләчәктә дә иштирак итеп (катнашып) барыңыз. Эш гомуми эш булганга, Ләбибкә үпкәләүдән, әлбәттә, бик югары торырга тиештер. Хушыңыз.

Рәбига ханымга сәлам. Әгәр мәкаләңезне аннан үткәрү уңайсызлык ясаса, монда күндереңез. Ләкин бу номер өчен инде алай итәрлек вакыт калмагандыр. Монысын аннан гына кертеңез.

Гаяз Исхакый
14 ноябрь, 1930

Кереш мәкаләне һәм хатларны басмага Г.Исхакый исемендәге бүләк иясе ***Лена Гайнанова*** *әзерләде.*

---

[4] Зөһрә Кошай — 20 нче еллар башында Германиянең Дрезден шәһәрендә педагогика факультетын тәмамлаган татар кызы.

[5] Әхмәт Ләбиб Каран (1887-1967) — табиб, шагыйрь һәм галим.

ШАГЫЙРӘ,
С.СӨЛӘЙМАНОВА ИСЕМЕНДӘГЕ ӘДӘБИ ПРЕМИЯ ЛАУРЕАТЫ

ФЛЁРА ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА

(06.09.1931)

УЙЛАР ВАТАНЫ

I
...Мин уйланам! —
Уйдан китә алмыйм,
Көтә алмыйм шатлык,
тантана...
Милләтемә дан җырлаган саен,
Йөрәгемнән тып-тып кан тама.

Милләт зурдан баш калкытты исә,
Ябырыла илгә мең яла.
Алдаша да туры күзгә карый,
Яла колы белми ояла.

II
Хаклык турындагы һәрбер уем
Ага төптән агым уйнатып...
Төптән өзгәләнгән хаклыгыма
Дәва табалмадың, и вакыт!

Бер яклаусыз калган хакыйкатькә
Төптән килү әллә хатамы?
...Уйланмыйча яшәү мөмкин түгел,
Минем күңел — уйлар Ватаны!

III
Уйлы-моңлы бишек җырым белән
Тибрәтәм мин былбыл оясын...
Чиксез уйларымда уелсам да,
Ояларны килми җуясым.

Урыныннан кузгатасым килми
Түрдә торган бала бишеген...
Китә алмыйм бишек тирәсеннән,
Чөнки үзем Ана кеше мин!
Хакыйкатьнең сүнмәс хисе мин!

* Шагыйрә Флёра Гыйззәтуллинаның кайбер сүз энҗеләре белән журналның башка битләрендә таныша аласыз.

ӘДИПЛӘРЕБЕЗ МИРАСЫННАН

КЫЛДАН НӘЗЕК, КЫЛЫЧТАН ҮТКЕН*

Роман

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ

4

Улы белән аз сөйләшәләр иде алар. Иң кирәген генә, иң саен гына. Хатыны: «Улыңның рухи тормышы белән кызыксыныр идең ичмасам», — дигән минутларда ул гел бертөсле җавап бирә иде: «Мин ата канаты астыннан унҗидедә чыгып киттем һәм шуннан бирле үз башым белән көн күрдем! Әгәр бүгеннән юк икән, аннан киләчәктә дә берни көтеп булмый. Абынса, хәзер абынсын! Соңрак абынса, ныграк авыртыр. Абынсын да егылып ятсын. Уйланыр!» — дия иде.

Теле шулай дисә дә, Мирзанур үтә көнче ата иде. Ул егетнең кая барганын, кем белән очрашканын, ниләр эшләгәнен читләтеп-читләтеп кенә һаман белешеп тора, җае килгәндә, астыртын рәвештә хатыны аша да улының серен ала иде. Әмма шушы кыска-кыска сөйләшүләрдә дә Мирзанурның бер генә мәртәбә дә әткәсен, ягъни егетнең бабасын телгә алганы юк иде. Ул үз соравына бер гаҗәпләнеп калса, улының төпле һәм бераз чәнечкеле контрсоравыннан бөтенләй телсез калды... Каян башына килгән диген!

Бүлмәсенә кергәч, ул гадәтенчә ишекне ачык калдырмады, әйбәтләп, тыгызлап япты, түбәтәен салып күз алдына, өстәлгә куйды, галстугын бушатып чишеп җибәрде. Аякларын сузып, җәеп йомшак кәнәфигә утырды.

Чыннан да, беләме ул бабасын? Хәтерлиме? Дөрес, кеше гомере өчен бу сорауның бернинди әһәмияте булмавы мөмкин. Кешеләр, үзләренең нәсел җепләре, каян, кем нәселеннән килеп чыгышлары белән бик сирәк кызыксыналар. Әмма каһәр төшкән зәңгәр тышлы дәфтәр булмаса, бүген Мирзанурдан да бәхетле кеше булмас иде бәлки. Чыннан да, ни ваемы бар аның? Фатиры бар, хатыны уңган, улы да әлегә яманлыкта йөрми, аны өметле киләчәк көтә. Сәламәтлеккә дә зарлана алмый Мирзанур. Беркөн танышын күмәргә баргач, ташлар арасында йөргән иде, аның күпме яшьтәшләре, аннан байтак яшьрәкләр әллә кайчан җир куенында ята. Ул исән-сау, авырырга да җыенмый. Тик теге дәфтәр генә...

Бабасы ничек һәм кайда үлгән иде соң әле? Әтисе сөйләгән дә иде бугай. Әллә егерме алтынчы, әллә утыз алтынчы елларда инде... Читтә яшәгән ул, яшьтән зимагур булган, өйләнеп, авылда аз-маз торган да тагын чыгып киткән. Шул чыгып киткәнендә югалган да бугай инде... «Җирән сакаллы, озынча, какча карт иде», — дип сөйләде әтисе...

Сөйләгән кадәресе онытылган, белгән кадәресе үз улыңа җавап бирерлек дәрәҗәдә түгел. Уңайсыз хәлгә куйды егет туры сорау белән әтисен! Бер атуда тиеннең күзенә генә чәпәде!

* Дәвамы. Башы журналның 7-8 нче саннарында

Аяз һәм Нәкыя Гыйләҗевләр. 1988 ел



Кыек атып, туры тидерү менә шулай була торгандыр инде.

Урамнан тәрәзә пыялаларын зыңгылдатып дәү-дәү машиналар уза.

Мирзанурның күңелен уйнатып, авыр уйлар кузгала.

— Чәй ясап кертимме, әтисе?

Хатынына ул «юк» дип бер генә эндәште. Күңелдәге уйларны чәй генә юа торган түгел иде.

Әйе, Мирзанур хәзер аңлый: әтисенә бер дин өчен, муллалык хезмәтен үтәгән өчен генә әр ташламады ул. Аның башка, күзгә күренеп бетмәгән бик күп сәбәпләре бар иде. Энесе Габделхай өйләнде. Казан кызы алды: гади кыз гынамы сиңа, райком секретаре кызы — Верховный совет депутаты, президиум әгъзасы кызы. Кызның әнкәсе дә дөнья таный белә торган, киң карашлы хатын. Бай кызы булган, имеш. Яшь милиционерга гашыйк булган да, әтиәнисенең каршы торуына карамастан,ябышып чыккан, мин сине кеше итәм, дигән. Һәм кеше дә иткән, Мөхәммәт Закировның шундый зур урыннарга үрләвендә хатынының да хезмәте ифрат зур, ирне тота белде, тиешле сукмакларны алдан күрсәтергә акылы җитте дип сөйлиләр. Ә акыллы хатын гаиләдә зур байлык, сукмакларда адашмаган ир, олы юлга тап булгач, шунда ук үзгәрә, ирлек сыйфатлары өстенлек итә башлый... Закиров белән дә шулай булган, бер иярләп алгач, юртактан төшмәде, гел чабышта, гел бәйгедә булды. Кайларда гына чабышмасын, ул офыкта һәрчак хатынының чак кына көлемсерәгән таләпчән күзләрен күреп торды.

Габделхай шушы гаиләнең бик иркә, бик сылу төпчек кызлары Нурияне алып кайтты. Бу Мирзанур өчен көтелмәгәнрәк хәл иде. Аның да олы, могтәбәр, абруйлы кешеләр белән аралашып, алар арасына катышырга кызыгып йөргән чоры иде. Һич көтмәгәндә Закиров белән кода булдылар, кунакка йөрешә башладылар, Закиров картның тәмләп кенә сала торган чагы, Мирзанур да тәмен белеп кенә эчә торган зат, килеште боларның серләре! Икәүләшеп түрдә утыралар: «Кода да кода!»

Берзаман авылдан Мирзанурның әтисе килеп төште. Табигый буларак, аны кодаларга кунакка алып бардылар. Ни гаҗәп, Закиров белән әтиләренең сүзе килешмәде, әллә нигә яратмадылар аны, Фазыйла кодагый кодага әйләнеп тә карамады, тырт-пырт кына бармак очларын биреп күреште дә: «Башым авырта», — дип, үз бүлмәләренә кереп бикләнде. Чыгып та карамады. Закиров ясаган сыек чәйне аннан-моннан

эчеп, ике сүзгә яртышар сәгать тыныш ясап таралыштылар. Мирзанур өйгә кайтышлый: «Йә, ничек, кодалар ошадымы?» — дип сорады. Карт алдан ук бу сорауга әзерләнеп барган ахрысы, туп-туры ярды да салды: «Яратмаганнар алар кызларының авыл егете Габделхайга чыгуын, яратмаганнар! Кыз теләгенә аяк терәп каршы да килә алмаганнар! Шуның үчен рәхәтләнеп миннән алдылар. Хәерле булсын, мин торасы кыз түгел!»

Габделхай белән Лира ялга Кавказ тауларына киткәннәр иде, икесе дә разрядлы турист булып әйләнеп кайттылар. Әтиләре турында сорашырлармы-юкмы дип йөргән иде Мирзанур, ай үтте, ике ай узды, Габделхай да, килен дә әтиләре турында сүз кузгатмады. Мирзанур да, ни сәбәптәндер, ул турыда аларга әйтеп, төпченеп торуны кирәк санамады.

Берзаман Закиров та пенсиягә чыкты, түгәрәк кенә карт булып, вәкарь белән генә сөйләшеп, өстән генә карап, вагон эскәмияләрендәге тәрәзәне уң якта калдырып (машинада йөреп өйрәнелгән гадәт!), утырып дачага йөри башлады, Мирзанурлар дәрәҗәсенә төште. Әмма авылдагы кодасына мөнәсәбәте берчакта да үзгәрмәде. Кунакка чакырмады, хәлен сорашмады, белешмәде. Алай гынамы сиңа, бер мөнәсәбәте белән аның югары дорфалыгына өйрәнә башлаган Мирзанурны да шаккатырды. Җәй иде. Әтисе тагын кунакка килеп чыкты. (Соңгы килүе булды мәрхүмнең!) Закировның үзен еш күрмәсәләр дә, Мирзанурлар аның күпсанлы улларын, киленнәрен, яки күрше-күләннәрен күргәләп, сирәк-сорак кына булса да шалтыратышып, хәл белешкәләп торалар иде. (Габделхай белән Лира ялда, Тува якларына нindidер тауларны өйрәнергә киткәннәр иде!) Мирзанур әтисен дачага алып китте. Карт шәһәр йортларын әле һаман да өнәп бетерә алмый, бигрәк тә туалетның кухняга янәшә булуына һич күңеле кереп бетми иде. Хуш, дачада тора бу, йорт тирәсендә нидер төзәтә, тәрәзә замаскаларын яңарта, нигезнең какшаган кирпечләрен ныгыта, Мирзанур да отпускада чак. Алай күтәрелеп үк чыкмаса да, әткәсенә караңгы чырай биргәне юк, яшиләр. Беркөнне, өйләдән соң тирләп-пешеп чәй эчеп утырганда, кемдер кереп: «Сезне роща янында белешләрегез көтә!» — дип чакырды. Мирзанурларның дачалары белән рәттән асфальт юл уза, ике арада матур гына каенсар, ул шул асфальтка чыкты һәм каен күләгәсенәрәк кереп туктаган машинаны күрде. Машина Закировның олы улы Илдусныкы, имеш. Закиров карт та шунда. Мирзанур, бер шәпкә кызып китеп, кодаларны кунакка дәшә башлады. «Әти дә килде», — дип ычкындырды. Пеләшен кулъяулыгы белән иркәләп утырган Закиров тук ирен читләрен бөрештереп кенә әйтеп куйды: «Ишеттек!» Кодалар кермәделәр, юк кына бер нәрсәне ачыкладылар да китеп тә бардылар. Аларның берәм-берәм машинага төялүләре, нindidер олысымак кыяфәтләре Мирзанурда чак кына көнләшү дә уятты бугай. Ничек тату һәм дус яшиләр бу Закировлар! Бергә төйнәлеп алганнар да арага беркемне кертмиләр! Бар иде Габделхай — йоттылар егетне, юк хәзер! Лира туризмны ярата дип, ул да шуңа иярде, башка гадәтләрендә дә Закиров булды да калды. Икенче кияүләренең дә Закировларның каз оясына кереп утырган бәбкә сыман гына калганын Мирзанурның күзәткәне бар иде инде.

Һәм ул Закировларга, олы кодага үпкәлисе урынга әтисенә үпкәли башлады. Аның ачык якасыннан күренеп торган ябык муены да, эре-эре тамырлары калыккан, ял белмәгән бирчәйгән куллары да (авыл укытучысы ул заманда крестьяннан бик аз гына аерыла иде!), бәрәңгене тәмләп ашавы да, тезенә ялгыш төшкән ипи валчыкларын берәмтекләп җыеп утыруы да ошамады. «Әйе шул, нигә инде моның янына

затлы, олы кешеләр керсен! Кем моның белән аралашсын!» дип уйлады ул. Кызганычка каршы, уйлаганын яшерә белми иде әле Мирзанур, мәхәббәте дә, усаллыгы да тиз үк тышка бәреп чыга: бите аллана, колагы торып кызара, ике күзе дә борын янынарак килә, ул туптуры карап, төнтекләнеп утыра башлый. Ата кеше үз баласының горефгадәтләрен белмиме?! Чәй яныннан чыгып киткән улының сөмсере коелып кайтып керүен һәм моның сәбәпчесе үзе икәнен карт бик тиз аңлап алды. Тагын бер-ике көн торырмын әле дисә дә, кичкә таба җыена башлады һәм саубуллашып чыгып та китте. Ишек катына җиткәч борылды, көрсенеп, борынын сеңгерде: «Алай да Габделхай кунакка кайтсын! Киленне әйтмим инде, вакыты юктыр! Мәгәр Габделхай кайтсын! Берике көнгә генә булса да!»

Нигә шул чакта Габделхайны гына чакырды ул? Мирзанурдан өметен өзеп бетергән идеме? Габделхайны аз булса да Закировларның татлы төрмәсеннән коткарып торырга уйладымы? Әмма өзелеп-өзелеп чакырды, күзләре дымланды, бөкре юка гәүдәсе тагын да юкарып, мескенләнеп калды. «Бар, озат инде!» — диде хатыны ул чыгып киткәч Мирзанурга. Мирзанур икеләнеп торды һәм картны асфальтка чыгып җиткәндә генә куып җитте. Каен төбенә үк кергән машина эзләрен күргәч, ул Закировларның, бер булып, бердәм булып, машинага төялүләрен күз алдына китерде һәм ачуы тагын аларга түгел, шым гына атлап барган әтисенә чыкты. «Яшәгән инде шунда иләк белән су сөзеп! Юк хыяллар белән! Әни аннан наданрак булган, алай да сугышка кадәр үк: «Чаллыга күчик, кешечә яшәрбез!» — дип үгетләгән. Ә бу яткан шунда караңгы керәшен авылында бурсып!» — дип уйлады ул.

Станцияләре ерак түгел, тиз үк барып җиттеләр, карт билетка үзе түләде, салкын гына аерылыштылар. Мирзанур поезд кузгалганны да көтеп тормады, томанлы тәрәзә аша күренгән әтисенең шәүләсенә кул болгады да китеп тә барды.

Өсте-өстенә, һәрнәрсә күзгә күренмәслек вак-төяктән башлана, бер күзәнәге китсә, бәйләнгән әйберләр тузып тарала, зур дәрьяларның башы да нәни генә сызылып чыккан чишмә була! Тау кабыргаларына убылып-убылып яткан тирән, иләмсез ермакларны да челтерәп кенә аккан нәни гөрләвекләр башлап җибәргән. Күңелне тырмап, эз калдырган сүзләр, кырын карашлар әллә нинди дошманлыкларга сәбәп була. Әтисен яратмый башлады Мирзанур.

Тагын бер нәрсәне хәзер үк ачыклап китәргә кирәк. Тормыш, кешенең яшәү мөмкинлекләре һәм бурычлары бик күп төрле законнарда чагылыш тапкан. Без уйлап тормасак та, адым саен законнарга буйсынып яшибез. Конституция бар, эш урынының кагыйдәләре бар, техника безопасности, урам хәрәкәтләре законнары безнең һәр адымыбызны алдан ук белеп, чамалап, билгеләп куйган. Без медицина законнары кушканча ашыйбыз, профсоюз биргән хокукларга буйсынып, ялга барабыз, балык тотуның да, урамга тәмәке төпчеге ташлауның да иреге һәм чикләүләре бар. Бер генә нәрсәдә катгый закон юк: ата-анага мөнәсәбәттә. Дөрес, монда да аларны тәрбия итү турында законнарда әйтелгән. Тик менә яратасыңмы син аларны, юкмы — бусы синең шәхси үз эшең, моны закон калыбына кертү мөмкин түгел. Чөнки бер гаилә икенчесенә бер чакта да охшамаган. Толстой да бу җәһәттә ялгыша. Ул: «Бөтен бәхетле семья бер-берсенә охшаган», — ди. Матур сүз! Әмма бәхетнең чиге юк, әнә шул чиксезлек гаиләләргә бер-берсенә охшарга мөмкинлек бирми дә инде! Бәхетле гаиләләр дә бәхетнең чиксезлегенә төшенеп җиткәч кенә, бәхетсезләр юлына да төшкәлиләр! Заман үзгәрде!

Тормышның башка кагыйдәләрен

бик нык төгәллек белән үтәп, законнарга педантларча буйсынып яшәгән кешеләрдә сирәк булса да бер гадәтне күзәтергә туры килә: алар ата-аналарына карата ваемсыз була. Чөнки законнарның барысын да бөтен ваклыкларына кадәр бары тик коры кешеләр генә үти. Мирзанур хәзер әнә шундыйлардан иде. Взносларны, ут-су өчен түләүләрне ул берәр-икешәр ай алдан ук түләп куя. Таныш-белешләренең туган көннәре аерым бер биткә бик җентекләп язып куелган, кәгазьне күз алдында гына тота Мирзанур. Һәм, Ходай сакласын, берәрсе онытылып калмасын тагын! Бәйрәмнәрдә ул дусларына, таныш-белешләренә йөзләгән открыткалар яза, йөзенә дә бер үк сүзләрне һәм һәр елны бертөсле үк сүзләр белән белдерсә дә, бер чакта да онытмый, соңга калмый. Чөнки закон, тормыш шуны таләп итә! Үзенә җавап язмаганнары өчен дә үпкәләми, һәр елны, һәр бәйрәмдә диярлек бер үк кешеләрне котлый.

Семья менә ничә еллардан бирле инде ныклы бер тәртипкә кергән, мебельләр, кузгалмаска тамыр җибәреп, үз урыннарына кереп урнашкан, китапханәгә дә китаплар байтак еллардан бирле өстәлми, чөнки алары да Мирзанурның гомеренә җитәрлек алынган, ашау-эчүнең дә ныклы бер тәртибе бар, хатыны да иренең ни тәпсерләвен белеп бетергән. Һәммәсе кагыйдәләргә буйсынган, ныгыган һәм үзгәртерлек сәбәп тә, ихтыяҗ да юк иде.

Әтисе, авыл, туган-тумачалар бу тормыштан күптән сызып ташланган, онытылган һәм аларның кирәклеген беркем дә сизми, юксынмый да иде.

Зәңгәр тышлы дәфтәр Мирзанур өчен искиткеч яңалык булды.

Ибрайларга коръән ашына төшү, анда утыру, гомумән, акылга сыймый торган хәл иде!

Байтак утырды болганчык уйларга уралып Мирзанур, акыллы бер нәтиҗәгә дә килә алмагач, үз уе юнәлешенә үзе дә исәп биреп бетермәстән, тагын Ибраһимнарга төшеп китте. Хуҗалар аны аптыраш белән каршыладылар. Мәсрүрә табын урынын җыештырып бетереп килә, Ибраһим юылган, корытылган аш тәлинкәләрен савыт-саба шкафына тезеп маташа иде.

— Мин йөрим әле монда, — диде тамагын кырып Мирзанур.

— Әйдүк, рәхим ит, — диде Ибраһим, кулларын тезенә ышкып.

— Мин шуңа керүем иде. Минем катнашу бик күңелсез, җайсыз булмадымы?

— Кая ул, нишләп алай булсын? Олыладың безне, әнкәй дә бик разый булып калды, — диде хуҗалар бер авыздан. Мирзанур почмакта, карават өстендә аякларын бөкләп утырган әбекәйне шунда гына абайлап алды.

— Моңарчы андый эштә бер дә катнашмагач… Җолаларын да белмим… Бер-бер хаталык ычкынмады микән дип төшүем иде.

Мирзанурның бу сүзе рас иде, шулай дип төшкән иде төшүен. Тик ул үзендә гаҗәеп бер үзгәреш сизде: сөйли, сөйләгән саен, шикләнеп һәм куркып, як-ягына карана. Бер дә андый гадәте юк иде моңарчы, күптәннән инде туптуры басып, күкрәкне аз гына алгарак чыгарып, кирәк чакта карашын кеше янышнан үткәреп җибәреп, кирәк икән нәкъ күзгә кереп сөйләшә иде ул. Бүген муены як-якка бөгелгәнен үзе дә сизде, тик үзе элек күнеккән, гадәтләнгән кыяфәтне таба алмады. Сүзләре дә язгы ташкын кебек гөрелдәп түгел, ишек ярыгыннан мыраулаган мәче тавышы булып кына ишетелделәр. Ялынып, ялварып сөйләшә иде бүген Ибраһимның гайрәтле күршесе. Моны, ахрысы, Ибраһим белән Мәсрүрә дә сизде, алар гайрәтле күршеләре янына, батыраеп, якынрак килде, Ибраһимның йөзен елмаю каплады. Мәсрүрә тагын бер тапкыр:

— Әнкәй дә бик рәхмәт укыды

Сезгә. Ипле кеше икән, ди. Яхшы кеше! Күрше хакын гына хаклап кермәгән бит ул, әрвахларның тынычсыз рухын да олылаган.

Мирзанур әрвахның ни, кем икәнен дә белеп бетерми иде, рух сүзе кушылгач, ул сүзнең үлгәннәр турында барганлыгын аңлады, күңеленнән генә: «Әрвахлар, әрвахлар… Берәр төплерәк сүзлектән карарга кирәк булыр моны», — дип уйлады.

— Ярый алайса! Хаталыгым юк иде, дисез инде! Рәхмәт!

Һәм ул баядан бирле кесәсен яндырып торган өч сумлыкны әбигә илтеп сузды.

— Рәнҗемичә генә алыгыз сана шуны!

Әбекәй, тешсез авызын кыймылдатып, рәхмәт укыды һәм озак итеп дога кылды. Дога беткәнне көтеп торган Мирзанурның күз төпләре дымланган кебек булды. Җылап җибәр тагын, сантый, дип сүкте ул үз-үзен һәм хуҗалар белән саубуллашмыйча да чыгып китте, өченче катка култыксага тотына-тотына менде, йөрәге күкрәк читлегеннән чыгардай булып тибә, чигәләре тоташ сулкылдый, тез буыннары сызлый иде.

Ул, ни булганын, үзенең ниләр эшләгәнен аңларга тырышып, озак кына диванда аунады. Диван пружиналарын сытардай булып як-ягына әйләнгәләде. Ләкин күңелгә иңгән сорулар буталчык иде, алар, укмашып, уйга бер юнәлеш бирә алмады. Сораулар җавапсыз, җаваплар мәгънәсез иде. Ул зәңгәр тышлы дәфтәр турында, әтисе турында, Коръән турында, бүгенге мәчет картлары турында, аларның гап-гади гражданнар булуы өстенә Ватан сугышы инвалидлары икәнлеге турында да, Ибраһимнарда ашаган итле токмач турында да уйлый иде. Әмма уйларның өстенлек иткән берсе бар иде. Малаеның кинәттән һәм кискен куйган соравы иде: «Ә син, па, үзең бабаңны хәтерлисеңме?»

Үткәннәргә йомгак ясаганда, кеше һәрчак алда ничек яшәргә дигән сорауны да куя. Үткәннәрне уйлау — киләчәккә карарга тырышу да бит ул. Һәм Мирзанур Янык авылына кайтып килергә булды. Быелгы ялы үткән булса да, бер-ике көнгә генә үз хисабына кайтып килә ала ич. Яныкта ике-өч көннән дә артык тормам дип уйлый иде ул. Бу фикер аңа төнге икеләрдә килде. Ул түзә алмады, күрше бүлмәдә йоклап яткан хатыны янына кереп сыенды. Хатыны уянды һәм йокы аралаш, әмма ап-ачык итеп: «Сәгать ничә, әтисе?» — дип сорады.

— Өченче бугай… Йокла син, йокла! — диде. Аннан соң гына өстәп куйды: «Мин Яныкка кайтып килергә булдым әле».

— Кайчан? — диде хатын, юрганын ача төшеп.

— Бүген үк булмас инде. Эштә кайбер нәрсәләрне хәл итәргә кирәк.

Хатыны йөзе белән борылды, җылы һәм татлы исле тәне белән аңа сырышты һәм үксеп-үксеп елый башлады.

— Кайтып кил, әтисе, кайтып кил. Күңелемә ачык: син тиз генә тынычлык таба алмассың хәзер. Сиңа килгән тынычсызлык мине дә изәчәк! Кайтып кил! Мин риза! Бик риза!

Хатынының мондый кинәт дулкынлануы, сорашып та тормастан риза булуы аны тагын да гаҗәпләндерде. Хатынының бик нык күзәтеп яши башлавын һәм моның кайчан башланганын Мирзанур белми иде. Гомумән, тормыш, яшәеш хакында алар аз сөйләшәләр иде. Тик аның хатыны сизгер, акыллы хатын иде. Сизгерлеге аркасында ул Мирзанурның җанына ярамаган сораулар бирүдән сагая иде. Ләкин иренең җаны аның өчен шактый ачык, аңлаешлы иде. Ул барын да аңласа да, Мирзанур аның янып, кабынып китүен аңламый калды.

Ахыры киләсе санда

«БЕР-БЕР АРТЛЫ ЗАМАНДАШЛАР КИТӘ, ӨЛГЕРАЛМЫЙСЫҢДЫР КУЛ БОЛГАРГА...»

ШАГЫЙРЬ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГАН СӘНГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ, ТР МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ ҺӘМ ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНЕҢ Г.ИСХАКЫЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЫ **ХАРРАС ГЫЙЛМЕГАЛИ УЛЫ ӘЮПОВ** 1946 ЕЛНЫҢ 21 АВГУСТЫНДА ТАТАРСТАННЫҢ МӨСЛИМ РАЙОНЫ ТҮРЕШ АВЫЛЫНДА КОЛХОЗЧЫ ГАИЛӘСЕНДӘ ТУА. 1964-1969 ЕЛЛАРДА КАЗАН УНИВЕРСИТЕТНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ БҮЛЕГЕНДӘ УКЫЙ. 1969-1972 ЕЛЛАРДА МӨСЛИМДӘ ЧЫГА ТОРГАН РАЙОН ГАЗЕТАСЫ, 1972-1983 ЕЛЛАРДА «ТАТАРСТАН ЯШЬЛӘРЕ» ГАЗЕТАСЫ РЕДАКЦИЯСЕ ХЕЗМӘТКӘРЕ, 1983-2008 ЕЛЛАРДА ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНЫҢ МАТУР ӘДӘБИЯТ РЕДАКЦИЯСЕ МӨХӘРРИРЕ. 2008 ЕЛДА ВАФАТ. ЖУРНАЛДА ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН ШИГЫРЬЛӘР



Басма китаплары: «Кояшлы яңгыр» (1983), «Каен балкышы» (1985), «Таң суы» (1987), «Төнге кояшлар» (1989), «Сабыр савытлары» (1992), «Ташка язганнар сөюне» (1994 — башкорт телендә), «Җәяүле буран» (1996), «Көй эзләү» (2001), «Ут аркылы сикерү» (2004), «Йөз яктысы» (2005), «Летнее течение» (2008 — рус телендә).

АКСАКАЛГА АЧЫК ХАТ

Кара да гына урман, караңгы төн…
Төн түгелдер — Илнең көнедер ул.
Карурманнар уртасында калгач,
Ак булулар җиңел түгелдер ул.

Караңгылы-яктылыга сизгер:
Янәшәңдә йөрми кемнәр генә! —
Мәңгелеккә күчкән Аксакаллар
Әйләнгәләп куя гүрләрендә.

Астыртыннар өскә калыкканда
Асыл ирләр җирдән китеп бара.
Сакал булыр ла ул,
Заманада
Ак көенчә менә яшәп кара!

Булыр ла ул сакал…
Яшәп кара
Рәнҗетмәслек итеп дөньяларны,
Онытмаслык итеп әле бүген
Җиһан уртасында син дә барны.

Кара да гына урман…
Ак җаныңны
Сиздермичә төртеп екмасыннар! —
Мәңгелеккә күчкән Аксакаллар
Кубарылып каршы чыкмасыннар…

2008

КАЙТЫП ТОРМАМ…

Сөргән Ходай.
Оҗмахлардан сөргән.
Без — шул сөрелгәннәр нәселеннән.
Әйтеп бетермиләр дөреслекне:
Мәңгелеккәниләр яшерелгән?

Түзәлерме җиһан,
Озаккамы
Бу язмышлар адәм баласына? —
Синең белән без бит әле һаман
Оҗмах белән тәмуг арасында.

Бөтенесен күреп тора Ходай.
Адәм заты юкка сөрелмәгән!
Яннарымда минем син булганда
Кайтып тормам, ахры, сөргеннәрдән,
Кайтып тормам…

2007

СҮЗ ӘЙТМӘГЕЗ…

…Хәмдиягә сүз әйтмәгез —
Зиһене таралган чагы.
(Рәшит Ваһапов репертуарындагы
«Хәмдия» җырыннан.
Мирхәйдәр Фәйзи шигыре)

Үзәкләр бик өзгәләнгәндә дә
Сүз әйтмәгез берүк, әйтмәгез сүз,
Тын калыгыз… Бары тын калыгыз…
Күктән иңгән моңны тыңлагыз сез.

Бик таманга туры киләчәктер,
Гомер буйларына тыңласаң да.
Күтәрер дә —
Кире төшәлмәссең,
Инде фәрештәләр булмасаң да.

Бер елата, бер юата икән:
Әллә кайда түгел, монда бит ул,
Сүз әйтмәгез берүк, әйтмәгез сүз —
Моңнан гына торган дөнья бит ул!

Тыңласаң да гомер буйларына,
Җитми кала барыбер, җитми ара.
Билгеледер: мәңгелектән килгән —
Ул барыбер мәңгелеккә бара…

2008

МАТБУГАТ ЙОРТЫ БЕЛӘН ХУШЛАШУ

Авыр чакта елый алмый ирләр.
Күпме яшьләр эчкә йотылган!
Бисмилласыз гына чыгып киткән
Идемме әллә туган йортымнан?!

Язмышыма — шуның каргышымы? —
Туган өйнең игез сыңары…
Төшләргә дә кереп карамады
Аның болай юкка чыгары.

Авыл белән хушлашмадык шул без,
Хушлашмадык туган өй белән.
Кинәт беркөн йөрәк тамырыңа
Сугачагын аның кем белгән?!

Инде менә… Игез сыңары да…
Ишеткәндер күпме исемне? —

Күпме исемнәрне җир йөзеннән
Алып китү җиңел дисеңме?!

Авыр чакта дога кирәк, диләр…
Җимерелде еллар, ишелде.
Дога багышларга куркып торам, —
Яшен булып чыгар шикелле…

2007

ИСӘ ВАКЫТ…

Төшәсең су буйларына,
Уйланырга җай кала…
Хәтер тулган.
Өсләрендә
Акчарлаклар чайпала.

Хак Тәгалә дөньяларны
Нигә болай яратты? —
Югыйсә бит мәңгелектә
Балыклар да канатлы!

Җир йөзендә халыклар да
Канатсыз булмагандыр,
Булмагандыр! —
Хәтер тулган,
Бәхетләр тулмагандыр.

Канатларны канатканны
Кем ишетми, кем күрми?!
Исә Вакыт.
Мәңгелектә
Акчарлаклар җилферди…

2008

КАРГА БУРАНЫ

Шәһәрдә карга бураны.
Малайларга кызык:
Йомарлап кар ыргыталар
Һаман кызып-кызып.

Тәрәзәдән карап торам,
Урынында бары да.
Төшәр еллар аръягыннан
Без ыргыткан кар да…

Кара каргалар да килер,
Ак булмаслар инде —
Алар теге малайларны
Апкилмәсләр инде!

Ыргытылып бетә гомер,
Кеше җаны чыдам.
Казанда карга бураны —
Тын алмыйча торам…

2008

***

Тартылган кыл сыман зыңлап тора
Шыр ялангач калган бу киңлекләр.
Ямансудыр… Бәйрәм түгел инде
Җир йөзенә килгән ятимлекләр.

Кими бара дөнья:
Арабыздан
Җелек кебек замандашлар китә.
Кителә чор…
Бөтенлектән безне
Нигә болай мәхрүм итә?!

Сагыш арта. Чаларадыр чәчләр.
Олыгая адәм балалары.
Киткәннәре — җилдер,
Шул җилләрдә
Саргаялар икән калганнары.

Бер-бер артлы замандашлар китә,
Өлгералмыйсыңдыр кул болгарга.
Карап торасыңдыр
Күз алдында
Бетә барган фани дөньяларга…

***

Ир-егетнең йөрәгендә
Җырлыйсы җыры була.
Ул җыр кагылган чагында
Карлар да җылы була.

Аны җырлый алганнарның
Уйлары олы була.
Бары шундый җаннар гына
Халкының улы була.

2007 ■

БУРОВОЙЛАР ГӨРЕЛТЕСЕ

ЭНҖЕ МӨЭМИНОВА

Бер матур җыр ишеттем мин
таң алдыннан.
Җырлап кайтты аны берәү
тау ягыннан.
Күтәрде җыр бик күп тәрәз
пәрдәләрен.
Чиртте бу җыр, чиртте күңел
тәрәзләрен.
Кем күтәрде, кем җырлады
соң ул җырны?
Каян алган җырлаучысы
яңа моңны.
Китердеме аны Әлмәт
нефтьчесе?
Моң бирдеме буровойлар
гөрелтесе?

Тынгылыгым җуйдым менә
шушы көннән.
Сихерләнеп калган сыман
серле көйдән.
Һәрнәрсәдә ишетәм мин
җыр авазын.
Ишетәм мин җәен, көзен,
кышын, язын…

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНӘ

Сәхифәне филология фәннәре докторы ЗӨФӘР РӘМИЕВ алып бара.

Нәфыйков Рәфикъ Измаил улы (1928-2001), тарихчы галим, тарих фәннәре докторы, Казан университеты профессоры, Татарстан Фәннәр академиясе хакыйкый әгъзасы. Тумышы белән Уральск шәһәреннән. Кечкенәдән Тукай шигырьләрен, әбисенең Тукай турындагы истәлекләрен тыңлап, Тукайның балачагы, Уральскидагы тормышы һәм әдәби, иҗтимагый эшчәнлеге белән бәйле биналарны күреп, аталары Тукай белән бергә мәдрәсәдә укыган балалар белән уйнап үсә. Уральск педагогия институтын тәмамлап, Казанга килгәч, ул Казан университетында аспирантурада укый, язучылар белән аралаша, Әхмәт Фәйзи, Вафа Бәхтияровлар белән очрашып сөйләшә. Шул вакытларда ук Тукай темасына, Уральскидагы иҗтимагый тормышка караган мәгълүматларны, документаль материалларны җыйный башлый, Ленинград, Мәскәү, Саратов, Самара архивларында эзләнә.

Нәфыйковның фәнни эшчәнлегендә төп урынны Казан төбәгендә инкыйлаби вакыйгалар, Идел буенда социал-демократик оешмаларның формалашу тарихы, биредәге иҗтимагый хәрәкәтләрдә Федосеев, Ленин, Вахитовларның роле мәсьәләсе биләп торды. Ул беренчеләрдән булып татарның алдынгы иҗтимагый-сәяси фикеренең 1895-1917 елларда формалашу һәм үсеш тарихын нечкәләп өйрәнде һәм 1964 елда аны күләмле монография сыйфатында бастырып чыгарды. Бу хезмәттә, бигрәк тә IV бүлегендә, Тукайның әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеге турында бик күп яңа фактларга нигезләнеп, бөтен Россия фонында сүз алып барыла, киләчәктә ныклап тикшереләсе, җитди игътибар итәргә тиешле мәсьәләләр күрсәтелә.

Нәфыйков соңрак Тукай турындагы фикерләрен, уйлануларын, эзләнүләрен бергә туплап «Тукай һәм даирәсе» дигән китап (1986; рус телендә) бастырды. Аның үзәгендә — Тукай. Ул шәхес буларак та, журналист, публицист, җәмәгать эшлеклесе буларак та киң яктыртыла. Хезмәтнең фактик нигезен Нәфыйковның берничә дистә ел дәвамында җыйнаган материаллары тәшкил итә, авторның XX гасыр башы татар вакытлы матбугатын аерата тәфсилле өйрәнгәнлеге күренә. Китап «Уральск таңнары. Үсүформалашу», «Әдәби һәм мөхәррирлек эшчәнлеге», «Туган җирдә. Халык шагыйре, сәясәтче», «Большевиклар белән дуслыкта, киләчәккә өмет белән» исемле биш бүлектән тора. Нәфыйков Тукайның Россия укучысы хөрмәтен яулаганына, гади халык күңелендә урын алганына басым ясый. Автор шагыйрьнең әдәби мирасын төгәлрәк күзаллауга юнәлтелгән фикерләр дә әйтә. Мәсәлән, аның фикеренчә, «Доносчы колагына хор белән әйтелер», «Кызганыч бабай», «Фәлсәфи сүзләр» кебек тескстларның авторы Тукай түгел. Ул шагыйрьнең русча язылган әсәрләре булуын, аларны эзләргә, табарга, өйрәнергә кирәклеген дә әйтә. Тукайның алдынгы фикерле, прогрессив карашлы замандашлары, якыннары, танышлары инкыйлаби хәрәкәттә актив катнашуларында Тукай иҗатының, иҗтимагый эшчәнлегенең бәрәкәтле тәэсире бар дип саный.

Нәфыйков Тукай иҗатын, даирәсе белән мөнәсәбәтен, чор вакыйгалары

белән бәйләнешен, чордашларының язмышын өйрәнүне моннан соң да дәвам иттерде. Моның гаять уңышлы нәтиҗәсе итеп 1998 елда рус телендә басылган «Безнең Тукай. Шагыйрь тормышыннан яңа сәхифәләр» исемле китабын күрсәтергә кирәк. Бу монографиядә Нәфыйковның 40 еллык эзләнүләре чагылыш тапкан. «Беркадәр тарих», «Шагыйрь, матбугат эшчәне», «Уральск эзләре һәм серләре», «Туган Казанда», «Дуслар һәм дошманнар» дип исемләнгән бүлекләрдә шагыйрь тормышының төрле чорлары тасвирлана. Шулай да хезмәттә Тукайның Уральскида яшәгән еллары тәфсиллерәк яктыртыла. Ул җигелеп эшләгән, актив язышкан «Фикер», «Уклар», «Әлгасрелҗәдид» журналларын төрекмәннәр, азәрбайҗаннар, балкарлар, комыклар, нугайлар, каракалпаклар, уйгырлар, хәтта калмыклар укыган һәм Тукай әсәрләре белән таныш булганнар дип саный Нәфыйков. Китапта Тукайның рус әдәбияты әсәрләре белән яхшы таныш булуы әйтелә, дәлилләр китерелә.

Китапның тагын бер мөһим ягы шунда: Нәфыйков Тукайның дуслары белән мөнәсәбәтләре турында гына түгел, шагыйрьне өнәмәгән, аңардан көнләшкән, кимсетеп караган, иҗатын түбәнсетеп чыгыш ясаган, аңа дошман күзе белән караган кешеләр турында да күп фактлар китереп, дәлилләп яза. Шундыйлардан аеруча Зариф Бәшири тупас кыланган, ялган фикерләрен «Чүкеч» журналында әледән-әле бастырып торган. Нәфыйков аның «Замандашларым белән очрашулар» исемле китабындагы фактларның ялган булуын әйтеп, китапның басылып чыгуына үкенеч белдерә.

Нәфыйковның Тукай иҗаты һәм иҗтимагый эшчәнлеген тикшергән, совет чорында нәшер ителгән хезмәтләрендә сыйнфый идеология күзлегеннән фикер йөртү шактый күренеп торса да, бүген дә үзләренең кыйммәтләрен югалтмыйлар әле. Алар фактик материалның байлыгы, күп фикерләрнең бүген дә әле актуаль яңгыравы белән аерылып тора, Тукайны өйрәнүдә кыю булырга, ирешелгәннәр белән канәгатьләнмәскә, эзләнергә, туктаусыз эзләнергә чакыра.

Нәфыйков Тукай иҗатына багышланган һәртөрле җыелышларда, конференцияләрдә бик теләп катнашты, яңа мәгълүматлар, фикерләр белән баетылган докладлары тыңлаучыларда һәрчак зур кызыксыну уятты.

Нәфыйков үзен тарихчы галим генә түгел, кызыклы шагыйрь буларак та күрсәтте: бер-бер артлы (әмма гомеренең азагында гына) ике җыентыгын укучылар игътибарына тапшырды. Шигырьләрдә автобиографик детальләр чагылып тора, бер төркем шигырьләренә Тукай образы килеп керә.

Чыганак

Нафигов Р.И. Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли (очерк истории 1895-1917 гг.). — Изд-во казанского университета, 1964. — 446 с.; Нафигов Р.И. Тукай и его окружение. — Казань: Тат.кн.изд-во, 1986. — 208 с.; Нафигов Р.И. Наш Тукай. Новые страницы из жизни Поэта. — Казань: «Фикер», 1998. — 168 с.; Нафигов Р. Слушай, шепчет что трава. — Казань, 2000. — 128 с.; Нафигов Р. Край весенних разливов. — Казань, 2001.

Әдәбият

История общественной мысли народов России и Татарстана. — Изд-во казанского университета, 2001. — 104 с. (статьи Р.А.Гарафутдинова, Е.Д.Румянцевой, М.Юсупова, Р.М.Амирханова); Рамеев З.З. Уроженец Уральска — казанский историк — тукаевед // Түрік тілді халықтар тарихындағы Габдолла Тоқайның орны; халықаралық ... конференция материалдары. – Орал, 2013. – 294 б.

Зөфәр Рәмиев,
филология фәннәре докторы

Сәнгать

— Җырла! — дип, мәшһүр
Урсалга
Баш ия Урал батыр...
Җырчылар сакта торганда,
Дөнья искиткеч матур.

Флёра Гыйззәтуллина

ӘЛМӘТ ТӨБӘГЕНДӘ ТАТАР ТЕАТРЫ: 1940-1970 ЕЛЛАР

ДАНИЯ ГЫЙМРАНОВА,
театр белгече, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Җ.Вәлиди исемендәге әдәби премия лауреаты

1944 ел. Совет гаскәрләре, дошманны эзәрлекләп, алга бара. Шәһәр артыннан шәһәр, авыл артыннан авыл азат ителә. «Барысы да фронт өчен» — тыл әнә шундый девиз белән яши. Киеренке сугыш елларында сәнгать әһелләре дә бөтен авырлыкларны зур фидакарьлек белән үз җилкәләрендә карусыз күтәрәләр. Артистлар тарафыннан төзелгән сәнгать бригадалары сугышның алгы сызыгында була: туплар гөрелтесе астында концерт артыннан концерт куялар, шул рәвешле сугышчыларга мәдәният хезмәте күрсәтәләр.

Әлмәт районы колхоз театры артистлары. 1934 ел

Тылдагылар — Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры, шулай ук, күчмә эш шартларында эшләүче колхоз-совхоз коллективлары — Минзәлә драма театры, Республика күчмә театры артистлары илебез халкы белән берлектә сугышның бөтен киеренкелеген, авырлыгын үз җилкәләрендә татыйлар. Менә шушы авыр, дәһшәтле сугыш елларында Әлмәт якларында нефть катламнары ачыла. Һәм Әлмәт шәһәренең киләчәктә кара алтын үзәге булачагы күздә тотылып, Әлмәт район Башкарма комитеты 1944 елның 3 февралендә анда театр булдыру турында карар чыгара. Бу карар нигезендә Татарстан Министрлар Советы шул елның 20 мартында Әлмәт профессиональ театрын оештыра. Шуңа күрә Әлмәт татар дәүләт драма театрын Татар нефтенең яшьтәше дип әйтергә тулы нигез бар. Ул менә шулай һәвәскәр

1944 елда Әлмәт күчмә театры район мәдәният йортында (фоторәсемдә) **урнаша**

сәнгать коллективы нигезендә стихияле рәвештә төзелә башлый.

Театр мәдәният йорты базасында барлыкка килә. Директорлык вазифасын Нәгыймә Дәүләтшина башкара, тиздән аның янына театрның беренче карлыгачы, Казан театр техникумын тәмамлап кайткан Нәгыймә Кимова килеп кушыла. Баштарак икәүләп, үзешчән түгәрәккә йөрүчеләр ярдәмендә түләүле концертлар оештыралар. Нәгыймә аккордеонда һәм фортепианода уйный белә, татар халык җырларын, төрле спектакльләрдән, опералардан популяр җырлар башкара. Профессиональ җырчыларга сусаган тамашачыны үзенә җәлеп итеп өлгерә. Соңыннан театрга Гыйбадулла Хәбибов (Хәбибуллин), Сания Хәбибова, Касыйм Еникеев, Таһирә Җаббарова, Һади Җәләтов, Хәлимә Маннурова, Хәмзә Рамазанов кебек артистлар килә һәм алар бергәләп зур, катлаулы драма әсәрләренә мөрәҗәгать итә башлый. Артистлар сәхнәләштергән иң беренче пьеса фронтовик-язучы Риза Ишморатның «Кайту» драмасы була (1944 ел). Аны сәхнәгә Әсфан Галиев куя. (Коллектив әлеге пьесага алга таба да берничә тапкыр мөрәҗәгать итәчәк әле.)

Әлмәт театры, табигый ки, репертуарын, нигездә, колхоз тормышына багышланган әсәрләр хисабына киңәйтергә тырыша. Икенче яктан, Бөек Ватан сугышында зур батырлык күрсәткән совет кешеләре образын сәхнәдә гәүдәләндерүне дә үзенең төп бурычы итеп саный.

Аңлашыла ки, театрның иҗади составы тулыланганчы, аңа бер актлы пьесаларга ешрак мөрәҗәгать итәргә туры килә. Сәхнәдә татар драматургиясе классиклары һәм замандаш авторларның әсәрләре уйнала. Шул дәвернең афишалары буенча театр җитәкчесе К.Халәпов төзегән исемлектә түбәндәге әсәрләр китерелә:

1. Г.Камал. «Кайнеш» — 1946.
2. Г.Тукай. «Ысул-кадимче» — 1948.
3. Г.Камал. «Бүләк өчен» — 1948.
4. А.Әхмәт. «Дуслык» — 1948.
5. А.Сәгыйдуллин. «Вәгъдә» — 1949.
6. К.Халәпов. «Бәйрәм алдыннан» — 1949.
7. А.Ампилов. «Яшәсен Корея!» — 1950.
8. Р.Ишморат. «Бүләк» — 1950.
9. А.Никулин. «Тынычлык урамы» — 1951.
10. Р.Ишморат. «Омтылыш» — 1954.

Спектакльдән соң һәрвакыт диярлек концерт куела. Ул вакытларда сәхнә җиһазланышы бик ярлы була, чөнки авылларга барып уйнау өчен

унар чакрым һәм аннан да ераграк араны җәяү тәпиләргә туры килә. Өстәвенә сәхнә киемен һәм бар булган җиһазны үзең белән йөртүне дә исәпкә алсак, артистларның фидакарьлегенә, сәнгатьне чын йөрәктән илаһи мәхәббәт белән яратуларына таң каласың.

«Нефтьне кырыгынчы ел урталарында ачтылар. Шул көннән башлап тормыш үзгәрде, районны алмаштырып куйдылармыни. Шәһәр төзи башладылар. Театр эшләре дә хутка китте, — дип искә ала театр ветераны Хәлимә Маннурова. — Театрның оешкан, аякка баскан көннәрен дулкынланмыйча гына искә алып булмый. Ул район мәдәният йорты каршындагы үзешчән сәнгать түгәрәгеннән барлыкка килде. Без, яшь кызлар, ул вакытта картлар, хатыннар, балаларның күңелләрен күтәрү өчен концертлар куя идек. Аннан бер пәрдәлек пьесалар әзерли башладык. Көзге, кышкы суыкларда җәяүләп яки ат белән күрше авылларга да барабыз.

Башкорт авылы Иштирәккә баруыбызны әле дә хәтерлим. Клубның ватык тәрәзәләрен без килер алдыннан гына фанер белән кадаклаганнар. Аның эче шыксыз, салкын. Сәхнәнең ике ягында ике керосин лампасы эленеп тора. Мин III пәрдәдә генә чыгасы идем. Сәхнә артындагы салам өеменә барып утырдым. Өстемдә сырма, саламга сыеныбрак утырып йоклап киткәнемне сизми дә калганмын. Кемнеңдер кычкырганына уянып киттем. Партнёрым артист Бакиров икән.

— Миңлекамал, — дип кычкырды ул. — Кая югалдың анда?!

Аннан-моннан саламны каккалап сәхнәгә чыктым. Теге минем әле кайдалыгымны, ни эшләргә кирәклеген төшенмәвемне күреп, сөйләвен дәвам итте.

— Син миңа нидер әйтергә теләгән идең бугай, Миңлекамал?

Шунда гына йокым ачылды. Әгәр сәхнәдә хәзерге кебек яктылык булса, тамашачылар минем каушавымны һәм оялудан йөзем кызарганны, һичшиксез, күргән булырлар иде».

Әйе, театр репертуарында акрынлап бик җитди спектакльләр барлыкка килә башлый. Шундыйларның берсе итеп Мирсәй Әмирнең алда искә алынган «Миңлекамал» драмасын күрсәтергә була.

Бөек Ватан сугышында тыл хезмәтчәннәренең каһарманлыгы, фидакарь эшләре хакындагы киң колачлы бу әсәрне сәхнәләштерүне үз өстенә Әлмәткә яңа гына килгән Камал Халәпов ала. 1943 елда ул Курск-Орёл дугасында каты яралана һәм 1944-1946 елларда Минзәлә драма театрында режиссёр булып эшли. Ә 1946 елда аны Әлмәт театрына сәнгать җитәкчесе итеп җибәрәләр. Бер аяксыз сугыш инвалиды, әмма рухы сынмаган Камал солдат бөтен җаны-тәне белән театр эшенә бирелгән шәхес була, югарыда утыручы түрәләрнең бусагасын еш таптый, берәмтекләп диярлек һөнәри кадрлар туплый.

Профессиональ артистларның азлыгы, репертуар кытлыгы, илдәге хәерчелек театр һәм аның режиссёрына җәелеп эшләргә мөмкинлек бирми. Әлбәттә, мондый шартларда труппаның иҗади йөзен билгеләү кыен була.

Театр «Миңлекамал»ны сәхнәләштерергә батырчылык итсә дә, мондый зур полотнолы спектакльне куйганда һәрбер рольгә лаеклы артист кирәклеге ачыклана. Шуңа күрә труппаны артистлар белән тәэмин итү чарасы күрелә. Нәтиҗәдә, 1946-1949 елларда Әлмәт коллективына Минзәлә театрыннан ирле-хатынлы Сәрвәр белән Галимҗан Вәлиевләр, Ютазы театрында эшләгән Илгизәр Кәтиев, Нурзидә Зиазиева, Әлифә Мөслимова, Галимә Лотфуллина, Харис Зарипов, Һади Җәләтов, Касыйм Еникеев һ.б. артистлар чакырыла.

Шушы елларда режиссёр К.Халәпов (1946-1951) Р.Ишморатның «Бүләк», А.Пушкинның «Солдат хаты», Ә.Шамилнең «Вәгъдә», А.Успенскийның «Өч дус тормышы», чуваш язучы-

сы Г.Харлампиевның «Язгы моңнар» (Т.Гыйззәт тәрҗемәсе), Н.Гайсинның «Давыллар эчендә», «Айсылуның мәхәббәте», «Таһир Биккенин», А.Назаровның «Сеңелкәш», үзе тарафыннан язылган «Бәйрәм алдыннан», классик әсәрләрдән Г.Камалның «Кайнеш», «Уйнаш» исемле пьесаларын куя. Шулар арасыннан М.Әмирнең «Тормыш җыры»н сәхнәгә кую коллективның идея-эстетик үсешенә зур ярдәм итә. Театр Г.Насрыйның «Күңел дәфтәре» драмасын куя. Җиңел тел белән язылган, артык катлаулы булмаган ситуацияләргә нигезләнеп эшләнгән бу әсәр, җыйнак кына куелып, театр репертуарында шактый озак саклана.

«Кайту», «Миңлекамал», «Тормыш җыры»ннан соң А.Әхмәтнең патриотик темага язылган «Серләр» драмасы сәхнәләштерелә. Ул республикабызда нефть табылу темасына багышланган. Драмада нефтьчеләр хезмәте, үзара мөнәсәбәтләре, көрәш һәм кичерешләре тасвирлана. Аны К.Халәпов 1948 елда сәхнәгә куя һәм спектакль зур уңыш белән бара.

Райком секретаре (артист И.Кәтиев) һәрвакыт нефть эзләүчеләрне рухландырып тора, чөнки ул үзе нефть табылачагына нык ышана һәм коллективны бердәмлеккә өнди. МТС механигы Газиз Салиховның (артист К.Еникеев) «ташлар җыеп йөрүче» Рәхимәгә (артист Х.Маннурова) мәхәббәт хисе кабынып китүе, өч кызның берьюлы скважинага эшкә килүе һәм башта икеле-микелерәк сөйләнгән авыл карты Фәйзрахман (К.Халәпов) абзыйның соңыннан, мылтык тотып, скважина капкасы төбенә постка басуы һ.б. күренешләр нефтьчеләр арасындагы эчке дуслыкның ныклыгын күрсәтә.

1948 елда Ә.Шамилнең патриотик темага язылган «Егет сүзе» драмасы куела. Эшче яшьләрнең зур рух белән производствоны күтәрү темасын тамашачы үзенең тормышы итеп кабул итә. Бу пьеса актуальлеге белән дә бик әһәмиятле. Теманы уңышлы чагылдыру нәтиҗәсендә, спектакль тамашачыда якын теләктәшлек тудыра. Комсомолец Гаяз (артист Г.Камалов), цех начальнигы Шәрипов (артист Г.Вәлиев) рольләрендә җанлы образлар тудыруга ирешкәннәр.

Әмма шуңа игътибар итәргә кирәк: Ватан сугышына багышланган беренче спектакльләрдә уңай геройлар күп очракта берьяклы, рухи тормышлары чикләнгән һәм шәхси драмалары юк итеп күрсәтелә. Ә мондый хәл, табигый инде, образларны ярлыландыра гына. Моңа ачык мисал итеп Н.Гайсинның «Давыллар эчендә», «Айсылуның мәхәббәте» пьесаларын күрсәтергә була. Гәрчә алар патриотик темага язылган булсалар да, художество эшләнешләре ягыннан аксый төшәләр. Шуңа күрәдерме, бу спектакльләр тамашачыда уңыш казана алмыйлар.

Классик әсәрләр — Г.Камалның «Кайнеш» белән «Уйнаш» пьесалары традицион куелышлары ягыннан башкалардан әллә ни аерылмый. Ләкин, беренчедән, алар башка театр репертуарларында да була, икенчедән, күп кенә артистлар бу спектакльләрдә әледән-әле уйнап килә, шуңа да әсәрләр шома уйнала, образлар кызыклы һәм тулы канлы булып чыга.

Әлмәт театры оешкан чорыннан ук оригиналь әсәрләрдән тыш тәрҗемә материалларга, башка милләт язучылары пьесаларына да игътибарын юнәлтә. Әйтик, «Өч дус тормышы», «Солдат анты», «Язгы моңнар» кебек спектакльләрне тамашачы хуплап каршы ала. Болардан тыш мәшһүр азәрбайҗан драматургы Г.Хаҗибәковның «Аршин мал алан» комедиясе куела.

1949-1952 еллар сезонында Әлмәт театры яңадан тәҗрибәле артистлар белән тулыландырыла. Мамадыш театрыннан Барый Гатауллин, Әгъзам Галиуллин, Әминә Садыйкова, Ибраһим Гомәров, Рәйсә Гобәйдуллина, Зәкия Туишева, Әхмәдулла Галиәкбәровлар килә. Шулай итеп сәхнәгә зур формалы әсәрләр куярга һәм ике бригада белән эшләргә

мөмкинлек туа. Акрынлап театр репертуарында Р.Ишморат, Ш.Камал, Ф.Бурнаш, Г.Камал кебек танылган драматургларның әсәрләре белән рәттән С.Кальметов, Х.Вахит, Ш.Шаһгали, М.Хәсәнов, Г.Ахунов, Ш.Бикчурин, Г.Минский, Г.Хөснуллин пьесалары да күренә башлый. Алар иҗатын әле сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан иң югары баскычларны билиләр дип әйтүе бераз кыен, билгеле, ләкин иҗади эзләнүләр юлында киләчәк өчен аларның әсәрләре дә бик мөһим һәм кирәклеләр.

Гомумән, илленче еллар Әлмәт драма театры тарихына иң катлаулы, иң авыр еллар буларак кереп калды. Театр бирелеп эшли, аңа тәҗрибәле менә дигән артистлар да тупланган. Ләкин һәм иҗат, һәм идея-эстетик, һәм хәтта финанс планын үтәү ягыннан да ул шактый зур кыенлыклар кичерә. Бу, билгеле, бер Әлмәт театры өчен генә хас авырлыклар түгел. Ул чорда барлык совет театрлары шундый ук халәттә яши. 40-50 нче еллардагы сәхнә сәнгатенә бер урында таптану, торгынлык чире хас. Бу, бер яктан, тарихи чынбарлык белән бәйле булса, икенче яктан, берникадәр шул чорда театр мохитендә хакимлек иткән һәм бары тик Станиславский системасын гына алга сөргән тәгълиматлар белән дә бәйле була. Зур академик театрлар ничек кирәк алай шул тупиктан чыгу ягын эзләп тапсалар, кечерәк район театрлары — күчмә шартларда эшләүче сәхнә эшчәннәре өчен бу исә гаять авыр бурыч булып тора.

Режиссура мәсьәләсе, дөресен генә әйткәндә, Әлмәт театры оешыуның башлангыч елларыннан ук төп проблемаларның берсенә әверелә. Ниһаять, 1952 елдан алып биредә режиссёр һәм педагог, ул вакытта әле Татар театр училищесы директоры Сәет Булатов килеп, даими рәвештә спектакльләр куеп киткәли. Алар арасында А.Арбузовның «Гөлмәрфуга», Т.Гыйззәтнең «Кысыр кайгы тәүбәсе» һәм башка әсәрләр бар. Ә инде баш режиссёр Тайфур Кичубаев белемен күтәрү өчен Мәскәүгә укырга киткәч, 1954-1958 елларда ул Әлмәт театрының сәнгать җитәкчесе була. Театр артисты Бари Гатауллин үзенең истәлекләрендә: «Казаннан С.Булатов килде. Ул — ГИТИС тәмамлаган югары белемле режиссёр. Бу театр өчен шатлыклы зур вакыйга булды. Чөнки бездә моңа кадәр С.Булатов кебек режиссёр-педагог эшләгәне юк иде әле. Ул килү белән, театр җанланып китте. Сәет Садриевич күтәренке рух белән эшкә тотынды. Моңа кадәр спектакльләрне бик тиз арада «әмәлләргә» өйрәнгән коллектив яңа спектакльләр өстендә берәр ай эшли башлады. Кыскасы, бу зур иҗади борылыш иде», — дип язды. Әйе, ул театрга күп нәрсә бирә.

Бу еллар һәвәскәр һәм профессиональ белемле яшь артистлар өчен сәхнә серләренә төшенү мәктәбе була.

«Булатовның һәр репетициясе безнең өчен чын мәгънәсендә дәрес иде, — дип искә ала актёрлар. — Ул безне кеше холкының асылына үтеп керергә, шул ук вакытта бер генә вак-төякне дә күз уңыннан ычкындырмады, аңа нинди дә булса мәгънә салырга өйрәтте: сәхнәгә ничек керергә, ничек исәнләшергә, утырырга, хәтта костюмны ничек килешле итеп йөртергә — барысына әһәмият бирде». Шулай итеп, беренчеләрдән булып ул сәхнә теориясен — образга, тормыш дөреслегенә үтеп керә белү, характерларны типаж буларак кабул итү, актёр техникасының асылына төшенеп, аны үзләштерү серләрен ача. Һәм алар С.Булатов эшләгән чорда коллективка кереп кала. Режиссёр-куючы буларак, ул шулай ук яшь драматурглар белән һәм тәрҗемә әсәрләр өстендә күп эшли. Алар барысы да уңышлы килеп чыкты, дип әйтү дөрес үк булмас, билгеле. Ләкин арада Ш.Камалның «Томан арты», Р.Ишморатның «Бай кияү», «Шайтан таягы», Ш.Шаһгалинең «Бала бәхете — ана бәхете», Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр»е күңелле, тормышчан яңгыраган спектакльләр була.

С.Булатов баш режиссёрлык вази-

Сулдан уңга: С.Булатов, Ф.Хәмәтдинов, С.Өметбаев

фасыннан азат ителгәч, театр вакытлыча тагын бер урында таптану, торгынлык чоры кичерә башлый. 1958-1963 елларда спектакльләрне янәдән читтән чакыртылган, килеп-китеп йөрүче режиссёрлар куя. Арада Ш.Габдрахманов, Г.Ильясов, Х.Усманов, Х.Сәлимҗанов, Г.Йосыпов, П.Исәнбәт, Т.Кичубаевлар бар. Аларның кайберләре бер-ике генә әсәр сәхнәләштерсә, Х.Усманов — 4, Х.Сәлимҗанов исә 7 спектакль куя. Ничек кенә булмасын, театр башында хуҗа юклыгы беренче нәүбәттә аның репертуар сәясәтенә йогынты ясамый кала алмый.

Ул чорда репертуар төрле тәрҗемә әсәрләр хисабына чуарлана башлый. Бу турыда 1962-1963 елгы сезон ябылуга багышланган республика киңәшмәсендә дә ачык әйтелә. ТАССРның мәдәният министры Б.Гыйззәтуллин үзенең докладында ачык итеп әйтә:

«Театр репертуар төзү эшендә тиешле мөстәкыйльлек күрсәтми, — диелә анда, — сәнгатьлелеге ягыннан уртакул пьесаларны ала. Әлмәт драма театрының репертуарын киң колачлы пьесалар хисабына баетканлыгын күрмибез. Бу исә аның иҗади үсешенә комачаулый. Соңгы елларны (1962-1963) куелган Байтимеровның «Таһир», С.Кальметовның «Тамгалы йорт», Дилмөхәммәтов һәм Киньябулатовның «Таң атканда» исемле пьесалары эчтәлекләре белән «яңгырамыйлар». Театрга торгынлыктан чыгарга вакыт җитте инде. Шулай ук чынлап торып киң полотнолы әсәрләр куярга иҗтиһат итәргә, үз авторларын булдыру чарасына керешергә, нефтьче, авыл эшчәннәре, төзүчеләргә багышланган пьесаларны һәм шулай ук классиканы да искә төшерегә кирәк», — диелә.

Әлмәт театры хезмәт күрсәткән районнарның социаль йөзе соңгы елларда шактый үзгәрә. Әлмәт, Азнакай, Лениногорск һәм Бөгелмә нефть промышленносте үзәкләренә әйләнә. Инженер-техник интеллигенциянең эстетик таләпләре колхозчыларныкына караганда үзгәрәк, аларны инде колхоз тормышын чагылдырган спектакльләр генә канәгатьләндерми башлый.

Әлмәт театры моны үзе дә аңлый, әлбәттә. Һәм төрле катлам, дөресрәге, төрле һөнәр ияләренең тормышын чагылдырган пьесалар сәхнәләштерүне үзенә бурыч итеп куя. Чыннан да, бу елларны Х.Сәлимҗановның «Ил атасы», Ш.Бикчуринның нефтьчеләрнең тормышын чагылдырган «Тальян моңы», Г.Уральскийның «Балыкчы кызы», З.Аграненконың «Алар язмышы», Х.Уразиковның «Тау чәчәге»,

Әлмәт күчмә театры труппасы. 1935 ел

Ә.Атнабаевның «Ул кайтты» һәм С.Кальметовның «Йолдызлар балкый», «Зәкия», «Уйланырсың, кодагый», «Тамгалы йорт», А.Островскийның «Гаепсездән гаеплеләр», Ш.Камалның «Габбас Галин» дигән пьесалары куела.

Илебездә, җәмгыятебездә бара торган тирән иҗтимагый процессларның чагылышы буларак, театрлар тормышында да зур үзгәрешләр башлана, Әлмәт театры да, җәмгыятебездәге башка сәнгать учаклары белән берлектә «җанлана», яңарышка йөз тота башлый. Әйтелгәнчә, театрның озак еллар буена коллектив белән даими рәвештә эшләүче, аны җитәкләүче режиссёры булмау бу өлкәдә үзенең тискәре йогынтысын сиздерә. Һәм менә 1963-1968 елларда театрның даими баш режиссёры булып Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Габдулла Йосыпов эшли. Тәҗрибәле сәхнә художнигы, сәнгатебезнең үз эшенә бирелгән фидакаре бөтен көчен, сәләтен пыскып яткан иҗат учагын дөрләтеп җибәрүгә, яңадан кабызуга багышлый. Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының танылган артистлары Камал III һәм Ф.Шәрәфиев Габдулла Йосыповка багышланган бер мәкаләдә, аның иҗат эшчәнлегенә хас үзенчәлекләргә тукталып: «Ул бүгенге көнне чагылдырган әсәрләрне куюга аеруча игътибар бирә. Аның тарафыннан куелган 100 спектакльнең 75е совет чынбарлыгына багышланган. Ул драматургларга актив булыша. А.Әхмәт, Г.Насрый, С.Кальметов, Ш.Хөсәенов кебек драматургларның әсәрләре, Г.Йосыповның тырышлыгы нәтиҗәсендә сәхнәгә менеп, зур уңыш казандылар. Габдулла Йосыпов катлаулы рольләрне яшьләргә тапшырудан курыкмый. Ул артист иҗатына хас үзенчәлекләрне табуда аларга булыша».

Г.Йосыпов республика драматурглары белән тыгыз иҗади бәйләнешкә, элемтәгә керә һәм коллективка күп кенә яшь язучыларны тарта. Театр белән драматурглар арасындагы мондый бәйләнеш тиз арада үзенең уңай нәтиҗәләрен сиздерә дә башлый. Ул чакта әле драматургиядә, гомумән, әдәбият өлкәсендә беренче адымнарын атлаучы, хәзерге көндә исә әдәбиятыбызның күркенә әверелгән язучылар Гариф Ахуновның «Утлар яна учакта» һәм Аяз Гыйләҗевнең «Яланаяклы кыз» драмалары бик уңышлы куела һәм алар репертуарны җанландырып җибәрүдә этәргеч көч була. Коллективны тирән социаль эчтәлекле, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан кызыклы һәм камил булган әсәрләр кызыксындыра башлый. Ә аларны кую өчен коллективның

Әлмәт Татар дәүләт драма театры. 2013 ел

үзендәге иҗат мөмкинлекләрен тулы файдалану, тулыландыру зарур иде. Шул максатны күздә тотып, театр каршында студия төзергә карар кылына. Бу чара театрның иҗат перспективасын үстерү нияте белән эшләнелә. Студиягә керергә теләүчеләрнең саны 30дан артык була. Шулардан бары тик алтысы гына сайлап алына, ике елдан соң алар, коллективның тулы хокуклы әгъзалары буларак, театрга артист итеп кабул ителә.

Эшләүләренең тәүге елларында ук халыкка танылып өлгергән Г.Гобәйдуллина, Б.Гатауллин, З.Туишева, К.Игъламова, И.Әбләминов, Д.Хисаметдинова, Р.Ихсанов, Л.Садыйкова, З.Гыйлемов кебек сәхнә осталарының иҗаты белән беррәттән К.Вәлиев, Л.Солтанова, Д.Кузаева, Ә.Мусина, Җ.Исмәгыйлов, Р.Сабиров, Н.Фазлыева, К.Сәетгәрәев исемнәрен дә тамашачы да тиз арада үз итеп, яратып кабул итте. Табигый ки, труппага килгән яшьләр репертуарның уңай якка үзгәрүенә нигез салды. Инде 1965-1966 елгы афишаларга күз салсак, аның бай һәм үзенчәлекле якка үзгәрүен сиземләрбез. Алар арасында Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар» трилогиясе буенча эшләнгән инсценировка, Г.Ахуновның «Утлар яна учакта», А.Гыйләҗевнең «Яланаяклы кыз» һәм «Көзге ачы җилләрдә» драмалары, В.Собконың «Тоткынлыкта» («За вторым фронтом»), М.Кәримнең «Ай тотылган төндә» трагедиясе, Ш.Хөсәеновның «Зөбәйдә — адәм баласы» трагикомедиясе, Р.Хубецова һәм Г.Хугаевның «Кияүләр» («Песня Софьи») комедиясе бар. Репертуар исемлегеннән күренгәнчә, театр пьесалар сайлауда шактый кыюлык күрсәткән. Аталган әсәрләрнең күбесе зур сәхнәләрдә куелган һәм вакыт сынавы узган, һәркайсының сәхнәдә үз урыны бар. Коллективның репертуарда мондый кискен борылыш ясавы — зур күләмле әсәрләргә мөрәҗәгать итүе, һичшиксез, шул вакыт күзлеге аша караганда, уңай күренеш.

Күрәбез ки, оешу, аякка басып, ныклы адымнар белән атлап китү чорында Әлмәт театры үз спектакльләрен күбрәк колхозчыларга, нефтьчеләргә күрсәтә, театрлар була алмаган җирләрдә дә йөри һәм авыл тамашачысының зәвыгын тәрбияли, аның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә зур роль уйный. Инде оешуына 70 ел тулып килгән театр бүген республикада гына түгел, илебездә зур мәртәбәгә ия. ■

ЯҢА КИТАПЛАР



РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН. ДИНИ ВӘ ИҖТИМАГЫЙ МӘСЬӘЛӘЛӘР: сайланма хезмәтләр / Төз.: Л.Гобәйдуллин, Р.Миңнуллин. — Казан: Рухият, 2011. — 344 б.

РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИН. МӘШҺҮР АДӘМНӘР: «Шура» журналы сәхифәләреннән / Төз.: Л.Гобәйдуллин, Р.Миңнуллин. — Казан: Рухият, 2012. — 376 б.

«Рухият» рухи яңарыш фонды тарафыннан Р.Фәхреддин мирасын халыкка җиткерүдә максатчан эш алып барыла. «Ризаэддин Фәхреддин: фәнни-биографик җыентык» (1999), Р.Мәрдановның «Шура» журналы: әдәбият мәсьәләләре» (2001) монографиясе, хәдисләргә комментарийлар булган «Җәмавигуль-кәлим шәрхе» (2005), 4 томнан торган «Асар» исемле биобиблиографик хезмәт (2006-2011), «Мөфти Ризаэддин Фәхреддин хәзрәтләре» («Яңа милли юл» журналы, 1936, №7-8), «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр: сайланма әсәрләр» (2011), «Мәшһүр адәмнәр: «Шура» журналы сәхифәләреннән» (2012) исемле басмалар шушы хезмәт нәтиҗәсе.

Сүзебез «Рухият» рухи яңарыш фонды әзерләп бастырган соңгы ике китап — «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр: сайланма әсәрләр» (2011), «Мәшһүр адәмнәр: «Шура» журналы сәхифәләреннән» (2012) җыентыклары хакында. Беренче җыентыкта Р.Фәхреддиннең шактый зур, фәлсәфи «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр» (1914) исемле хезмәтеннән тыш, шәригать һәм җәмгыять, мөселманнар һәм Россия империясе кануннары мөнәсәбәтләрен яктырткан «Мәктәп вә зәкәт, хәзинә вә земство ярдәме» (1906), «Русия мөселманнарының ихтыяҗлары вә алар хакында интикад» (1906), «Исламнар хакында хөкүмәт тәдбирләре» (1907), «Мәнасыйбе диния» (1907) исемле тирән эчтәлекле әсәрләре һәм «Шура» журналыннан дини, дөньяви мәсьәләләрне яктырткан мәкаләләр тәкъдим ителә.

Р.Фәхреддин «Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр» әсәрендә Г.Курсави, Ш.Мәрҗаниләрдән килгән фикерне — Коръәнгә һәм сөннәткә таянып, мөстәкыйль фикер йөртү кирәклеген куәтли. Моның өчен галим Коръән һәм хәдисләрне, гарәп теле гыйлемен, ислам хокукын тирәнтен белүне шарт итеп куя.

Мөселманнар арасында хәерчелек, һөнәрсезлек, эшсезлекне киметү өчен, садакаларны хәйрия җәмгыятьләренә бирү, фәкыйрь балаларны укыту, алар өчен һөнәр мәктәпләрен ачу, эшли белгәннәренә кул һөнәрләрен үстерергә машиналар алып бирү, ярдәмчесез калган картларга өлкәннәр йорты ачу, фәкыйрьләрне арзанлы торак белән тәэмин итү кебек чаралар тәкъдим итә.

Шулай ук Р.Фәхреддин хатын-кызларны тәрбияләү, садака бирү, хәйрия җәмгыятьләре, вакыфлар, мәет җирләү, «изгеләр каберләре», «изгеләр чишмәләре»нә табыну кебек мәсьәләләргә дә туктала. Изгеләр каберләренә килгәндә, галим: «Догаларны кабул кылучы, бәрәкәт бирүче, һәртөрле куркуларны, мөшкеллекне, хәсрәт вә хасталыкларны, бәла вә казаларны җибәрүче зат — ялгыз Аллаһы Тәгалә, үзең

генәдер», — дип изгеләргә, әүлияларга табынып, алар каберләренә корбан чалу, иман китерү гадәтләрен тәнкыйть утына тота.

«Дини һәм иҗтимагый мәсьәләләр» исемле хезмәте белән Р.Фәхреддин исламны ахирәт дине генә түгел, ә дөнья өчен кирәк булган дин дип карарга өнди. «Инсаннарның ахирәттә сәгадәтләре ислам диненә бәйле булса, дөньяда бәхетле яшәүләре дә ислам диненә ябышуларына бәйледер», — ди ул. Әсәрдә мөселманнар арасында наданлык, эшсезлек, әхлаксызлык сәбәбе, шул чорда киң таралган фикер буенча, ислам дине һәм мөселманлык түгел, ә хак ислам диненнән тиешле дәрәҗәдә хәбәрдар булмаганлык дигән нәтиҗә ясала.

Бу җыентыкка кергән башка әсәрләрдә Россия империясе кануннары һәм мөселманнарның хокуклары, дини вазифалар тикшерелә.

Китап азагында бирелгән 11 мәкаләдә шул заман өчен дин һәм җәмгыять арасында әһәмиятле күп мәсьәләләр — сурәт, мөселманча кием, малны кадерләү һ.б. тикшерелә. Мәкаләләрдә милләт яшәеше темасы үзәктә. Р.Фәхреддин фикеренчә, милләтләрнең үлү сәбәпләре булып аларның башкалар белән кушылулары, икътисад кануннарына игътибар бирмәү, әхлаксызлык, көчсез милләтләр өстеннән көчлесенең золымы тора. Мөселманнар өчен милләт картаюына китерә торган сәбәпләрдән саклану актуаль булып кала бирә, ә моның өчен тәрбия мөһим чара. «Балаларга иман өйрәткәннән соң, һич юанмый, үлгән милләтнең нинди хасталык берлә үлгәнлеген вә шул хасталыктан саклану юлларын өйрәтү мөһим. Бу яшь милләт тә, карт милләт юлы берлә ярдан төшеп китмәсен, үзен һәлаклык диңгезенә ташлап харап булмасын!» — дигән сүзләрне милли тәрбия белән шөгыльләнүче һәрбер мөгаллим истә тотарга тиеш.

Р.Фәхреддиннең «Мәшһүр адәмнәр...» исемле җыентыгында тупланган мәкаләләре 1908-1917 елларда «Шура» журналында дөнья күргән әсәрләре нигезендә төзелде. Мәгълүм булганча, Р.Фәхреддин үзенең күп көчен, вакытын, эрудициясен әлеге журналны басмага әзерләүгә биргән һәм биредә авторы куелган һәм куелмаган күп кенә мәкаләләр дә мәгърифәтче каләменә нисбәтле. Җыентыкның беренче кисәгендә «Шура» журналындагы «Мәшһүр адәмнәр һәм олуг хадисәләр (вакыйгалар)» рубрикасыннан зур күләмле 23 мәкалә тәкъдим ителде. Биредә дөньякүләм мәшһүр затлар — шәрык әдипләреннән Хафиз, Сәгъди, Нәвои, Хәйям кебекләр, европалылардан Бэкон, Декарт, Нобель, шулай ук татар галимнәре һ.б. танылган шәхесләрнең тәрҗемәи хәлләре урын алган. Р.Фәхреддиннең рус һәм Европа зыялылары, көнчыгыш әдипләре, хәтта Кытайдагы тарихи шәхесләр турында да язуы аның энциклопедик гыйлем иясе булганлыгы турында сөйли. «Шура» журналындагы «Мәшһүр адәмнәр һәм олуг хадисәләр» рубрикасы күпмедер дәрәҗәдә «Асар» биобиблиографик хезмәтенең логик дәвамы булып тора.

Җыентыкның икенче бүлегендәге 13 мәкалә дин, мәгариф, матбугат, тарих мәсьәләләренә багышланган. Бу бүлектә Р.Фәхреддиннең тәнкыйть, кадими мәдрәсәләр турындагы мәкаләләре һәм тәрҗемәи хәлләр, сәяхәтнамәләр исемлеге тәкъдим ителгән библиографияләре аеруча фәнни әһәмияткә ия. Мәкаләләрдә аерым шәхесләр һәм аларның әдәби, фәнни эшчәнлекләре турында кызыклы мәгълүматлар бар.

Р.Фәхреддиннең эшчәнлеген һәм иҗади мирасын тулаем җентекләп өйрәнү, репринт һәм хәзерге татар әдәби теленә тулысынча тәрҗемә ителгән фәнни академик басмаларын, тәнкыйди текстларын, кулъязмаларын, документларын күптомлы хезмәтләр рәвешендә укучыга җиткерү киләчәктә зур бурыч булып тора. «Рухият» рухи яңарыш фондының Р.Фәхреддин хезмәтләрен бастыру юнәлешендә башкарган күркәм фәнни гамәлләре хаклы рәвештә милли мирасыбызны барлау һәм кайтару өлкәсендә игелекле гамәл дип бәяләнергә лаек.

Ленар Гобәйдуллин

Дөньяда сүзем калыр

...Сүз хәстәрле чакта
җылы сүзгә
Юмарт язучылар бар иде...
Шигъриятнең тел төбенә хәзер
Кар өйде дә тәкъдир, зар өйде.

Флёра Гыйззәтуллина

АКЫЛ – ТУЗМАС КИЕМ, ГЫЙЛЕМ – КОРЫМАС КОЕ*

ГҮЗӘЛ НӘБИУЛЛИНА, ЛИЛИЯ ГЫЙЛӘҖЕВА,
филология фәннәре кандидатлары

Берәр бөек кешенең шәкерте генә булса да, үзен бөекләрчә тота торган кешегә нисбәтләнә.

Мәхмүт Кашгарый

Гамәл кылмый сүз гыйлемен
уку беләң калганнар,
Аркасына күтәрер
кырык ишәк йөген.

Әхмәд Ясәви

Табиблар дәваламас
авыруын наданның.
Дәвала белем белән
наданлыгын аның.

***

Акыл-гыйлем —
кайсыдыр шул бер баудыр —
Упкыннан безне һәрчак
тотып торыр.

Йосыф Баласагунлы

Күп илне фикер белән яулап була,
«Кылыч белән алыйм», —
дисә таркала.

Котб

Мәңге яшәргә теләсәң, и угыл,
Ал гыйлем, чөнки тереклек суы ул.

***

Гыйлемлек — яшьрен хәзинә,
кем таба,
Ике дөнья байлыгы булыр аңа.

***

Күп гыйлемле булса адәм —
байдыр ул,
Башкалар йолдыз кебектер —
айдыр ул.

***

Чын бәхетне бирә тик гыйлем генә,
Баш ияләр һәрвакыт белемлегә.

***

Килсә дә үлем, галим үлми һаман,
Үлеме килгәнче үк үлә надан.

***

Бел: гыйлем — нур ул,
сине нурландырыр,
Ә наданлык — ут,
сине ул яндырыр.

***

Дөньяның малы кими тоткан саен,
Өстәлә белем сарыф иткән саен.

Габдерәхим Утыз Имәни

Гыйлемдер —
җөмлә әгъмальнең әсасы
(Гыйлем — барлык
эшләрнең нигезе).

Һибәтулла Салихов

Һәрбер гыйлемгә бер остаз кирәк.

***

Дөньяда гакылдан шәриф [кадерле, өстен] нәрсә юк вә рух байлыгыннан артык байлык юк.

*Сәхифә «Дөньяда сүзем калыр» (Татарстан китап нәшрияты, 2012 ел) китабы нигезендә даими алып барыла.

***

Ахмак вә надан адәм дуслыкка вә дошманлыкка ярамас.

Каюм Насыйри

Кеше үзен үзе таныса, камил акылы шуннан беленер.

***

Әгәр берәүгә гыйлем үгрәтергә теләсәң, әүвәл үзеңне үзең үгрәт.

***

Һәрнәрсәнең чиге бар, акылның чиге юк.

***

Әгәр дә бер адәм белән иптәш булсаң, аның акылына кара, диненә карама. Чөнки аның дине үзенә фәкать, ә акылы үзенә һәм сиңадыр.

***

Һәрбер нәрсә күп булган саен, бәһасе арзан булыр, кадерсез булыр. Әмма акыл арткан саен, бәһасе һәм кадере артыр.

Каюм Насыйри

Галим булса, лаф орсын хикмәт берлән!

Акмулла

Надан бай — галимнәр мәҗлесендә телсездер.

***

Якын карендәшләреңне бозык кешеләрдән саклавың кебек, китапларыңны да тиешле булмаган кешеләрдән сакла.

***

Күп наданга иярүгә караганда, аз галимгә иярү яхшырак.

Ризаэддин Фәхреддин

Тарих гыйлеме инсанда милләт хисе уятучы гыйлемнәрнең бердәнбере булганлыгы сәбәпле, алдынгы милләтләр үз тарихларына фәүкылгадә әһәмият биргәннәр вә һаман бирмәктәләр.

Һади Атласи

Укыгач, күпне беләсең икән. Ләкин күзем ачылган саен, фикерем киңәйгән саен, шатлык, тынычлыклар урынына башым төрле кайгылар, хәсрәтләр белән тула бара. Шул хәсрәтләр, шул кайгылар белән йөрәгем янган саен, үземнең яшәвемдә бер ләззәт табам, тормышымда бер ямь сизгән кебек булам.

Гафур Коләхмәтов

Китап язу ул — чиксез мәгънәви азык бирә торган күңелле эш.

Хөсни Кәрим

…Бетә тиз дөнья малы,
мәңге тормый,
Белем бетми,
юылмый һәм дә череми.

Шәехзадә Бабич

Безне адәм иткән уку,
Адәмне алга илткән уку,
Илтеп күккә житкән уку,
Уку, уку, уку.

Сәгыйть Рәмиев

Гыйлемнең кадерен бел,
хасыйль булса*,
Һәрнәрсә кыйммәт була, асыл булса;
Гыйлемнең өстенә һөнәр кирәк:
Җимешнең файдасы аз, яшел булса.

Мәҗит Гафури

Өч наданга алмашынмас —
бер язу белгән кеше;
Мәгърифәт эстәр, иренмәс һич —
кеше булган кеше.

Габдулла Тукай

Укы, бел, яз, яшә, тор син хәзердә!

Сәгыйть Сүнчәләй

Бәхетсезлекнең күбесе наданлыктан башлана.

* Хасыйль булу — барлыкка килү, хасил булу.

***

Фәннең нигезе ныклы фактларга таяна. Кечкенә генә фәнни ачыш та мең тапкыр сыналган, үлчәнгән, кат-кат тикшерелгән, ышанычлы дәлилләргә нигезләнгән булырга тиеш. Шуннан соң гына ул фән дигән бөек һәм мәңгелек сарайга аяк басарга хаклы.

***

Ризык кермәсә, тән ачыга, ә кеше надан булса, аңа рухи азык кермәсә, күңел хәзинәсе, жаны ач кала.

***

Белгәнне бикләп яткыру акыллы эш түгел.

Гомәр Бәширов

Белгән тыйнаклана,
Белмәгән: «Беләм!» — дип мактана.

Нури Арсланов

Фән юлы тип-тигез, тап-такыр гына булмый. Фән юлына маяклар кадалмаган. Ялгышырга да, адашырга да мөмкин. Бер табасың, ул ялгыш булып чыга, тагын эзлисең. Өзлексез эзләнү. Шуңа күрә дә аны иҗат диләр.

***

Фән юлына керү өчен, ат кебек эшләргә кирәк.

***

Фән туганлык, дуслык, әшнәлек белән эш итми. Кемнеңдер абруен саклау турында да кайгыртмый. Фәнгә дөреслек кирәк, бары дөреслек кенә.

Хәй Вахит

Акылсыз башка алтын бүрек файда бирмәс.

Суфиян Поварисов

Кырык ел көтү көтеп, чыбыркы шартлата белмәгән кеше кырык беренче елында өйрәнә алмас.

***

Һәр бүрек эчендә баш булмавы ихтимал.

Әхсән Баян

Акыллы кешенең ихтыяр көчен кайгы да, бәхет тә сындыра алмый. Чөнки ул акылга, гаделлеккә, канунга таяна, чарасызлыктан ничек чыгарга белә. Акыл белән яшәү кешене күп тапкыр бәхетлерәк итә.

***

Ахмаклык кылу өчен, акыл кирәкми.

***

Бу дөньяда фәрештәләрнең белем шәме китап вә белемдер.

Мөсәгыйт Хәбибуллин

Хикмәт баланың нинди телдә укуында түгел, хикмәт баланың ничек укуында, аны ничек укытуда, аңа өйдә нинди тәрбия бирүдә.

Аяз Гыйләҗев

Бик акыллы булып йөри-йөри дә юләргә калуың бар.

***

Акыллы киңәш — яртылаш кимегән эш.

***

Ачыктан-ачык сөйләшү ябык ишекләр артында була.

***

Надан сүзлек карамый, галим аны гомер буе укый.

***

Ахмак акылдан язмый.

***

Акыл тешен да сугып сындыралар.

***

Мин сезгә шундый акыл бирәм: беркайчан да акыл бирергә ашыкмагыз!

***

Акыллы кеше картайгач та матур кала.

Шәүкәт Галиев

Кешегә, ни генә әйтмәсеннәр, акыл бик соң керә.

***

Акыллы кеше белән сөйләшү — җан рәхәте!

Мөхәммәт Мәһдиев

Укыган угыл — атадан олы.

Хәсән Сарьян

Дөньяда иң читене — үз алдыңда акыллы булып күренү.

***

Акыллы кеше эчендәгеи тышына чыгармый. Шуңа күрә ул акыллы булып күренә дә.

Туфан Миңнуллин

Китаплар — кешелекнең хәтере.

***

Кешелекнең миллион еллар буена тупланган иң зур байлыгы — акыл.

***

Кешенең акылы үзенең көчсезлеген җиңәргә тырышуда чарлана.

Фәнис Яруллин

Акыл —
Күз кабагы яшермәгән
Тынгысыз күз.

Әхмәт Гадел

Алламы ул, әллә башка берәр Илаһи затмы, белмим, әмма кешелек дөньясы да, бөтен табигать, Җир шары, хәтта бөтен Галактика ниндидер бер канунга буйсынып яши, алардан өстен ниндидер көч, гомум-галактик Акыл барлыгына ышанам мин.

Флүс Латыйфи

Наданлыгыңны таныйсың икән, димәк, белемгә ачкычың кесәңне тишеп тора.

***

Акылың алтын булса, күңел базына күмеп тор.

***

Үзеннән бер башка сәләтлерәк укучысын әзерли алмаган остазны үзеннән ун башка сәләтсезрәк укучысы таптап китә.

Марсель Галиев

Яшәп-яшәп тә акыл керми безгә. Әллә озаграк яшәгән саен, ул акыл дигәннәре, челләдәге ялгыз — аерым күл кебек, гел саега бара микән? Алай дисәң, каян килә бу әллә нинди уйлар? Алар бит — акыл-ми эшчәнлеге.

Рафаэль Сибат

Зирәк булсаң, исәп йөртсәң —
юл ачык,
Яшәү жирең булмас тишек алачык.

***

Ходай сиңа биргән булса
зирәк акыл,
Надан белән бәхәсләшмә
һичбер вакыт —
Барыбер сүзең асылына
төшә алмас,
Байлыгыңны әрәм итмә:
сүзең — алмаз.

Флёра Тарханова

Тәнеңнең гомерлек табибы бул, телеңнең гомерлек талибе* бул.

Зиннур Мансуров

Жыябыз, жыябыз да ул белемне, шуңа таянып болыннарны юк итәбез, матурлыкны, җанны юк итәбез. Алар урынына ясалма болыннар, ясалма җаннар уйлап табабыз.

Фәүзия Бәйрәмова

* Талиб — эзләүче, таләп итүче, шәкерт.

Күңел
Һәрчак ышанырга әзер,
Ярый, акыл тора сагында.

***

Гел акыллы гына
булып яшәү —
акылсызлыктыр әле үзе дә.

Акъегет

Акылсызның авызына алтын теш куеп кына акыллы сүз сөйләтеп булмас.

***

Ахмаклыктан көлүдә язык юк, ахмактан көлүдә мәгънә дә юк.

***

Ахмак теленең тезгене өзек.

***

Ахмак юләрдән акыллырак, әмма юләр ахмактан әдәплерәк.

***

Аңгырага аңлата-аңлата ахмаклануың бар.

***

Аңгырага дөньяның дүрт ягы да бер.

***

Ахмаклар арасында акыллының акылы артмый, акрынлыгы арта.

***

Бар белгәнен башкаларга белдерүчене бер үк вакытта галим дип тә, бушбугаз дип тә атарга мөмкин.

Мөхәммәт Мирза

Акылы белән югары
Түбәндәрәк тора.
Хикмәт нидәлеген
Тамырлардан сора.

Нәҗибә Сафина

Беркем дә үзеннән акыллырак кешене яратмый. Шул сәбәпле акыллы кеше әңгәмәдәшенә караганда акыллырак күренүдән саклана.

Зөлфәт Хәким

Акыллы кешеләр яхшы белә: ишеткәннәренең яртысына гына ышанырга кирәк. Ләкин бик акыллы кешеләр генә шуның кайсы яртысы хак икәнен аера алалар.

Зиннур Хөснияр

Акыл сатмау хәерле.
Саткан әйбер кире кайтмый ул.

***

Акылның хатасы булмый,
Акылсызлык хатадан туймый.

Бикә Рахимова

Китап белән бергә йөри икән
Гореф-гадәт, акыл, тел, сөйләм.

Харрас Әюп

Акыл сатучылар
Бездә сирәк түгел,
Чөнки моның өчен
Акыл кирәк түгел.

Әхтәм Фәтхи

Котырган ат кебек хисләр алдан чапса, ватык арба кебек акыл һәрчак арттан сөйрәлә.

***

Утыз ел укып, кадак та кагарга өйрәнмәде.

Нурулла Гариф

Күп санлы милләт булсак, безнең китапларны укучылар да күп булыр иде. Китап кадерен белгән кешеләребез күп булса, халыкның үз-үзенә булган ихтирамы артыр, ул үз тормышына аек күз белән карар дәрәҗәдә булыр иде. Һәм бәйсез, иркен тормышлы иҗатчылар тагы да яхшырак әсәрләр язар иде. Бу «иде»ләрне санап кына бетерерлек түгел. Һәм алар миңа беркайчан да тормышка ашмаячак хыял гына булып тоела.

Марат Кәбиров

«Татнефть» берләшмәсе тарафыннан ТАССР территориясендә бер миллиард тонна (1943-1971) нефть чыгарылу хөрмәтенә куелган һәйкәл. Әлмәт шәһәре.

Л.Гобәйдуллин фотосы

Индекс 54132
70275

Халкыбыз тарихы, әдәби, мәдәни мирасыбыз, тәнкыйди фикер һәм заманча караш – барысы да «ЧЫН МИРАС» *журналында*



ИНДЕКС

ТАТАРСТАНДА – 54132

ЧИТ ТӨБӘКЛӘРДӘ – 70275

БЕЗ МИРАСЛЫ ХАЛЫК. «ЧЫН МИРАС» БЕЛӘН БЕРГӘ БУЛЫГЫЗ!